Рәис Сафин

Аллаһка мәдхия

Казан
2018

УДК
ББК
С

Р.Сафин
Аллаһка мәдхия. – Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2018. – 496 б.

Аллаһы Тәгалә бар. Ул бердәнбер Илаһи һәм тиңе булмаган заттыр. Авторның мактауга лаек иҗаты исә – моның һичшиксез шулай икәнлеген исбатлаучы Коръән аятьләренең асыл мәгънәләрен үзебезнең ана телебездә җиткерүендә. Ал арның тылсымлы серләренең чатын ачуда.


Китапның тагы бер асыл сыйфаты, үзенә тартып тору көче шунда: Рәис Сафинның үзенең ихлас дини тойгы-хисләрен белдереп язган шигырь-поэмалары иманлы рух белән сугарылган булуында. Ул шушы әсәрләре аша Аллаһы Тәгаләнең сүзен, Коръән-Кәрим аятьләрен, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.в.) нең хәдисләре эчтәлеген – укучылар игътибарына юнәлтүдә.

Сайланма әсәрләре тупланган авторның бу китабы, иншалла, укучыларның өметләрен аклар, андагы әсәрләрне игътибар белән укучылар, һичшиксез, канәгать булырлар, дигән өметтә калабыз.

© Р. Сафин, 2018
© РИЦ «Школа», 2018



Коръән әйтә: “Фани дөнья тик уенчык”,
Адәми зат шул дөньяның бер баласы.
Ялгыш кына уенчыкка зыян кылса,
Тәмуг дигән ут-ялкынында янасы!





Тугра: Сафин Рәис
Галәүгә улы (С.Р.Г.)

Нәҗип Нәккаш эше.

Сентябрь – 2016.

I бүлек

Коръән безнең тормышта,
Коръән мәңге булмышта...

Галәмнәрнең бердәнбере

Торып-торып исем-акылым китәдер,
Тәре таккан саташып гомер итәдер.
Кемдер ясап куйган җансыз сурәт-рәсем...
Гәм потларны ул Аллаһым дип йөртәдер.

Акыл заты булган кеше, күрә торып,
Үзен алдап көферлеккә башын ия.
Ике мең ел нәсара дин әһелләре
Гайсә пәйгамбәрне, безнең Аллаһ, дия.

Сын-гәүдәсе тора чиркәү, костелларда,
Сурәтенә багып халык дога кыла.
Өч затны[1] да Аллаһ сыйфатында күреп,
Ялган белән башкарыла дини йола.

"Аллаһны без уйлап табар идек" диеп,
Әйткән мәшһүр француз акыл иясе.
Уйлап тапкан адәм сурәтле "аллалар" –
Имештер лә, чиксез Галәмнәр иясе.

Тик Аллаһы охшамаган беркемгә дә,
Ул тумаган, беркемне дә тудырмаган.
Ләкин Ул бар: һәр тарафта, Ул һәр җирдә,
Ул – мәңгелек-әүвәл – ахыры булмаган.

Коръәнле һәр хак мөселман моны белә –
Аллаһыны күңел күзе белән күрә.
Адәменә илаһилык белән өргән,
Мәңге җанлы тәннәр генә гомер сөрә.

[1]Алла ата, Алла ул, Изге рух.

Тере Аллаһ иксез-чиксез Ғаләмнәрнең
Тиңе булмас хуҗасы һәм бердәнбере.
Җисемнәрнең хәрәкәтен барлап тора –
Дөньяларга яшәү бирә, булып тере.

июнь, 2012 ел

Аллаһ куша

Тормышымнан зарланмадым, уфтанмадым,
Ипи-тозым булса шөкерана кылдым.
Ғомер көземдә Аллаһтан вәхи килде,
Алтмыш дүрттә кулларыма каләм алдым.

Язганнарым бәлки бик камил түгелдер,
"Әсәр түгел бу" – дип, әйтер бәлки кемдер.
Бәхәсләшмим. Тик уйларым – изгелектә,
Күңелемә Аллаһ индергән сүзлектә.

Бөек заттан иңгән сүзне, уй-фикерне,
Бәгъзе акыл ияләре ирештерә.
Аллаһ куша адәмнәргә үзгәрергә,
Җирдә халык булсын өчен көрәшергә.

Җир йөзендә бар тереклек бер хокукта,
Филнең хакы бер дәрәҗә, бер зурлыкта.
Саны белән башкалардан аз булудан
Ким дә түгел, хур да түгел бер халык та.

Ғамьсезлектән күгебезне төн каплады,
Милләтебез барган юлдан туктап калды.
Кол Шәрифтәй каһарман булыр уларын
Битарафлык дулкыннары кочып алды.

Сүнеп бара йөрәктәге ут һәм ялкын,
Милләтебез көл хәленә килгән якын.
Шовинистлар учак тирәсенә басып,
Әзер тора сүндерергә ирек утын.

Милли рухы, горурлыгы булган татар,
Учак утын кайнар йөрәгендә тотар.
Билгә бәйлик милли постау сөлгеләрне,
Мәйдан көтә, көрәш көтә чын ирләрне!

5 гыйнвар, 2010 ел

Аллаһының илаһияте

Кемнәр генә, нәрсә генә әйтсәләр дә,
Барлыгы һәм берлеге һәр нәрсәләрдә.

Көч-кодрәтле дөньякүләм хәрәкәттә,
Хәрәкәттә булган барлык бәрәкәттә.

Тиңсезлеге иксез-чиксез Галәмнәрдә
Җан иясе кылган барлык гамәлләрдә.

Илаһилык – җисемнәрнең йөрешендә,
Мәхлукларның җирдә гомер сөрешендә.

Сер-хәзинә, аң-акылы – җир-күкләрдә,
Яшәешне барлык иткән хикмәтләрдә.

Аның кылган гамәлләрен, һәрбер эшен
"Океаннарның суы җитмәс язар өчен"[2].

[2] Коръән сүрәләреннән.

Ул җан өрә һәр цселлек, тереклеккә,
Куркәм нәсел калдырсынга киләчәккә.

Иген цсә, чәчәк ата, шыта цлән,
Ғәм һәрберсе цзенә хас төсе белән.

Яшен яшьни Аның ут-ялкыны булып,
Биниһая Ғаләмнәрдә балкый тулып.

Ғелем-гыйлем, мәгърифәте чик-чамасыз,
Адәмгә Ул тормыш бирде шик-чарасыз.

Җир йөзендә яшәешне барлык итте,
"Ғыйбадәт кылыгыз миңа", – диеп әйтте.

Хак мөселман Исламның биш баганасын
Фарыз итте. Ихлас белән кыла хаҗын.

Йөзләрендә Аллаһ нуры, иман нуры –
Инша Аллаһ, җәннәт юлы булыр туры!

И кардәшем, Аллаһыга гыйбадәт кыл,
Шәфкатенә рәхмәт әйтеп, канәгать бул!

август, 2014 ел

Лә иләһә илләл-лаһ[3]

Лә иләһә илләл-лаһ –
Аллаһы тик бер, дию.
Ғамәл-гыйбадәтләр кылып,
Аны ихластан сөю.

[3] Рамил Курамшин көе

Лә иләһә илләл-лаһ –
Мөхәммәдер рәсүлүл-лаһ.
Аның илче икәнлеген
Коръәндә әйтә Аллаһ.

Лә иләһә илләл-лаһ –
Мөселманның туграсы.
Лә иләһә илләл-лаһ –
Җәннәт ишек тоткасы.

Кушымта:
Лә иләһә илләл-лаһ,
Лә иләһә илләл-лаһ.
Аллаһ – галәмнәр Раббысы –
Бердәнбер тиңсез Илаһ.

июль, 2015 ел

Аллаһыга сыгыныйк

Бербөтенне бүлгәләмик,
Хак Тәгалә – бердәнбер.
Җир йөзендә затлы кеше –
Вәкаләтле илчедер.

Аллаһ вәкил вазифасын
Аның аңына сала.
Идарә итүче инсан
Тәкъдире итеп ала.

Мәшһүр пәйгамбәрләренә
Изге китаплар иңә.
Илаһи Аллаһ сүзләре
Дәшә иманлы дингә.

Хак мөселман Аллаһының
Бар һәм берлеген таный.
Әманәтләрен үтәүне
Бурычы итеп саный.

Тик шәһадәтсез бәндәләр
Фәнне тәүге димәкче.
Аллаһка кайтуны алар
Һаман инкяр итмәкче.

Бүлгәләнмик һәм бүлешмик,
Аллаһны танып белик.
Коръәнне хакыйкать итеп,
Ислам динендә гөрлик.

сентябрь, 2013 ел

Аллаһ хикмәтләре

Без ак тәнле, кара тәнле, саргылт тәнле,
Һәр төснең дә үз сыйфаты, бар үз йөзе.
Бу дөньяга яратылмыш һәр кавемнең
Бар үз дине, бар үз моңы, бар үз сүзе.

Җир-анада миллионлаган үсемлек бар,
Яшәп ята төрле-төрле җан ияләр.
Барысы да, фәрештәләр белән бергә,
Зикер итеп бер Аллаһка баш ияләр.

Тик Үл гына җир-күкләрне барлык итте,
Адәменә бәрәкәтле җан керттте.
Гыйбадәтле, итәгатьле булыгыз дип,
Киң дөньяга Ислам динен фарыз итте.

И саваплы, и гөнаһлы эшләр заты,
Кунак булып Җирдә яшәү бик тә татлы.
Монафикъгай икейөзле булмаганга,
Теге дөнья, бу дөнья да – булыр затлы.

Мөселманнар Аллаһ җәннәтенә керер,
Чынбарлыкта шат-бәхетле тормыш күрер.
Бу дөньяда хәрам эш-гамәл кылганның,
Тәмуг уты ялкыннары тәнен төрер.

Кара тәнле, саргылт тәнле, ак тәнлеләр –
Аллаһының алар тере чәчәкләре.
Адәмнәрне төрле төстә яралтуда
Бардыр аның тиңсез-гыйбрәт хикмәтләре!

август, 2010 ел

Юлы туры, юлы такыр

Торып-торып үз-үземә сорау бирәм:
Ни өчен дим Аллаһ безне җиргә сөргән?
Нигә әле барлык фәрештәләренә:
"Адәмемә сәҗдә кылыгыз сез!" – дигән?

Адәмгә сәҗдә кылмаган Иблис-шайтан,
Яралса да дәһшәтле ут-ялкыныннан.
Кешеләрне алдап аздырудан башка
Эш-гамәлләр һич тә килмидер кулыннан.

Ә Адәмдә Аллаһ сыйфатлары бардыр,
Ул – галимдер, акыл-фикер ияседер.
Бу дөньяда Аллаһ сынауларын үтеп,
Җәннәткә дә хуҗа булып керәседер.

Мөэминнәрнең юлы туры, юлы такыр,
Яши алар Аллаһыга гамәл кылып.
Шәригатьнең кануннарын җанга алып,
Яшәр алар мөселманча гына калып.

июнь, 2010 ел

Бердәнбер

Беренче сан тик Аныкы –
Аллаһ Тәгалә саны.
Ул берләрнең бердәнбере –
Ул бар иткән дөньяны.

Ул – тиңсез акыл иясе,
Ул илаһи Бөек зат.
Дөньядагы тереклеккә
Ул яшәү биргән кат-кат.

Адәм балалары җирдә
Бер җаннан яратыла.
Аның рәхмәт-шәфкатеннән
Яшәүгә хокук ала.

Ике дөньяның рәхәтен
Татыр иманлы җаннар.
Камил акыл галәмәте –
Коръәнгә кергән саннар.

Могҗизалы ул саннарда
Аллаһ хикмәте, сере.
Ул гыйлемле, ул белемле
Затларның бердәнбере.

июнь, 2009 ел

Аллаһка сыену
(Коръәннән)

Җәннәт белән тәмугны аера белгән –
Бу дөньяда Коръән белән тормыш кора.
Итәгатьле, гыйбадәтле адәмнәрнең
Йөзләрендә Аллаһ нуры балкып тора.

Ул – сәгадәт, бәхет нуры, шатлык нуры,
Буыннардан буыннарга килә күчеп.
Коръән белән гамәл кылган кешеләрнең
Нәселләре яшәү җирдә гомер кичеп.

Изге Коръән адәмнәргә акыл бирә,
Акыл белән бизәлгәннең юлы – туры.
Тик хакыйкый һәм Илаһи көчкә ия –
Коръән нуры, ислам нуры, иман нуры.

Аллаһының сөеклесе – тәкъва кеше,
Тик шул заттыр Аллаһ нурында коеныр.
Залимнәрнең яманнан да яманыннан
Хак мөселман бер Аллаһка тик сыеныр.

сентябрь, 2010 ел

Коръән әйтә

Коръән әйтә: "Фани дөнья тик уенчык",
Адәми зат шул дөньяның бер баласы.
Ялгыш кына уенчыкка зыян кылса,
Тәмуг дигән ут оясына барасы.

Туганчы ук язмышларны язып куеп,
Безнең белән оста итеп тәкъдир уйный.
Тели икән – бездән чын әдәм ясый,
Тели икән, гөнаһларга урап сыный.

Галәмнәрнең бер хуҗасы булган Аллаһ:
"Итәгать ит, гыйбадәт кыл миңа!" – дия.
Үз теләге белән җиргә килмәгән зат,
Сәждә кылып, Аллаһыга башын ия.

июнь, 2010 ел

Тик бер!

Иң борынгы кешеләр дә,
Илаһ барлыгын белгән.
Йолалар дингә әйләнгән,
Заманнар үтү белән.

Бөрәңләр шул илаһларны
Аллаһыга тиң иткән.
Сурәткә, потка табыну
Безнең көннәргә җиткән.

Бөрәңләр сынга табына,
Бөрәңләр сурәтләргә.
Әйтерсең, Аллаһ кодрәте
Сыннарда, сурәтләрдә.

Юкны бар итүче илаһ –
Тик тиңдәшсез бер Алла.
Гөммәбез яшәү хокукын
Тик бер Алладан ала.

октябрь, 2009 ел

Үткәннәргә кайтып...

Тапкан-баккан газиз әниемә
Мин мәңгегә әҗәт-бурычлы.
Чәчем белән җирне себерсәм дә,
Тиңли аллмам аңа бурычны.

Үлеме дә телеп-тетрәндереп,
Каләм бирде, яз дип, кулыма.
Өзгәләнеп сагыну-сагышларым
Сәбәп булды иҗат юлыма.

Җәннәт – безнең газиз аналарның
Җирдә йөргән табан астында.
Әти-әни хәер-догаларын
Алып калыйк исән чагында.

Бу дөньяда кылган изгелекләр,
Эш-гамәлләр бирсен игелек.
Коръән әйтә: "Җирдә бар да фани,
Тик үлемдә, диеп, мәңгелек!"

ноябрь, 2007 ел

Коръән әйтер

Дөньялыкта без ялгыштык, без адаштык,
Денсезлекнең сазлыгына кереп баттык.
Без мөшрик тә, без кяфер дә, без монафикъ...
Аллаһының газапларын инде татыйк.

Шул адашу караңгылыгыннан чыгу –
Аллаһының хак ислам диненә кайту.
Ибраһимның милләтендә мәңге калып,
Үзеңне хәр мәмләкәттә итеп тату.

Изге Коръән – хакыйкый белем күзедер,
Ул бәхеткә ирешү юлын күрсәтер.
Халкыбызга: "Аллаһының арканына
Мәңгелеккә ябышу кирәк", – дип әйтер.

май, 2010 ел

Коръәннән

Ислам дине тыя фәхеш, сәрхүшлекне,
Каннар коеп, җаннар кыеп үтерешне.
Аллаһының тыйганнарын белә торып,
Денсез кеше кылып йөри хәрам эшне.

Хак Тәгалә адәмнәргә гыйбрәт өчен
Юлдан язган азгыннарга җәза бирер.
Сихерләнеп елан авызына кергән
Куян кебек, имансыз тәмугка керер.

Ислам динен хур итүче тәкәбберләр
Гөнаһ кылып йөри һаман кяферлектә.
Үзен алдап адаштырган Иблис белән
Мәхшәргәчә алар буладыр берлектә.

Хак Тәгалә үзе шулай хөкем кылган:
Мөселманга ислам динле Коръән иңгән.
Итәгатьле адәмен дингә күндереп,
Җәннәтемне мәңгелеккә бирәм, дигән.

июль, 2010 ел

Җавап
(Коръәннән)

Ишәк укый-яза белми,
Яһүд, насара белә.
Яһүд, насара бот чабып,
Надан ишәктән көлә.

Тәре таккан ишәкләргә
Әйтәләр: "Сез бит җүләр,
Сыным-потлар, иконалар,
Аллаһ түгел бит!" – диләр.

Аллаһ әйтә: "Бу кяферләр
Динне беләләр, юкса.
Тик җәннәткә керер алар
Әгәр ишәк исән хәлдә
Энә күзеннән чыкса".

июль, 2010 ел

Килер бер көн
(Коръәннән)

Килер бер көн: ай, кояшның нуры сүнәр,
Җирләр-күкләр дөм караңгы булып калыр.
Тик Ибраһим һәм Мөхәммәт пәйгамбәрнең
Ислам нуры бар дөньяны урап алыр.

Килер бер көн: кяферләр һәм мөшрикләр дә,
Төркем-төркем Кәгъбә тирәсенә килер.
Ибраһимның ислам динле милләтенә,
Мөхәммәтнең өммәтенә дәррәү керер.

Килер бер көн: тау-кыялар көл булырлар,
Тик Коръәннең аятьләре нык торырлар.
Тәмугларда янып яткан гөнаһлылар:
"Исламлагыз безне", – диеп кычкырырлар.

сентябрь, 2010 ел

Гамәленә күрә әҗере
(“Пәрдә“ сүрәсеннән)

Хак Тәгалә кешеләрнең һәм җеннәрнең,
Кайсыларын тәмуг өчен барлык итә.
Аллаһ сүзен тыңламаган томаналар,
Фанилыктан җәһәннәмгә атлап китә.

Бөрәкләре – комсыз нәфес колы булып,
Иблис-мәлгунь коткысының әсиредер.
Кяферләргә ияргәннең, дус булганның
Нәселенә Аллаһ котсыз язмыш бирер.

Гәммә кеше тормышта үз юлын үтә,
Ә берәкләр туры юлдан читкә китә.
Кяфер белән, иблис белән йөргәннәрне
Аллаһының ут газабы булыр көтә...

октябрь, 2010 ел

Коръән сүзе

Аллаһ башта бу кавемне өстен күрде,
Пәйгамбәрләр күндерде, Тәүрат индерде.
Тик үзенә хыянәт иткәнне белеп,
Каһәр белән җәзасын да иештерде.

Гыйбрәт өчен бу кавемнең бер фиркасын
Дуңгыз, маймыл сурәтенә алыштырды.
Риба малы, ришвәт алган тәкәбберне
Көферлектә Иблис белән чагыштырды.

Алар Аллаһ хөкемнәрен инкяр итә,
Тәүратны да үз файдасына үзгәртә.
Динсезлектә, төрле-төрле бозыклыкта...
Мөшрик белән монафикъны узып китә.

Хәйлә, мәкер белән җыйган хәрам малы
Черер байлык булып җирдә ятып калыр.
Ил каргышы, сабыйларның күз яшьләре
Газап булып муеннарына сарылыр.

Залимнәре нәфесләренә баш ия,
Хөсетләнеп золым кыла, байлык җыя.
Яшәүләре – тик бу фани дөньяныкы,
Тәмугның да аскы каты – аларныкы.

июнь, 2010 ел

Хаклык

Коръән-Кәрим – уңдырышлы җир шикелле,
Бар тереклек таба аннан үз кирәген:
Иман нурын, Аллаһының кануннарын,
Әдәп-әхлак, инсафлы булу үрнәген.

Шул кешеләр эш-гамәлдә игелекле,
Ике дөнья тормышында да кирәкле.
Коръән белән затлы тәрбия алганнар –
Бисмиллалы, ул тәвәккәл, ул йөрәкле.

Адәмнәргә Аллаһ Коръәнне иңдерде,
"Хак мөселман җәннәтемә керер", – диде.
Гәркемнең дә әйтте әле тереләсен,
Кяферләрнең тәмуг утына керәсен.

Тик берәүләр – тәкәббер булып йөргәннәр –
Аллаһының хакыйкатен инкяр итә.
Юкса үле табигатьне терелтергә
Бер шифалы яңгыр явып үтү җитә.

Аллаһының көч-кодрәте иксез-чиксез,
Ул – Адәмнең кеменә дә мохтаҗ түгел.
Коръәнсезне, имансызны, динсезләрне
Бар итү дә, юк итү дә Аңа җиңел.

июль, 2010 ел

Аркан юлы

Аста – ургып-тузгып аккан тау елгасы.
Ике яктан кыккә ашкан тау кыясы.
Кыяларны бер-берсенә тоташтырып,
Аркан тарткан галәмнәрнең Зур хуҗасы.

Хак динендә булган мөэмин-мөселманнар,
Ябышканнар Аллаһының арканына.
Итәгатьле, гыйбадәтле тәкъва җаннар
Аркан аша чыга ярның уң ягына.

Изге Коръән безне хакыйкатькә әйди,
Аркан безне ике дөнья белән бәйли.
Тик кешелек азган саен аза бара,
Киләчәге – тау упкыны сыман кара?..

июль, 2010 ел

Намаз вакыты

Сәждәдә чак – Аллаһ белән
Бәндәнең якын чагы.
Тәкъва, ихлас, саф күңелнең
Гарешкә ашкан чагы.

Аллаһ нурында коеныр
Җан-тәне мөселманның, –
Ике дөнья рәхәтенә
Ирешүе инсанның...

гыйнвар, 2009 ел

Адашу

"Динне кыенлыштырмагыз", –
Бу – Аллаһы кануны.
Коръәндә ничек язылса,
Шулай үтәгез аны.

Шулай дия дин әһеле,
Хәзрәтләр – вәгазьләрдә.
Шулай диелгән хакыйкый
Китаплы кәгазьләрдә.

Тик берәүләр үтә динле
Булыргамы тырышып, –
Хак дингә мөгез чыгара
Наданлыкта карышып.

Әллә ниләр уйлап таба
Газапка тара үзен.
Сөйли тузга язмаганны
Белмичә дин нигезен.

Кайсы – еландай шуыша
Сәждәдә булган чакта.
Берәве тәнен камчылый
Охшатып үзен аткa.

Шулай иткәндә, имештер,
Савабы була мулдан.
Тик бу үз-үзеңне алдау –
Дингә тагылма ялган.

Бу тамаша – каш ясыйм, дип,
Күз чыгарып маташу.
Шайтан юлында саташып,
Вәсвәсәдә адашу.

август, 2015 ел.

* * *

Ут- ялкыннан яратылган горур Иблис:
"Мин Адәмнән затлырак!" – дип, аваз салды.
Кешеләрне туры юлдан биздерергә
Аллаһыдан кәлимәле ирек алды.

Череп юкка чыгар байлык колы булып,
Адәм заты гомер итә ялгышлыкта.
Гәр күңелдә Аллаһ та бар, Иблис тә бар...
Кан-яшь аша көрәш бара бу тормышта.

Коръән белән гамәл кылмаучы адәмнәр,
Җәннәт йортын фанилыкка алыштыра.
Иблис-мәлгунь иманы юк адәмнәрне,
Алдап-йолдап, көндезен дә адаштыра.

сентябрь, 2010 ел

Имансызлык

Монафикъларны яратмый Аллаһ та,
Ул аларны гаепли зур гөнаһта.
Икейөзлеләр бу якта – алабай,
Аргы якта алар сатлык, ялагай.

март, 2006 ел

Дәһри адәм

Бер имансыз: "Алла юк" – дип әйтә,
Ил-җирләргә ялган тарата.
"Әлифне таяк дип белмәгән" ул –
Аш бирүче затка таш ата.

Көч-кодрәте тиңсез Аллаһыга
Бу иш адәм тел-теш тидерә.
Үзен сөеп, юктан бар итүче
Илаһ заттан йөзен чөерә.

Ай-кояшны Аллаһ күккә элде,
Җир, су, һава, утны бар итте.
Галәмнәрне гүзәллеккә бизәп,
Тереклеккә бакый җан кертте.

Адәменә – күркәм төс-кыяфәт,
Чиксез хөрлек бирде җанына.
Җир-әнкәнең барлык нигъмәтләрен
Көйләп куйды аның җаена.

"Эт симерсә, хуҗасын, ди, тешләр",
Бу адәм дә, Аллаһ юк, дия.
Тик Аллаһка шөкерана кылып,
Гәммә мәхлук бердәй баш ия.

август, 2014 ел

Сукырлык турында

Табигатьтә бар ике төрле яктылык:
Рух яктысы, Кояш белән Ай яктысы.
Бар хикмәти Коръән нуры, иман нуры,
Ике дөнья ишегенең сап-соткычы.

Караңгылык мәгънәсе дә ике төрле:
Ул айсызлык, кояшсызлык, нурсыз калу.
Кояш чыгар, ут кабыныр, Ай да калкыр,
Тик динсезлек, имансызлык – сукыр булу.

июль, 2010 ел

* * *

Кем тәрегә, кем сурәткә, кем сыннарга...
Бөтенләре иконага табынадыр.
Хак мөселман Аллаһыга нык ышанып,
Сәҗдә кыла, карап кыйбла ягынадыр.

Хак Тәгалә – сурәт, тәре, сын да түгел!
Галәмнәрдә Ул мәңгелек илаһи көч.
Ул күренми, ләкин Ул бар, Ул – һәр җирдә:
Тик йөреше, искән җилдәй күренми һич.

Аллаһ безне төрле хәлгә куеп сыный,
Адәм заты әле ярлы, әле байый.
Мөселманлык. Иманыңа тугрылыгың
Яхшылыкта, яманлыкта яшәп ныгый.

Таш потларга, иконага табынганнар,
Яши булыр фани дөнья гомерендә.
Аллаһыга табынмаган кяфер заты
Янар тәмуг утларының иң түрендә.

сентябрь, 2010 ел

Фани дөнья, фани эш

Җан иясе матдәләрдән тора,
Тән-гәүдәсен төзи, үстерә.
Миллиардлаган камил күзәнәкләр
Тереклеккә яшәр көч бирә.

Илаһи зат зур төгәллек белән
Иҗат иткән һәрбер әсәрен.
Һәрнәрсәдә аның тиңсезлеге,
Һәрнәрсәгә салган хәбәрен.

Күзәнәкләр үлә, алмашына,
Үзгәрешсез кала йөз, гәүдә.
Аллаһ иҗат иткән әсәрләрне
Төрләндерә аллмый берәү дә!

Төсе-бите, сын-гәүдәсе аның
Булып кала тик бер нөсхәдә.
Ул тик берәү, ләкин охшашлыгы
Очрый булыр берәр кемсәдә.

Аттан ала да, кола да туа,
Ләкин алар туа ат булып.
Җәнлек, бөҗәк, балык, кош-кортлар да...
Мәңге яшәр корттан корт туып.

Хак Тәгалә һәр җан иясенең
Геннарына салган хас сыйфат.
Һәрберсенә җирдә яшәр өчен
Шартлар биргән, кылып илтифат.

Илаһи зат ләкин көч-кодрәтне
Биргән бары кирәк кадәресен.

Хәтта Кеше – акыл иясе дә,
Аллаһыга мохтаҗ иярчен.

Бөлә торып кем соң әйтә алыр
Җир-күкләрдә юк дип Бөек Көч?!
Аның кодрәт, көч-куәте белән
Бу дөньяда бара фани эш.

Галиҗәнап, акыл, аң иясе,
Илаһи зат хуҗа Галәмдә.
Ул Мәҗүд[4] тә, Әхәт тә, Халикъ та...
Ул – Басыйр, Ул – Кадыйр... Галим дә.

24 март, 2007 ел

Үлчәүләреңҗитмәс, үлчәсәң...

Әермәләр үреп, давыл өреп,
Күтәрелде җирдә зилзилә.
Котырынып ачы җилләр исә,
Бөтен дөнья чәчрәп ду килә.

Йорт-каралты түбәләре оча,
Умырыла тирән тамырлар.
Ил-җирләрне диңгез суы юа,
Корбаннарын кемнәр танырлар?

Җирләр-күкләр соң нигә ачулана?
Ни аңлатмак була кешегә?

[4] Мәҗүд – бар.
Әхәд – бер.
Халикъ – булдыручы.
Басыйр – күрүче.
Кадыйр – көчле.
Галим – белүче.

Гөнаһлар алып килгән туфан
Котырына бөтен көченә.

Бу дөньяда һәрчак булып тора
Бәла-каза, хәвеф, фаҗига.
Әле аны сугыш урап ала,
Әле гарасатлы вакыйга.

Кеше дигән акыл иясенә
Нәрсә җитми, ник ул шашына?
Җир-анабыз сыкрый, күкләр елый,
Бу бәддога кемнең башына?

Рәнҗү, каргыш алган адәми зат
Бу дөньяда рәхәт күрерме?
Рәхмәтенә мохтаҗ фәкыйренә
Хак Тәгалә фәтва бирерме?

Җир-ана да, үз анаң да газиз,
Баш иябез алар алдында.
Ике дөнья җәннәтенең биге
Аналарның аяк астында.

Җәннәт әһеле булыр адәменә
Хокук бирә Аллаһ яшәргә.
Аналарның исемнәре тора
Аллаһ исеме белән янәшә.

Алтын-көмеш, энҗе, асылташлар
Ага итми акыл иясен.
Аллаһ хакын, Ана хакын белгән
Ахирәттә алыр бәясен.

март, 2007 ел

Җиргә, күккә карап...

Күзалласаң Галәм төзелешен,
Акыл җитми серен белергә.
Барысы да микрон төгәллектә,
Кем алынган аны төзергә?

Нурлар бөркеп иртән кояш чыга,
Җир йөзендә тормыш башлана.
Болытларны җил китерә куып,
Яңгыр ява, туфрак ашлана.

Шифалы су эчкән үсемлекләр
Керфек сирпи, яшьни-яшәрә.
Җәнлек-җанвар, кошлар бөҗәкләр дә...
Азык ала җирдән яшәргә.

Бер карасаң, гади генә туфрак,
Каян килә аңа бу кодрәт?
Шул туфракта тереклекнең тәме,
Тормыш яме... Җиргә мең рәхмәт!

Кояш балкый зәңгәр күк йөзендә,
Гүзәл тарафта озон, саф һава.
Кем булдыра мондый могҗизаны, –
Кем әмере белән кар ява?

Күкләр белән кем идарә итә,
Тереклеккә яшәү кем бирә?
Ул: "Бул!" дисә, юктан барлык була,
Чиксез Галәмнәргә җан өрә.

Ул бар иткән мәңге юкка чыкмый,
Китә булыр башка тарафка...
Күзәнәкләр кала, матдә кала,
Әверелеп башка сыйфатка.

Бар нәрсәне кирәк кадәр итеп,
Төгәл үлчәүләрдә яралткан.
Кеше дигән сәнгать әсәрен ул
Берничә кат төзеп яңарткан.

Тик бу аңлы сәнгать әсәре дә –
Газиз, зәгыйфь бер җан иясе.
Җирдә вәкил булып ул йөрсә дә...
Аңа килеп башын иясе.

Галәмнәрнең тиңсез бер хуҗасы
Бар нәрсәне белеп яралткан.
Кемгә акыл, кемгә җаен биреп,
Мәхлукләрен җиргә тараткан.

Җир йөзендә булган барлык нәрсә
Бер-берсенә тәңгәл ярашкан.
Иксез-чиксез Галәм тереклеккә,
Ә тереклек күккә җайлашкан.

Күк йөзендә җисемнәр бихисап,
Тик кояш бит ике булмаган.
Төн өчен дә ай берүзе. Әллә
Тагы бер ай күккә сыймаган?

Кем аларны анда бар иткән дә,
Кем кабызган утлы учакны?
Кем җир белән кояш, ай арасын
Төгәл үлчәп куйган бу чаклы?

Кояш икәү, яки якын булса,
Дөрләп янар иде җиребез.
Күк йөзендә ике ай калыкса,
Йолдызларны күрмәс идек без.

Җемелдәгән йолдызларга карап,
Хыялланмас идек бу кадәр.
Күкләр гыйшкы безне ымсындыра,
Сөйгән ярлар кебек ул чибәр.

Галәмнәрнең сихри гүзәллеге
Күңелләргә иңгән безнең дә.
Якты кояш, йолдыз, ай, зәңгәр күк
Адәмнәрнең күзе-йөзендә.

Галәмдәге булган җисемнәрнең
Гәрберсендә вәкарь вәкаләт.
Барысы да Хуҗа фәрманында,
Вәкаләт тә итә хәрәкәт.

Нинди кодрәт, нинди илаһи көч
Гәммә белән итә идарә?
Җисемнәрнең олы-кечеләре
Тайпылмыйдыр читкә бер кәррә.

Тик илаһи Җәнабе Хак күрә
Күңел кылларының дулкынын.
Тик Ул белә, тик Ул гына тоя,
Адәменең йөрәк ялкынын.

Ул ишетә, сизә ни-нәрсәдән
Гәркемнең дә йөрәк тибешен.
Тереклекнең нинди гамәл кылып,
Нинди уйлар белән йөрешен.

Иксез-чиксез Ғаләмнәрне иңли
Аның тиңсез көче-кодрәте.
Ғәрнәрсәдә аның күз-колагы,
Ғәрнәрсәдә аның җөрьәте.

Ул түгелдер пот та, икона да,
Ул түгелдер җансыз сурәт тә.
Юктыр аның сыны-гәүдәсе дә,
Ашау-эчү юктыр, әлбәттә.

Ләкин Ул бар! Ул илаһи бер зат,
Мохтаҗы юк һичбер нәрсәгә.
Мохтаҗ затлар илаһ була аллмый,
Ихтыяҗ да түгел кемсәгә!

Бу уйларым – төш гамәле түгел,
Йокламаган килеш уяну,
Дөньяларны уйлап уяну бу,
Җиргә, Күккә карап уйлану.

апрель, 2007 ел

Шигъри вәгазь

Мөселманча яшәү тәгълиматын
Әл-Коръәндә Аллаһ индергән.
Мәңгелеккә барыр юлны әйтеп,
Кануннарын Җиргә күндергән.

Адәменә хак ислам диненең
Фарыз иткән биш баганасын.
Ғамәл кылган мөэмин-мөселманнар
Хозур кылыр оҗмах дөньясын.

Ислам – Аллаһка ихлас буйсынып,
Ризалыгы өчен эш кылу.
Иман – бер Аллаһыга инанып,
Изге гамәлләрне тапшыру.

"Аллаһ бар! Ул – бердәнбер!" дигәннең
Иман нуры балкый йөзендә.
Хак мөселман Аның рәхмәтенең
Бәрәкәтен тоя үзендә.

Аллаһ – тел гыйльме, фәннәр галиме,
Акыл иясе Ул, тиңдәшсез!
Ул – гыйззәтле, хикмәт иясе дә,
Мәңге яшәре дә бәхәссез.

Аның мәшһүр асыл сыйфатлары:
Затлы, күркәм, камил, иләһи.
Иксез-чиксез Галәмнәргә хуҗа,
Мәңге тере калыр Ул дәһи.

Гәрнәрсәне юктан бар итәргә
Аллаһының җитә кодрәте.
Аның серен белү өчен хәтта
Җитми безнең акыл куәте.

Галәмнәрдә балкып торган Кояш –
Рәхмәтенең нурлы балкышы.
Шул балкышның бәллүр бер тамчысы –
Шәфкатенең айда чагылышы.

Җир-анабыз – Аллаһ могҗизасы,
Йөзек кашы, Галәм юлдашы.
Адәм заты – Аның иҗат тажы,
Юк бу тажның Җирдә аллмашы.

Җәннәткә тиң шушы гүзәл Җирне
Бүләк итте Аллаһ кешегә.
"Кунак ашы – кара-каршы" да бит,
Тик кемнәр соң моңа төшенә?!

Кемнең хәер-фатихасы белән
Килдең, Кешем? Гомер итәсең...
Җирдә яшәп, дин сынавы үтеп,
Кылганыңны алып китәсең.

Аллаһ, изге максат үтәр өчен,
Зекер өчен бакый җан өргән.
Гыйбадәтләр, шөкерана кылып,
Яшәр өчен Җиргә китергән.

Адәми зат! Аның кушканнарын
Үтисеңме ихлас күңелдән?
Үтәгәннәр Коръән кануннарын
Рәхмәтемдә булыр, диелгән.

Барлыгыңны, бирлегеңне танып,
Сәждә кылганнарны гафу кыл.
Ирешкәнгә рәхмәт-шәфкатеңә
Җәннәтеңә күрсәт туры юл!

май, 2006 ел

Җеназадан соң...

Өчесен дә, җидесен дә үткәр,
Кырыгын да үткәр, елын да...
Ай-һай, озын... Озын аралар бар
Кешеләрнең соңгы юлында.

Өчесенә килә иң якыннар,
Җидесенә – туган-тумача...
Кайбер мәҗлес, үзбелдекле хәзрәт,
Абыстайга гөнаһ юл ача.

Вәкарь белән вәгазь сөйләр алар,
Белдеклегә санап үзләрен.
Әрвахларга дога багышлармлар,
Ватып-китеп Коръән сүзләрен.

Кемдер белеп, кемдер белми кыла
Сәдакага фарыз гамәлне,
Кемдер, әнә, җеназалар укый,
Кәсеп итеп шушы әмәлне.

Кем ул анда кеше кайгысыннан
Ясап йөри әле тамаша?
Дине өчен түгел, көне өчен
Хак мөселман белән талаша.

Икейөзле монафикълар бездә
Чабып йөри, нәфесе кушканга.
Мөселманга гаеп ташлар өчен
Азык бирә алар дошманга.

Өчесен дә, җидесен дә үткәр,
Кырыгын да үткәр, елын да...
Булсын Аллаһ ризалыгы өчен
Йолалар да диннең юлында!

май, 2009 ел

Дәвам итә тормыш

Һәрбер җисем атомнардан тора,
Күзәнәктән һәр җан иясе.
Үсемлекләр орлыклардан үсә –
Барысы да Аллаһ бирнәсе.

Аның хәер-фатихасы белән
Туа-яши, бетә-таркала.
Ләкин атом, күзәнәкләр кала,
Орлык шыта, тормыш тын ала.

Җәнабе Хак терелткеч җан өрә,
Яңгыр сибә, тормыш яңарта.
Кояш бата... Караңгы төн ката,
Ләкин иртән балкып таң ата.

Галәмнәрдә тормыш дәвам итә,
Җисем белән җисем ярашкан.
Бинисһая тиңсез бу хәрәкәт
Тартым көче аша тоташкан.

Галәмнәрнең бер хуҗасы – Аллаһ,
Мәхлукларга бирә нигъмәтен.
Җан иясе һәрчак тоеп яши
Аның чиксез шәфкать-рәхмәтен.

Хак Тәгалә үзе бар иткәнне
Саклый-яклый, сөя-ярата.
Табигатьне язын уята да,
Җир-Анада тормыш яңарта.

Җирдә яшәү, тормыш барсын өчен
Әсәрләрен җенси пар иткән.
Якты, нурлы, җылы булсын диеп,
Ай-Кояшны күккә беркеткән.

Гәрберсенә кәсеп, сәләт биреп,
Тормышларын җиргә җайлаган.
Гәрберәсен табигатькә бәйләп,
Көйле яшәр урын сайлаган.

Мәхлукларның шушы җир өстендә
Яшәү белән үлем арасы.
Мәхшәр көнне Аллаһ каршысына
Юктыр җавап тота барасы.

Язылмаган алар тәкъдиренә
Бу дөньяда ниләр күрәсе.
Кеше кебек аңлы тормыш корып,
Аларның һич юктыр беләсе.

Гәм кеше дә фанилыкта гына
Яшәү өчен килсә дөньяга...
Нигә акыл, фигыль, зат сыйфатлар
Кирәк булган бирү аңарга?

Аны гүзәл, камил, аңлы итеп
Яралтуда булган ни сәбәп?
Мәхлуклар күк ул да яшәр иде
Алар кебек үтәп бер гадәт.

Яшиләр иң җирдә төрле җаннар
Бала таба, бага, үстерә.
Кеше кебек сулый, ашый-эчә...
Үз гадәтен үтәп көн күрә.

Кеше кебек кайгы-хәсрәт кичми,
Интекмидер иза-газаптан.
Фанилыкта исәп-хисап ясый,
Авыз итми хәрам азыктан.

Нинди гөнаһ шомлыклары өчен
Адәмнәргә тәкъдир язылган?
Язылганны ул тик бер үтәүче,
Шул сәбәптән юлдан язылган.

Ихтыярсыз калган җинаятьче
Бу дөньяда ала җәзасын.
Кайгылардан янып-көеп яши,
Ялый-ялый йөрәк ярасын.

Яшәп буллмый хата-гөнаһ кыллмый,
Дөньясы бит шулай корылган.
Җирдә газап чигеп яшәүчегә
Тик нигәдер тәмуг каралган?!

ноябрь, 2006 ел

Яшәү катламнары

Табигатьтә бар да катлам,
Аллаһ шулай яралткан.
Бар тереклек катламнарда
Яшәү урыны тапкан.

Кешеләр дә катлам-катлам
Бар өске, аскы катлам.
Яшәр өчен һәр кешегә
Акыл иңгән бер саплам.

Һәр катламның үз шөгыле,
Үз тормышы, үз көе.
Һәркемнең үзенә лаек
Үз начары, үз юне.

Берәүләр азык эшкәртә,
Берәү идарә итә.
Шат-бәхетле яшәү өчен
Мал-мөлкәтләре җитә.

Тик бер адәм катламнарны
Болгатырга маташты.
Арканнан[5] ычкынган халык
Аллаһ юлын саташты.

Рухи байлык җилгә очты,
Хәләлне йотты хәрәм.
Әдәп бетте, әхлак китте -
Яшәгән гомер әрәм.

Бөтен дөнья катлам-катлам -
Катламнар бер Ходайдан.
Үзгәртермен дип уйлама,
Тусаң да син яңадан!

июнь, 2015 ел

[5] Сүз Аллаһы Тәгалә арканы турында.

Иншаллаһ

"Югалтканнарны табарсыз, –
Дия Аллаһ – исламнан".
Чукындырылган татарлар
Аерылды иманнан.

Йөз миллион татар югалды,
Әверелде кяфергә.
Чукынмый калганнары да
Кяферләр белән бергә.

Хәрам ашый, хәрам эчә,
Манкорт балалар үсә.
Милли асылын югалткан –
Татар тамырын кисә.

Теленә богау салдылар
Мәктәпләрен дә ябып.
Балыкка әйләнде халык,
Илсез, телсез дә калып.

"Югалтканнарны исламнан
Табарсыз", дия Аллаһ.
Мәчет-мәдрәсәләр барда
Югалмабыз, иншаллаһ.

ноябрь, 2011 ел

Бердәнбер юл

Аллаһ әйтә: "Югалтканны
Исламнан, – ди, табарсыз".
Йөз миллион татар кырылды,
Каян аллаш табарбыз?

Ханлыгын җуйган татарның
Милли кояшы бата.
Ил-җиребез илбасарның
Табан астында ята.

Ятим калган халык цзгә,
Сатлык түрәләр цзгә.
Дәцләтебезне торгызыйк
Берләшеп динебезгә.

октябрь, 2011 ел

Өч һәдия[6]
(Тарихтан бер сәхифә)

Аллаһының рәхмәтләре яусын!
Өч сәхабә - дәрвиш өч кемсә,
Китергәннәр Болгар дәүләтенә
Символларда изге өч нәрсә:

Юл таягы – дәүләт таянычы,
Ышанычы хәтәр чагында.
Күңелләрдә иман нуры балкыр –
Чалма торса өммәт сагында.

Дин-әхлаклы, кәлям, фикыһ фәнле –
Милләтебез дине сабаплы.
Аллаһының кануннарын язган:
Татар иле – кара савытлы.

Ата-баба ядкәр символларны
Мирас иткән безгә соңыннан.
Газиз халкым милли әманәтне
Васыять итә буын-буыннан.

июль, 2014 ел

[6] һәдия – бүләк

Денсезлек

Тигез хокук таләп иткән мөселманга,
Вәһһабчы дип, нахак бәла, яла якты.
Иманы хак кардәшләргә пычрак атты,
Шул монафикъ аркасында каннар акты.

Хуҗалары бу денсезне мактадылар,
Кәһарман дип, тышенә орден тактылар.
Каберләрдә каргыш, бәддогалар юллап,
Мәрхүмнәр дә кыйблага карап яттылар.

Җир-анабыз тетрәнде бу яман эштән,
Аллаһыдан вәхи иңде кük-гарештән:
"Дәһриләргә җәзам чиксез каты булыр,
Сакланыгыз ялган сүздән, көферлектән.

Ярлыкаусыз гөнаһ гамәл – хыянәттер,
Ияләре Иблис белән янар утта.
Сатлык җаннар – тәмуг кисәүләре булыр,
Котылалмас тәүбә-истигъфар кылып та".

сентябрь, 2012 ел

Ике язмыш,
ике юл

Хак Тәгалә адәм баласына
Камил акыл, ике юл биргән:
«Дөньялыкта үз иркеңдә яшә,
Асылыңда ләкин кал», – дигән.

«Уңга киткән – минем юлым булыр.
Рәхәтемнең хакын өзәрсең.
Күз күрмәгән, колак ишетмәгән
Оҗмах рәхәтләрен гизәрсең.

Уйлаганың - өстәлендә булыр,
Теләгәнең - килер каршыңа,
Һәммәсе дә тиңгел әҗәткәдер,
Гамәл-гыйбәдәт кыл тик миңа.

Сулга киткән - имансызлар юлы -
Иблислектә гөнаһ кылганнар.
Җирнең-Күкнең шәригатен бозган
Тәкәббер һәм дәһри булганнар.

Бу ишләр дә өлешләрен алыр -
Аруланыр тәмуг утында.
Бит алтын да затлы булыр өчен
Яну ала утлы ялкында.

июнь, 2015 ел.

Әйләнеш

Җирләр-күкләр бертуктаусыз әйләнештә,
Әйләнешле көрәш бара яшәештә.
Бүген җиңгән җан иясе – иртәгесен
Үзе корбан башкаларга җиңелештә.

Туу, яшәү, тормыш кору, гамәл кылу –
Барысы да вакытлыча бу дөньяда.
Хикмәт шунда: акыл заты булып җирдә
Яшәвеңнән тереклеккә бармы файда?

Аллаһының дин-иманлы бәндәләре
Яшәештә бәрәкәтле тормыш кора.
Әдәп-әхлак белән гомер итүеңне
Баш очында фәрештәләр саклап тора.

Дөньяда бар рәхимсезе, кабахәте –
Кеше рәвешендә булган хәшәрәтләр.
Байлык колы булып йөргән шул явызлар
Тереклеккә китерәдер һәлакәтләр.

Җан иясе сан-сыйфатта җирдә яши,
Үз-үзенең холкына хас эшен эшли.
Керә алар төрле-төрле кыяфәткә,
Кем оҗмахка, кем үрмәли кыямәткә.

май, 2012 ел

Күк җәзасы

Коръән әйтә: "Элгәреләр
Акыллырак иде" – дип.
Дан, мәһабәт һәйкәлләре
Торалар борын чөеп.

Серле Киек каз юлыннан
Әкәмәт затлар килгән.
Җир кешеләре аларны
Аллалар диеп белгән.

Сыннары чиркәү, йортларда
Тора шул "Алла"ларның.
Кяфер, нәсара табына –
Чынын белми Алланың.

Аллаһ – пот та, сын да түгел,
Дивардагы рәсем дә.
Тумаган, тудырмаган да,
Түгелдер Ул җисем дә.

Үзен инкяр иткәннәргә
Аллаһ хөкеме катгый:
Су баса, давыл котыра –
Дөньяны туфан айкый...

октябрь, 2013 ел

Кеше хакы – Аллаһ хакы, диеп...

Гәр тарафтан чиркәү аваз сала –
Кыңгырау – чаң кага җилкенеп.
Ханнар аңа ризалыгын биргән,
Толерантлык җаен китереп.

Күрше хакы – Аллаһ хакы диеп,
Татар аңа эшләр майтара.
"Бусы минем хакым" – дип күршесе
Золым кылып, әҗәт кайтара.

Юмарт татар илсез-йортсыз калды,
Җире дә юк мәчет салырлык.
Үз хакын да инде күршесеннән
Куәте юк кире алырлык.

Гаепсездән һаман ул гаепле,
Зинданнарда татар милләте.
Эзәрлекләү, кыйнау, җәзалаудан
Иза чигә ислам өммәте.

Таш атканга – аш атучы татар
Гыйбрәт алмый сукыр ялгыштан.
Үлә-бетә күрше хакын хаклый,
Үзмышлар юк, имеш, язмыштан.

Хак Тәгалә шулай куша диеп,
Күршесенең күрә күңелен.
Тамырына балта чаба-чаба
Гәлакәткә илтә килерен.

Эт, мәчеләр дус яшәми җирдә,
Толерантлык булмас берьяклы.
И татарым, бул Аллаһка хаклы,
Милли рухлы, милли сабаклы.

май, 2013 ел

Җәннәтне белү

Коръән әйтә: "Җәннәттә – ди, –рәхәт булыр,
Кирәк нәрсәң өй-йортыңда тулып торыр.
Хур кызлары әйләнәңдә биеп торыр,
Фәрештәләр нигъмәт тулы табын корыр.

Җәннәтнең асыл кошлары канат кагар,
Төрле-төрле ширбәт елгалары агар..."
Бирәүләргә җәннәт бик тә кулай булыр,
Эшләмичә ашап яту уңай булыр.

Аллаһының җәннәтенә керә алган
Гел типтереп яшәр "яңа байлар" сыман.
Кайберәүләр сыйлы бу тормышка түзәр,
Кайберәүләр тик ятудан бик тиз бизәр.

Кырын яту хөрәсәннәр эше дияр,
Эшләп ашый, яши торган тормыш сөяр.
Әйтер: "Җәннәт әүлияләр өчен булсын,
Безнең ише җәһәннәмдә яшәп торсын.

Анда минем ике кулыма эш булыр,
Хезмәтемнән җаным-тәнем сихәт алыр.
Шул тормышта яшәдем мин җир-анада,
Кеше хакын ашамадым беркайчан да.

Эшсезлекнең фаҗига икәнен белдем,
Эшсезләрнең яман кылганнарын күрдем.
Азгынлык та, бозыклык та – эшсезлектән,
Эшсез кеше мажаралар эзли читтән.

Фахишәлек, зина кылулар котыра,
Әби-бабай, бала-чага ач утыра.
Әдәп-әхлак, күркәм гадәт онытыла,
Денсез кеше бөтен явызлыкны кыла.

Аллаһының җәннәте ул – чын могҗиза,
Тик кешегә эшсез тору – үзе җәза.
Хак мөселман – Аллаһыга зекер иткән,
Җир-анабыз – тиңсез, гүзәл җәннәт икән!"

май, 2010 ел

Замана корбаннары

Мәрьям кызның җиңеннән Җәбраил өрде,
Кодрәт белән бу дөньяга Гайсә килде.
Фәхешлектә, сәрхүшлектә йөргән кызлар
Бала таба алмас булуларын белде.

Табибләргә чаба-йөгерәләр хәзер,
Шайтанга да "өрдертергә" алар әзер.
Бала өчен җаннарын бирерләр иде...
Тик һаман да кысыр булып кала гозер.

Фәрештәнең "Амин" дигән чагы булып,
Кодрәт белән тансык бала куйса туып...
Итәгатьле, гыйбадәтле бул Аллаһка!
Мәрьям-Ана кебек асылыңда калып.

Тик заманның чирләрен җыйган анадан,
Сау-сәламәт бала тумый могҗизадан.
Гарип илдә гарип бала туып тора,
Ташландыкта ята бала миллионлаган.

Алар – спид, наркоманлык корбаннары,
Иблис белән дусташ ата-аналары.
Ике азгын зиначыдан туган бала,
Ятим калып, гомер буе җәза ала.

июль, 2010 ел

Чарасызлык

Тереклеккә Аллаһ – ай, кояшны бирде,
Туры юлдан барыр өчен Коръән иңде.
Нәфес колы булып йөргән денсезләрнең
Күңелләрен адаштырып, шайтан җиңде.

"Әгүзү-билләһи-минәш-шайтанир-рәхим"...
Мөэминнәргә шайтанның көче җитмәстер.
Шайтаннарның вәсвәсәсенә ышанып,
Имансызга ияргән кеше – иләстер.

Иләстер дә... Шуңа Хак Тәгалә әйтә:
"Мин теләгән бәндәм туры юлда булыр.
Хак диненнән читкә китеп адашканнар
Газаплардан газаплырак җәза алыр".

Уйланганда – мәгънә бу сүзләрдә бардыр,
"Адашканга ислам дине юлын калдыр.
Тәүбә итеп, иман китергән затыңны
Ялгыш кылган гөнаһларыннан арындыр".

июнь, 2010 ел

Дөреслектә

Балкып янган Галәм кояшыннан
Якты нурлар җиргә ишелә.
Изге Коръән-Кәрим мөнбәреннән
Иман нуры иңә кешегә.

Коръән-Кәрим, кояш кодрәтедәй –
Аллаһ нуры, иман балкышы.
Хак Тәгалә әйткәннәрен үтәп,
Дәвам итә аның тормышы.

Дөрләп торган биниһая кояш
Сүнәр диләр, кылып изгелек.
Тик Аллаһның нуры, изге Коръән,
Тәкъва затлар гына – мәңгелек!

ноябрь, 2008 ел

Җир һәм күкләрнең тетрәнүе

Хак Тәгалә җан иясен парлы итеп,
Бersen хатын, бersen ир итеп ярата.
Дөньядагы барлык җан ияләре дә
Пар булырдай ишен үзенә карата.

Гәммәсенең ире – ир, хатыны – хатын,
Гәркайсының үз вазифасы тормышта.
Хайваннар да, җәнлекләр дә, бөҗәкләр дә...
Шул тәртиптә тормышларын да кормышта.

Табигатьтә һәр җенеснең үз бурычы:
Ир-егетнең ир-егеттә юк өлеше.
Хатыннарның бerse-бersen сөешүе,
Бер үк җенесләрнең була бәрелеше.

Хатын-кызлар бер-берләрен сөешкәндә,
Ир белән ир җенси хистән үбешкәндә,
Җир һәм күкләр ыңгырашып тетрәнәләр
Бу азгыннар җенси тойгы бүлешкәндә.

Күкләр күкри, ут-ялкынлы яшен үгы,
Кисеп үтә шомлы кара болытларны.
Аяз көндә Аллаһның каһәре сугар
Зина кылган кара йөзле мокытларны.

Табигатьнең дөньялыкта үз кануны,
Яшәешне шул кануннар, тәртип тота.
Фәхешлектә, азгынлыкта йөргәннәрне
Тормыш үзе, җәза биреп, басып сыта.

май, 2010 ел

Ялгышмагыз

Гәм Тәүрат та һәм Инҗил дә – Аллаһ дине,
Тик бу изге китапларда – кеше сүзе.
Ай-кояшны болытлар каплаган кебек,
Аллаһ нурын җуйган бу диннәрнең йөзе.

Аллаһ – ата, Аллаһ –углан, Изге рух та –
Гыч тә түгел! Хак Тәгалә ул – бердәнбер!
Гәм Иблиснең уттан яралганын белсәк,
Чиркәүләрдә янган шәмнәр – Иблис-шәмдәр.

Хак Тәгалә тумаган, тудырмаган да,
Ул – мәңгелек Илаһи бер көч җиһанда.
Ул – тередер, ул – тиңсез акыл иясе,
Рәсем-сурәт, сыннарның җаны соң кайда?

Иксез-чиксез Ғаләмнәр хуҗасы булу –
Гәрнәрсәнең хәл-халәтен белеп тору;
Энә күзе кадәр нәни бөҗәкнең дә,
Бинһая җисемнең дә җаны булу.

июль, 2010 ел

* * *

Оҗмах, тәмуг барлыгына
Ышана, ышанмыйлар.
Ахирәт, кыямәтне дә
Бар да, юк та саныйлар.

Иксез-чиксез галәмнәрдә
Буллмас икән ни генә?
Киек Каз юлында мең-мең
Планеталар бар, әнә.

Һавасы, суы бар икән,
Яши, ди, җан ияләр.
Килер бер көн, без цзара
Йөрешербез, дияләр.

Бәлкем ул планеталарда
Торадыр оҗмах йорты?
Йолдызлар җемелдәвендә –
Дулавы тәмуг уты?

Кцккә карап без оҗмахны,
Тәмугны кцрәбездер?
Шәһвәттән тән яратылып,
Без шунда кцчәбездер?

Мең сынаулар аша уза
Оҗмах, тәмугның юлы.
Әй, адәм, син – җир валчыгы,
Хакның тәҗрибә колы.

апрель, 2009 ел

Курыкмагыз!

Безне ачлык-ялангачлык,
Явызлыклар куркыта.
Тираннар җәбер-золымы
Гәрчак якадан тота.

Гайбәтләрдән, яман сүздән,
Гөнаһлардан куркабыз.
Төрле юк-барга ышанып,
Җаныбызны йолкабыз.

Ышанабыз "Аллаһыдан
Куркыгыз!" дигән сүзгә.
Тиңдәше юк гүзәл заттан
Нигә куркырга безгә?

Ул шәфкатьле, мәрхәмәтле,
Бәрәкәтле һәр эше.
Хакыйкатьне хаклый алмый
Куркып буйсынган кеше.

Аллаһ тиран да, явыз да...
Ул залим зат та түгел.
Аллаһ – гаделлек иясе,
Аңа тартыла күңел.

Чиксез Галәмнәрдә балкый
Аның мәңгелек нуры.
Ул – бердәнбер илаһи зат,
Булыйк Аллаһка тугры.

Аллаһтан куркырга тиеш,
Кушканын үтәү мөһим.
Иманы Лиллаһ затларга
Ул Гафур, Рахман, Рәхим.

август, 2008 ел

Канун булсын

"Сырхау кеше ураза тотмасын",
Пәйгамбәрдән килә бу хәбәр.
Адәменә мәрхәмәтле булган
Аллаһка дан, Аллаһу әкбәр.

Уразада ашау-эчү... Хәтта
Ярамыйдыр дару кабу да.
Татарны да берләштерү өчен
Кирәк рухи-милли кагыйдә.
Канун булсын дини кагыйдә!

Бер нәсихәт

Адәм – акыл белән яратылды,
Бар үз уе, бар үз фикере.
Акыллы зат булган адәмнәр дә –
Аллаһының затлы фәкыйре.

Чөнки адәм – зәгыйфь җан иясе,
Тик акылы белән ул өстен.
Ләкин җирдә яшәүне мәхлуклар
Бер хокукта, алар – бербөтен.

Гәммәсе дә Аллаһыга мохтаж,
Рәхмәтенә Аның сыена.
Гәммәсе дә Аллаһ ярдәмнәрен
Тоеп яши гомер буена.

Адәм заты Аңа сәждә кыла,
Ғөнаһларым диеп, ярлыка;
Җир-күкләргә яшәеш индергән
Аллаһ дигән тиңсез барлыкка.

Тик берәүләр акылыннан яза –
Тәкәбберлек ала өстенлек.
И кардәшем, бисмиллаңны әйтеп,
Тәүбәгә кил, дөнья – өч көнлек.

август, 2014 ел

Җан

"Сөбханалла!" – дия адәм заты,
Хак Тәгалә аңа җан өргәч.
"Аллаһ әкбәр!" – диеп мактау әйтә,
Ғәүдәсенә бакый җан кергәч.

Хак Тәгалә юктан бар кылучы,
Мәхлукларга тәкъдир юллаучы;
Бинһая чиксез Ғаләмнәрнең,
Тереклекнең тиңсез хуҗасы.

Аллаһыдан иңгән мәңгелек җан
Мәңгелеккә юлдаш кешегә.
Уртак итеп шатлык-кайгыларны,
Кеше белән гомер кичерә.

Кешедәге вәкаләтле шул җан,
Хәбәр итеп тора Аллаһка.
Уй-хисләр дә, кылган гамәлләр дә...
Бүленәләр савап, гөнаһка.

Бәндәчелек белән белеп-белми
Гөнаһ кылган – тотар җавабын.
Ахирәттә, Кыямәттә булып,
Кичерер ул гөнаһ газабын.

Үзен юктан бар кылучы затка
Җан ияләр иман китерер.
Намаз укып, гыйбадәтләр кылып,
Рәхмәтләрен Аңа җиткерер.

Ходай кушса, җир-анага килер
Кан-орлыктан туып анадан.
Кырыс сынау үтеп, савап җыйса,
Җәннәтенә кайтыр яңадан.

Бар юк буллмый, юктан бар да буллмый,
Кеше җаны – Аллаһ өлеше.
Кеше үлми. Өслүб алышына
Гәм үзгәрә аның рәвеше.

апрель, 2009 ел

Гыйбрәтле гамәлләр

Берәүне Ул олуг, дәрәҗәле итә,
Берәүләр сау, ә берәүләр сырхап китә.
Берәүләрнең башына байлыгы җитә,
Ә берәүләр фәкыйрьлектә сынау үтә.

Зур диңгезнең агар суы катлы-катлы,
Бәрсе татлы, икенчесе аның тозлы.
Ләкин алар бер-берсенә кушылмыйлар,
Әйтерсең лә Үле диңгез – уллы, кызлы.

Хак Тәгалә гыйбрәтле бу гамәлләрне
Адәменә гыйбрәт булсын өчен кылды.
Фәнни-дини гыйлемнәргә ия булган
Коръән үзе мәңгелек могҗиза булды.

май, 2010 ел

Мәңгелек көрәш

Безнең тормыш – көрәш, ызгыш, талаш...
Миллионлаган корбан сугышта.
Тереклекнең яшәү кагыйдәсе –
Бер-беренә азык буллышта.

Иблис-мәлгунь яман кешеләрне
Вәсвәсәли, канын котырта.
Кешелекне, нәфес колы итеп,
Үз канына үзен утырта.

Ләкин кеше дигән җан иясе
Хаталарны тора кабатлап.
Алгарышлы яңа буыннарга
Үткәннәрне буллый яраклап.

Абсолют акыл иясе – кеше,
Галәмнәргә бага карашын.
Көнчелеге, нәфес, хөсетлеге...
Күзәтәдер зиһен тарафын.

Фани дөнья үтә каршылыклы –
Бераңларнең Иблис ипташе.
Тормыш үзе – яхшы белән яман,
Үлем белән яшәү көрәше.

Акыллы зат – үз нәфесе белән,
Аллаһ Иблис белән көрәшә.
Үз каныннан иблис рухын куып,
Хакыйкатькә кеше ирешә.

август, 2011 ел

Адәм

Иллә көләч, елмаюлы,
Якты-нурлы адәм йөзе.
Аллаһтан соң уйлы-хисле...
Акыл заты да ул үзе.

Адәм заты – илаһи зат,
Аллаһ аңарга җан өрде.
Җан белән бергә мул итеп,
Үз сыйфатларын да бирде.

Шуңа Адәм мәңге серле,
Мәшһүр галим, ул – төзүче.
Ул – акыл, фикер иясе...
Буллмаганны бар итүче.

Адәм – балчык кына түгел,
Рухында Аллаһ көче бар.
Тик ул – табыныр зат түгел,
Табынырга бер Аллаһ бар.

Адәм – җирнең хәлифәсе,
Ләкин Аллаһның бәндәсе.
Хәлифә булган бу затның
Бар әле беркөн үләсе.

Җир астына бар керәсе,
Аллаһка җавап бирәсе.
Нинди гамәл кылганлыгын
Мизанда күреп беләсе.

Җирне-күкне онытканны
Аллаһның каһәре ора.
Акыл заты булган Адәм
Хата-гөнаһ кыла тора.

Күкрәк сугып, мин кем, диеп
Йөри җирдә балчык-адәм.
Җир-ананы йолкый-талый,
Чыгырдан чыкты ул тәмам.

Ул – нәфесле, ул – тәкәббер...
Аңа булсын бөтен әйбер.
Байлыгы баштан ашса да,
Нәфесе туймый барыбер.

Тау-ташларны актара ул,
Өстен астына китерә.
Җир өсте үсемлекләрен
Корыта, кырып бетерә.

Җир йөзендә яшәешне
Мәхшәр хәленә җиткерә.
Үз-үзенә тәмуг ясап,
Дөньялыкта газап күрә.

Җелеген, канын суырып,
Тереклекне җансыз итә.
Икейөзле бу тәкәббер
Үз башына үзе җитә.

Кайбер тәкәббер Адәмнәр
Үз-үзләрен "Аллаһ" итте.
Потка, сурәткә табынган
Адәм кяфер булып китте.

"Эт симерсә иясен дә,
Танымый башлар", ди халык.
Хәлифә булган Адәм дә,
Яшәр эт көнендә калып.

июль, 2011 ел

Әхлак

Әхлак – халыкның таҗыдыр,
Коръәннең йөзек кашы.
Ул – әдәп, күркәм гадәт тә,
Күңелнең асылташы.

Дини әхлак – ул шәригать,
Аллаһның рухы сеңгән.
Кеше әхлаклы булсынга
Кануни Коръән иңгән.

Ислам әхлагы – Аллаһның
Бәрлегенә инану.
Биш баганасы балкыткан
Рәхмәтендә нурлану.

Әхлаклы кеше – Аллаһның
Шәрәфле сөеклесе.
Ихластан гыйбадәт кылган
Галибән, бөек кеше!

Гамәле изге булганнар
Хәерле юлдан бара.
Коръәннең янәшәсендә
Мөселман балкып тора.

Әхлагы саф, үзе инсаф,
Хөрмәтле, дәрәҗәле.
Юлы – изге, җаны – көзге,
Күңеле – тәрәзәле.

Коръән әхлагы – иң күркәм
Иманлы, изге әдәп.
Юккамы сине мин бүген
Йөрим әдәпкә әйдәп?!

апрель, 2007 ел

Никах

Туган-тумача җыелды
Никах мәҗлесенә.
Никахлашып яшәү фарыз
Мөселман кешесенә.

Хәзрәт аятьләр укыды
Хатыннар сүрәсеннән.
Егет-кызны вәгазь кылды
Нәсыйхәт җөмләсеннән.

Аллаһының изге сүзе
Ошбу аятьтә иңгән.
"Ирле-хатынлы булырга
Яралттым сезне", дигән.

Иланһи мәхәббәт хисе
Җан иясенә – терәк.
Бер-берсенә тугрылыклы
Булсын никахлы йөрәк.

Оят-намус гомер буе
Күңел сагында торсын.
Изге эш-гамәлләрегез
Айлы-кояшлы булсын!

июнь, 2014 ел

Сур мөгезе әле...

Җәйләрдән соң чуар көзләр килә,
Бәгырьләрне телә моңсулык.
Иртән ап-ак, кырпак кар төшәлә...
Гомер ишек шакый моң булып.

Көзләр булып мыштым картлык килде,
Елларым да йөзгә сарылган.
Яшьлек узган... Гомер арбасының
Тәртәләре көзгә борылган.

Сур мөгезе әле уйнамаган,
Балкып торсын күкнең кояшы.
Изге гамәл кылган бәндәләрнең
Хозыр Ильяс булыр юлдашы.

декабрь, 2013 ел

Тилмердем

Хәдисендә Рәсүл әйтә:
"Белмәгәнеңне әйтмә.
Үзеңне һәм башкаларны
Хәтсез гөнаһлы итмә".

Коръән – Аллаһ могҗизасы,
Ул тиңсез изге Китап.
Аның серләрен белер тик
Бик тирән белемле зат.

Гәр сүзе хикмәт-гыйбрәтле,
Галим зат серен ачар.
Ахырзамангача булып,
Кодрәте чынга ашар.

Ялгышып (әстәгъфирулла!)
Хак сүзгә тел тидердем.
"Раббым, ошбу гөнаһымны
Ярлыка", – дип тилмердем.

декабрь, 2008 ел

Гамәленә күрә...

Дәһри булма, көфер сүзләр сөйләмә син,
Гамәл дәфтәреңә гөнаһ өстәмә син.
Ике дөнья рәхәтләрен күрим дисәң,
Шайтан кушкан гөнаһ эшне үтәмә син.

Туфрак булгач, терелмәбез диеп әйтмә;
Нинди сыйфатта булсаң да ул көн килер.
Иксез-чиксез галәмне бар иткән Аллаһ
Адәменә үз җанын кайтарып бирер.

Яхшыны да, яманны да тере итәр,
Ахирәттә булып, Адәм хөкем көтәр.
Кемгә калҗа, кемгә җәза рәвешендә
Гамәленә күрә өлеш алып китәр.

Яхшылык һәм явызлык ул тигез буллмас,
Хак бизмәндә берсе, шиксез, авыр булыр.
Яхшылыкта – савап, явызлыкта – газап,
Хак Тәгалә хаклык белән хөкем кылыр.

июнь, 2010 ел

Икмәк каргышы

Бер юньсезе ипи ташлап киткән,
Аунап ята агы-карасы.
Чүпләкләрдә ризык өемнәре –
Алар минем йөрәк ярасы.

Бисмилламны әйтеп, башым иеп,
Биштәремә җыям шуларны
Җаным сыкрый, күңелләрем җылый,
Искә алам ачлык елларны.

Кырык өчнең кытлык июнь ае,
Валчык та юк чебен яларлык.
Юктыр өйдә черек бәрәңге дә –
Кәлҗемәсе итеп ашарлык.

Мин шешенеп, үләр хәлгә җитеп,
Өстерәлеп чыктым урамга.
Авыл тып-тын, гүя җансыз калган,
Аңым җуеп, чумдым томанга.

Көч-хәл җыеп, берчак керфек кактым,
Яшь бәбкәләр үлән чемченә.

Мин дә йотып, бераз сихәт алдым,
Хәйран калдым цләп көченә.

Үләп ашап кемдер исән калды,
Ә кемнеңдер өзде бәгырен.
Ач-ялангач цлем аша цтеп,
Икмәкнең без белдек кадерен.

Бер юньсезе ипи ташлап киткән,
Аунап ята агы-карасы.
Ипи ташлап йөргән бәндәләрнең
Бугазында икмәк каргышы.

июнь, 2012 ел

Яңгырдан соң...

Күк күкрәде, яшен угы
Һаваны ярып цтте.
Ялкыны күкләрне урап,
Җир битен төшеп цтте.

Сискәнеп куйды Җир-ана
Күкләр сәламен алып.
Игеннәр башын күтәрде,
Бер мәлгә тынсыз калып.

Әлсерәгән кызу дөнья
Карашын күккә бакты.
Зарыгып көтелгән яңгыр
Төрләвек булып акты.

Йотып-йотлыгып эчте җир
Галәмнең саф ширбәтен.
Җаны-тәне белән тойды
Күкләрнең мәхәббәтен.

Яшен яшьнәү, күк күкрәүләр –
Күкнең яшәү рәвеше.
Яңгыр – тереклекнең җаны,
Җирнең кан әйләнеше.

Йа, Раббым, кодрәтең тиңсез,
Рәхмәтең Синең чиксез.
Күк – атабыз, Җир – анабыз,
Адәмең түгел үксез.

8 гыйнвар, 2007 ел

Иншалла

Мәхшәр көне икән, имеш,
Биниһая мәйданда,
Гамәл дәфтәрләрен тоткан
Шыгрым халык вәйранда.

Булат кылычтан да үткен,
Кылдан да нәзек күпер.
Корбан чалган үтә аны,
Аллаһка әйтеп шөкер.

Тавыш иңде: "Илләллаһ, дип
Тәүбәгә килгән кемсә,
Җәннәтемә керә алыр
Сират күперен үтсә".

Камил акылына килеп,
Уянды татар улы.
Тар сират күперен кичеп,
Барасы аның юлы.

Язмышлардан узмыш...

Суга төкермә, дигән бабамнар,
Ә бел, шул суны үзең эчәрсең.
Саф су эчеп, үз татарың белән
Гомереңнең юлын кичәрсең.

Якын итә ятлар яланганда,
Тормыш өчен кирәк үз кешең.
Ятларга син – эткә аткан сөяк,
Милләтеңә – алтын, көмешсең.

Язмышлардан узмышлар юк, диләр,
Ихтыярсызлыктан аклану.
Аклануга сәбәп бирмик дисәк,
Хаталардан кирәк саклану.

Аллаһ безгә Коръән, дин иңдергән,
Мөселманны саклап, якларга.
Узмыш булыр Аллаһ язганыннан
Кыз-уллары бирсәк ятларга.

Туй-никахлар булсыннар мөбарәк,
Бисмиллалы табын – тугәрәк,
Тугәрәктә үз өммәтең белән
Яшә, кешем, яшә бергәләп!

Читкә язмасын

Җансыз кеше – кансыз кеше,
Денсез, имансыз кеше.
Динен, илен, үзен сата
Имансызның бер ише.

Тамак тәмугка кертә,
Газабын җан-тән кичә.
Чит җирдә тук яшәгәнче,
Илендә санлы яшә.

Дөньяда төрле чак була,
Үкенечтә калмасын.
Чит җирләрдә илсез, динсез,
Яшәргә тик язмасын.

4 июнь, 2008 ел

Аллаһ бүләге

Мәхәббәт – Аллаһ бүләге,
Ул дөньяның терәге.
Яшь чакта да, карт чакта да
Булып тора кирәге.

Мәхәббәт – Аллаһ бүләге,
Бүләкне саклау кирәк.
Ташкын-шашкын уй-хисләрдән
Йөрәккә акыл терәк.

Мәхәббәт белән аң-акыл
Адәмне Кеше иткән.
Ике канатлы кош сыман,
Кеше җир буе киткән.

Бер канаты аның акыл,
Икенчесе – мәхәббәт.
Икесе дә кешеләргә
Аллаһ биргән бәрәкәт.

октябрь, 2007 ел

Ике куен

Тәүге тапкыр юындыргач ана,
Куенына ала баласын.
...Соңгы тапкыр юындыргач бала
Җир куенына сала анасын.

Ике куен. Бersе – юлның башы,
Икенчесе – соңгы ноктасы.
Ике Ананың җылы куенында
Ике дөнья – ишек тоткасы.

Җиде көктә

Күп миллион еллар элек, диләр,
Маймыл тәпи йөри башлаган.
Таяк тотып торайган да, имеш,
Мәңгелеккә таба атлаган.

Алпан-тилпән килеп, китеп барган
Яшәешнең асыл төренә.
Дәверләрнең тирән катламында
Маймылларның эзе күренә.

Бәхәсләшмим, бәлкем, булгандыр да
Ерак үткәннәрдә бу хәлләр.
Кодрәтле вә тиңсез Хак Тәгалә
Барысын да үзе бәхилләр.

Атам – Адәм, Анам – Хәва (гөнаһ!)
Тешләгәндә алма җәннәттә,
Таяк тоткан маймыл затларының
Яшәве бар Җирдә, әлбәттә.

Ләкин алар – маймыл булып калган,
Агач башларында бүген дә.
Изге җанлы Адәм балалары –
Аллаһының җиде күгендә...

Әни талган үлем йокысына

Әни талган үлем йокысына,
Тәсбих тотып ике кулына.
Әни, уян... Уян инде, әнием,
Мәтрүшкәле чәең суына.

Әни талган үлем йокысына,
Сагыш кунган ап-ак йөзенә.
Әллә ниләр бирер идем аның
"Улым!" – дигән назлы сүзенә.

Әни талган үлем йокысына,
Ил рәхмәтен алган табибә.
Мәхәлләнең тансык абыстае,
И кадерле Әнием, Хәбибә.

Әни талган үлем йокысына,
Йөрәгемдә хәсрәт ярасы.
Әни, уян! Аллаһ хозурына
Үзем генә булдым барасы...

Аш ашадым, яшь яшәдем...

Аш ашадым, яшь яшәдем,
Үлемне хак саныймын.
Аллаһның бар һәм берлеген,
Тиңсезлеген таныймын.

Җәннәт тұрен өмет итмим,
Ишек төбе дә ярар.
Туганнарым күрермен дип,
Күзләрем тұргә карар.

Иркәләр идем үзләрен,
Мәхәббәтемә төреп.
Ата-анам, җефетемне
Сөеп, кадерен белеп.

Сый-хөрмәт күрсәтер идем,
Төрле җимешләр куеп.
Өчпочмакны, ипекәйне,
Гүнд чәйләрен, куанып...

Аш ашадым, яшь яшәдем,
Эшем дөньяда кала.
Кеше үзе белән фәкать
Үламәлен генә ала...

Могҗизалы терелү
(Риваять)

Зиннәтле вә затлы сараенда
Ғер аксөяк ята – сырхаулы.
Йөзе кипкән, күздән нуры киткән,
Көннәре дә, бәлки, санаулы.

Заманында ут уйнаткан куллар
Аркан сыман аска салынган.
Җир җимертеп йөргән аякларга
Әйтерсең лә герләр тагылган.

Ярсу елга кебек йөрәкнең дә
Дәрте сүнгән, дәрман түгелгән.
Ташып торган ирлек, сәламәтлек
Ғомер юлларына сибелгән.

Калтырана мескен галиҗәнап,
Ғәрелешә чек-чек тешкә теш.
Сихәт бирми тәнгә илдән җыйган
Мал-мөлкәтләр, алтын вә көмеш.

Әйтерсең лә, табибларның кемдер
Буып куйган белем чишмәсен.
Ғалиҗәнап сырхавының серен
Ғичкем белми ничек чишәсен.

Кояш чыга, ай да көн дә калка –
Вакыт сүтә гомер йомгагын.
Аллаһ белә Әюп пәйгамбәрнең
Елый-елый тәүбә кылганын.

“Йа Аллаһым, – ди пәйгамбәр үксеп,
Үөнаһларым минем ярлыка.
Шайтан вәсвәсәсенә бирелептер,
Табынганмын черер байлыкка.

Ибраһим күк хак мәселман булып,
Яшәремә Сиңа сүз бирәм.
Барлыгыңны, берлегеңне танып,
Хак динеңә иман китерәм.

Намрудныдай мине һәлак итмә,
Кавемемне итмә мәсхәрә.
“Лә иләһә илләл-лаһү” безгә
Үомер бакый булыр гыйбарә.

Коткар мине котсыз бу сырхаудан
Катылыкта тотма бу хәтле.
Үаләмнәрнең тиңсез хуҗасы син,
Акыл иясе дә хикмәтле.

Син рәхмәтле, рәхим вә шәфкатьле,
Син кодрәтле илаһ бердәнбер.
Терелт мине махау[7] сырхавыннан –
Тәмуг газабыдыр бу җәбер”.

***

Шулчак Аллаһ Җәбраиле аша
Сүзен әйтеп, фәрман иңдерде.
“Фәлән җирдә фәлән үлән үсә,
Дәва булыр аңа шул”, – диде.

Янә әйтте: “Баскан җиргә типсен”,
Ике төрле чыгар су гөрләп.
Кайнарыннан алыр шифа-сихәт,
Салкынында табар көч-куәт”.

[7] Махау – проказа.

Әл-Җәбраил таш сарайга килде,
Сырхау Дюп яткан ятакка.
Сүнеп барган шәм-гәүдәне күрде,
Уйга калды тынып озакка.

Гәм Җәбраил Аллаһыга әйтте:
"Тапшырыйкмы әллә тарихка?"
Диде Аллаһ: "Син савыктыр аны.
Миннән сезгә хәер-фатиха".

Шулай диде Аллаһ, әмер бирде,
Пәйгамбәргә гомер теләде.
Кавемен дә, әйкә халкын кебек,
Гәлак иттерәсе килмәде.

Әверелеп кеше сурәтенә,
Әл-Җәбраил эшкә керешә.
"Агачтан – ди, күркәм йорт салыгыз,
Мунчасы да булсын янәшә.

Намаз укып, изге теләк теләп,
Тәкбир әйтеп торсын кавеме.
Гөнаһ-хаталарын ярлыкауны
Аллаһыдан сорап һәркеме".

Күперделәр сырхау пәйгамбәрне,
Хуш ис аңкып торган йортына.
Күзен ачты, йөзе нурлар чәчте,
Иман нуры иңде җанына.

Ул таулардан яшь үлән чаптырды,
Кызу итеп мунча яктырды.
Яраннары шул мунчада юып,
Үләннәргә төреп яткырды.

Аллаһ әйткән җлән төнәтмәсе
Шифа булды сырхау тәненә.
Коенды ул госел, һәр биш вакыт
Намаз укый-укый көненә.

Пәйгамбәрнең изге догалары
Аллаһ тарафына иреште.
Илчесенең тәүбә-истигъфарын
Оҗмах белән тәмуг бүлеште.

Дюп тәнен каплап алган чирне
Хак Тәгалә артка чигерде.
Башкаларга гыйбрәт булсын өчен
Икеләтә бала, мал бирде.

Хак Тәгалә тугры булганнарга
Миһербанлы, юмарт, рәхмәтле.
Сын-потларга табынучы адәм –
Мәңгелеккә булыр ләгънәтле.

Тәүбә итмәс мөшрик бәндәләрнең
Киләсе бар Аллаһ каршына.
Сәмуд кавме кебек кяферләрнең
Тәкәбберлек җитте башына.

Дәһриләрнең һәрчак баш очында
Булып торыр Аллаһ каһәре.
Җәзасыннан кемдер котылса да,
Газап чигәр нәсел-нәсәбе.

июль, 2013 ел

Тарихтан бер сәхифә

Аны денсез Намруд[8] патша
Ут-ялкынга ташлаткан.
«Лә иләһә илләл-лаһ» – дип,
Уттан ул янмый чыккан.

Потларга табынган халык
Аптырап хәйран кала.
«Аллаһ бар, Ул бердәнбер», – дип,
Дөрес әйтәме бала?

«Нинди кодрәт Ибраһимны
Ялкыннан йолып алды?
Давылланып янган утта
Ул ничек исән калды?

Табынган потларыбыз да
Янмый калаллмас иде.
Кояш үзе дә бу уттан
Исән чыгаллмас иде».

Шулай уйлый җыен халкы
Шиксез могҗиза күреп.
«Уттта янмаган Ибраһим
Әйтә булыр бик белеп».

«Ул – сихерче», – ди берәүләр, –
Яндыру кирәк аны.
Бабалар изге санаган
Мәсхәрәли потларны».

[8] Намруд – мөшрик кавем патшасы.

Халык төркемгә бүленде,
Күрде ялганны, хакны.
Әһамруд: «Дәһшәтле итеп,
ягыйк, – диде, – учакны».

Халык Ибраһимны яклап,
Кат-кат уратып алды.
Ибраһим галәйһиссаләмнең
Янында алар калды.

Аллаһ Ибраһим халкына
Салды рәхмәт-шәфкатен.
Мөэмин-мөселманга бирде
Мөбарәк бәрәкәтен.

Гыйнвар, 2016 ел.

Пәйгамбәрне яд итү

Кешелекнең соңгы пәйгамбәре –
Хак Мөхәммәд Галәйһиссәлам.
Ислам динен безгә ирештергән
Ул – беренче мөэмин мөселман.

Дин-иманын үз йөрәге аша,
Инануы аша кичерде.
Аллаһының изге ислам динен
Дөнья өммәтенә күчерде.

Аңа Җәбраил фәрештә аша
Изге Коръән иңде Аллаһтан.
Белем, гыйлем, дини тәгълиматны,
Мәгълүматны алды догматтан.

Аллаһының бар һәм бирлеген ул
Күңеленә салды өммәтнең.
Кыямәттә янә тереләсен,
Булачагын тәмуг, җәннәтнең.

«Исламның биш баганасын үтәү –
Фарыз, – диде мөэмин бәндәгә. -
Намаз уку, рузә тоту, зәкят бирү –
Бурыч үтәү булсын һәркемгә!»

Шулай диде тиңсез Аллаһының
Пәйгамбәре, колы, илчесе.
Дине өчен мең газаплар чиккән
Ике дөньяның да кешесе!

Ятим калган Габдулланың улын
Рәсүлүллаһ итте Аллаһы.
Миллиардлаган мөэмин мөселманда
Аллаһ нуры вә Аллаһ рухы!

Гыйнвар, 2016 ел.

Соңгы чик

Без кешене акыллы зат дибез,
Чынлыкта ул акыл затымы?
Акыл заты диеп аталырга
Адәми зат чынлап хаклымы?

Яралганнан бирле кан-яшь коя,
Сугышмыйча торган чагы юк.
Җир-әнкәне талый, күкне даулый,
Нәфесенең иге-чиге юк.

Дөньядагы һәммә җан иясе
Табигатькә яшь ярашып.
Кеше заты берсе белән берсе
Бертуктаусыз тора талашып.

Аңа һаман дөнья малы җитми –
Аннан йолкый, моннан умыра.
Җәннәткә тиң гүзәл җир-әнкәне
Мәсхәрәли, шәрә калдыра.

Йә әйт, кеше. Син кем? Гүя ни өчен
Яратылдың гүзәл бу җирдә?
Акыл, зиһен кебек сыйфатларың
Кирәк кадәр юкса үзеңдә.

Аллаһ сине хак вәкиле итте,
Китапларын сиңа иңдерде.
Дин-иманлы, намаз-гыйбадәтле
Кеше итеп җиргә күндерде.

Җир-әнкәдә тормыш булсын өчен
Хаким булу кирәк кешегә.
Динле булу, гыйбадәтле булу –
Син бәхетле булсын өченгә.

Тик син, кеше, үтә киребеткән!
Үз туксаның синең тик туксан.
Кырык ел син чүл-сахралар гиздең,
Арынмадың котсыз холыктан.

Ничә килдең, ничә киттең Җирдән,
Аллаһ сине кат-кат сынады.
Утка якты, күктән ташлар атты,
Суга батырып та карады...

Тик син һаман гыйбрәт аласың юк,
Башың бетәр эшләр кыласың.
Көч-дәһшәтле корал ясауларың
Үз башыңа, бел син, буласын?!

Уйла, кеше! Афәт якыная,
Акылга кил. Төзәт ялгышны.
Йә Аллаһка тәүбә итәсең, йә
Туктатасың җирдә тормышны.

Җир-әнкәне үз әнкәңдәй ярат,
Аның кебек бул син хикмәтле.
Акыл белән гамьле яшәгәндә
Булырсың син һәрчак җәннәтле.

Гыйнвар, 2016 ел.

Саранлык бәласе

Саранлык та, юмартлык та, –
Үз эшләрен башкара.
Артык юмарт булганнарның
Гаиләсе ач кала.

Динне белми, зәкят бирми
Яшәсә саран посып,
Җәннәт әһеле булалмас,
Калыр ул малын кочып!

Ноябрь, 2015 ел.

Хисап бирәбез

Бу дөньяда кемнәр генә юктыр:
Яши булыр яхшы, яманы.
Аллаһының чиксез рәхмәтендә
Булып тора төрле заманы.

Яхшысы да, яманы да яши
Төрле юлда, төрле күңелдә.
Тик берәүләр яшәр Күк илендә,
Ә берәүләр каргыш телендә.

Без кешеләр – акыл заты булып,
Сынау өчен килгәнбез.
Кылынган һәр эш-гамәлләр өчен
Аллаһыга хисап бирәбез.

Дәһри бәндә бәлкем ышанмас та
Коръәндәге Аллаһ сүзенә.
Тик берәү дә, хәтта уй-фикер дә
Хуҗа түгел ләкин үзенә.

Башлар иеп, Аңа гамәл кылып,
Ләббәйкә ди Җәләм дөньясы.
Җир-күкләрнең, барлык тереклекнең
Ул хуҗасы – тик бер Алласы.

Март, 2017 ел.

Мәңгелек сорау

Галәмнәрнең иге-чиге юктыр,
Әмәл дә юк буен үлчәргә.
Күләменә – фән колачы җитми,
Акыл җитми күкне иңләргә.

Гади генә яфрак, нәни бөҗәк, -
Уй-фикергә сыймас могҗиза.
Табигатьнең асыл серләренә,
Галәмнәргә Аллаһ тик хуҗа.

Тик бердәнбер Хак Тәгалә генә
Яшәешнең Әлхәм догасы.
Дөньяларны юктан бар кылучы –
Тик Ул гына Күкләр Раббысы.

Йолдызларны, Җирне, Ай-Кояшны
Элеп куйган Күккә беркетеп.
Ай-Кояшның нуры, Җир сулышы
Дөньяларны тота бар итеп.

Шифа нурлар, яңгыр тамчылары
Җир-Әнкәгә бирә бәрәкәт.
Тереклеккә тормыш бүләк итә
Тик Аллаһы. Аңа зур рәхмәт!

Көч-куәтле Аллаһ - илаһи зат,
Ул мәңгелек кодрәт иясе.
Чиркәүләрдә сурәт, җансыз потлар...
Аларны соң кемнәр диясе?

Март, 2012 ел.

Нәфес турында

Бу дөньяда барысы да
Парлы булып яралган.
Тискәре, уңай сыйфатлар
Янәшә урын алган.

Яшәеш дәвам итсенгә
Алар булуы мөһим.
Яхшы-яман һәр сыйфатка
Булсын акылың хәким.

Һәр сыйфатның үз холкы бар
Үз горефе-гадәте.
Үзенә генә хас булган
Характер, табигате.

Нәфес – илаһи сыйфаттыр, –
Иҗатчысы тормышның.
Ләкин вәсвәсәле нәфес
Хәвефлесе язмышның.

Акыл, хикмәт хәлфә булсын,
Нәфесне шәкерт итик.
Изге гамәлләр кылуда
Нәфесне узып китик.

Июнь, 2017 ел.

Хисләрем дисбесе

Иртә торсаң – ит пешә, ди,
Соңга калсаң – бит пешә.
Яшьтән иҗтиһат иткәннәр
Дан-шөһрәткә ирешә.

Соңга калдым. Кабаландым –
Куып җитәргә теләп.
Үй-фикерем, сүз сөрешем
Җаныимны алды билән.

Ашыккан – ашка пешкән, дип,
Дөрес әйтә шул халык.
Ашыкканда иң мөһиме,
Һай, китә бит онытылып.

Әллә әмәлен тапмадым,
Төшенмәдем серенә.
Әсәрләрем чиле-пешле
Язылды күк үземә.

Юкса инде бик тырыштым,
Бөтен җан-тәнем белән.
Хис-тойгыларым дисбесе
Хак Тәгаләдән иңгән.

Соң булса да, уң булсын, дим,
Бәрәкәтле юнь булсын.
Көзге җимеш татлы була, -
Тәме телләрдә калсын.

Ихластан әйткән сүзләрем
Яшәешкә ямь бирсен.
Ай-кояштай нурлар бөркеп,
Күңелне назга төрсен.

Өметле теләкләр белән
Сөеп яратам сезне.
Чичек булсам, шул сыйфатта
Кабул итегез безне.

Май, 2017 ел.

Онытмыйк!

Әй татарым, мин синең бер улың,
Гомер буе ихлас яраткан.
Гомер буе сиңа тугры калып,
Җан-тәнеңә сихәт тараткан.

Бу дөньяда озын-озак яшәп,
Аңладым мин изге хаклыкны.
Язмышларны үзгәртерлек тиңсез
Тик Аллаһта кодрәт барлыкны.

Үз дәүләтле әгәр булыйк дисәк,
Арканына аның тотыныйк.
Сораганга бирермен, дигән Ул,
Сорый-сорый сәждә без кылыйк.

Үткәннәрдән сабак, гыйбрәт алып,
Хата-гөнаһларны онытыйк.
Аллаһының ярлыкавын сорап,
Тәүбә итәргә дә онытмыйк!

Май, 2016 ел.

Әйләнештә...

Сулар ага, җилләр исә, чорлар үтә,
Бу дөньяда бар нәрсә дә әйләнештә.
Еллар буе җир әйләнә Кояш тирә,
Әйләнә ул тәүлек буе күләрендә.

Йолдызлар да һәрвакытта хәрәкәт тә,
Хәрәкәттә булган гына бәрәкәттә.
Буыннарны яңа буын алыштыра,
Үткән белән бүгенгене кавыштыра.

Кеше туа, җир-бишектә гомер итә,
Бәхилләшеп китәр чак та килеп җитә.
Ахирәттә аны кемнәр, ниләр көтә?
Шушы сорау аны гомер буе өтә.

Нигә китә? Китә микән ул озакка?
Нинди тәкъдир әзерләнгән асыл затка?
Нигә кеше әҗәл белән бәйләнештә?
Ә бит сулар, җилләр һаман әйләнештә.

Җилләр исә, сулар ага, чорлар үтә,
Мәңгелек җан безне ташлап кая китә?
Әллә инде берәүләрнең яралгысы
Әнисенең карынында хәят көтә?..

Сулар, җилләр чорлар кебек әйләнештә,
Кешеләр дә яши булыр бәйләнештә.
...Иртән нурлы кояш чыгар, кич ай калкыр,
Кояш белән Ай бар чакта дөнья балкыр!

Июль, 2015 ел.

Яшәү мәгънәсе

Ирешүдә Аллаһ рәхмәтенә
Асылында калсын вәҗданың.
Һәр эшеңдә, кылган гамәлеңдә
Сакта торсын намус мизаның.

Бисмиллалы изге ниятләрең
Хәят яме белән бизәлсен.
Чор-гасырлар хәер-дога кылып,
Искә алыр хикмәт иясен.

Март, 2017 ел.

Әҗәлгә бер сүз

Ничә тапкыр инде очрашсак та,
Үзара без таныш булсак та...
Син эшеңне төгәл башкарачак,
Гомер ахыры җиткән берчакта.

Дөнья шулай итеп яратылган,
Һәрбер килгән тиеш китәргә.
Фанилыкта яшәү мизгелләрен
Аллаһ кушканынча үтәргә.

Исән чакта кылган гамәлләрең
Лаек булсын данлы мактауга.
Гасырларны кичәр игелекнең
Бәрәкәтен күреп саклауга.

Яхшылык та, явызлык та бергә –
Янәшәдә бара тормышта.

Икесе дә һәр җан иясенең
Тормыш иярчене буллышта.

Җир-әнкәгә вәкил булып килгән
Кешеләргә акыл бирелгән
Вәсвәсәдә гөнаһ кылганнарга
Җәза каты булыр, диелгән.

Ике юлны сайлау хак-хокукын
Хак Тәгалә затка юнәлтә.
Бирәң хәләл, бирәң хәрам белән
Яшәештә булып көн итә.

Гомер үтә. Әҗәл килеп җитә,
Башкарырга теләп үз эшен.
Адәм заты диеп аталганның
Туктатырга йөрәк тибешен.

Әйе. Әҗәл иң куркыныч кодрәт,
Гәркемгә ул беркөн киләчәк.
Гәркем кылган эш-гамәле өчен
Аллаһыга җавап бирәчәк.

Гамәленә күрә сые булыр –
Тик буллмасын ул сый аяныч.
Сәждә китеп, гыйбадәтләр кылам,
Җәннәттә бул, Аллаһ – таяныч.

сентябрь, 2015 ел

Шәһри Болгар җирендә

I

Гәр тарафтан шәһри Болгарга
Бихисап кеше килгән.
Өйлә намазына басты
Намазны укый белгән.

Ак чалмалар, ак яулыклар,
Чайкала диңгез сыман.
Борынгы Болгар җиренә
Мәңгегә кайткан иман.

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр,
Лә иләәһә иллəллаһу
Үә Аллаһу әкбәр...
Субухәнә раббиль әгълә...
Сәҗдәдә шәһри Болгар.

Олы-кечесе намазда,
Кыйбла якка төбәлгән.
Гыйбадәтле калебләре
Аллаһыга юнәлгән.

Пакъ күңелдән, чын ихластан,
Гафу сорый Аллаһтан:
"Арала белеп һәм белми
Кылган, хата-гөнаһтан".

Рәхмәт-шәфкать, куәт сорап,
Аллаһыга баш ия.
Явыз залимнәрдән саклап,
Җәбраил канат җәя.

Ата-баба, болгар-татар...
Мең гасырлар тоташты.
Салават күпере булып,
Күңелләр күккә ашты.

Асылына кайта татар,
Нияте изгелектә.
Аллаһ кодрәтенә каршы
Булаллмый һични киртә.

Җир-күкләр нурга төренде,
Дөньялар балкып китте.
Татар җаны-тәне аша
Аллаһның нуры үтте.

Болгарны назлап, иркәләп,
Кояш нурларын сибә.
Хәтфәдәй яшел болыннар
Үрелеп биттән үбә.

Идел сулары өстендә
Җемелди кояш нуры.
Мәркәз Болгарны сәламләп,
Тирбәлә иген кыры.

Гыйбрәт алып, корбан чалып,
Халык тәүбәгә килә.
Мәңгелек хәрабәләрдән
Иман нуры бөркелә.

Әби-бабалар рухына
Намаз-дога укылды.
Әрвахлар милләтебезгә
Хәер-фатыйха кылды.

Изге Болгар туфрагыннан
Әмерле аваз иңде:
"Идел-йортны торгызыгыз!
Дәүләт тотыгыз!" диде.

II

Хан төрбәләре ягыннан
Ата-ана, уллары...
Җәмигъ мәчетенә таба
Бара торган юллары.

Әтисе татар, әнисе –
Чит милләт нәселеннән.
Уллларының җан газабы
Саркып чыга сүзеннән.

Әрнеп әйтә әнисенә:
"Руслар җирне корыта,
Кәсепләре – сугыш-суеш,
Кан коя, вата, сыта".

Маржа әни нидер әйтмәк...
Ләкин тотлыгып кала.
Улы: "Пестрый" явыннан соң.
Юкка чыга бу кала.

Меңләп гөнаһсыз болгарның
Киселгән газиз башы.
Әнә, чиркәү нигезендә,
Бабамның кабер ташы.

Шушымы рус "бөеклеге",
Шушымы "серле" булу?
Җаннар кыеп, каннар коеп,
Буллмый гаепсез калу".

Татар әти башын иеп,
Сыкранып тыңлап бара.
Болгар җирендә кукраеп,
Урыс чиркәве тора.

III

Заманында шәһри Болгар
Иң мәшһүр кала булган.
Ул мәгърифәт, мәдәният
Чулары чәчеп торган.

Болгарда беренче булып,
Тимер, чуен кайнаган.
Көрше чабата ургәндә –
Итек-читек каеган.

Куәте белән җиһанда
Шөһрәтле урын тоткан.
Иген урган, чуен койган...
Атмаган дуска уктан.

Халык ярыша-ярыша,
Сәүдә белән көн иткән.
Мал төягән кәрваннар
Мисырга барып җиткән.

"Су өстенә таш калыкса,
Калмык суга чумганда..."
Диеп ант эчкән көршеләр
Килә Идел-Чулманга.

Алар гаскәр белән килә,
Тупгелдер сәүдә өчен.
Сынамак булган көршеләр
Бөек Болгарның көчен...

Чит патшалар фәрман язып,
Җимертте бу шәһәрне.
Илбасарлар басып алды
Болгардагы су-җирне.

Вәхшилек шул хәлгә җитте:
Җир-суның яме китте.
Йәәҗҗ-мәҗҗ токымыннан
Болгар җәннәте бетте.

Мәшһүр шәһри Болгарның да
Юк инде гүзәл йөзе.
Анда бар дивар калдыгы,
Берничә йорт нигезе.

Күршеләр, урыс җире дип,
Саный Себер, Даланы.
Алтын Урда җиреннән дә
Юк итте бар каланы.

Илбасарлар авылларны
Утка якты, талады.
Бу шәһәрләр, бу авыллар
Хәтерләрдән югалды.

Үткәнен белмәгәннәрнең
Киләчәге юк, диләр.
Халкыбыз күргән газапны,
Күп татарлар белмиләр.

Алар катнаш гаилә корып,
Көлдерә үз-үзеннән.
Динен, үзен сатканнарның
Чуры китә йөзеннән.

Әби-баба әманәте
Мәсхәрәгә әйләнә.
Динсез, денсез сатлык татар
Кяфер кызгы өйләнә.

Йа Ходам, хәерең белән,
Татарыма бир акыл.
Болгарыма, Биләремә,
Милләтемә рәхмәт кыл.

IV

Йөзен кулы белән каплап,
Үкси татар бабасы.
Илбасарга бирер Ходай
Ике дөнья җәзасы.

16 июнь, 2008 ел

Фарыз булсын!

Коръәндә һәм хәдисләрдә,
Бер үк фикер, бер үк уйдыр:
«Бу дөньяда үзеңнән соң
Игелекле нәсел калдырыр».

Итагатьле, гыйбадәтле
Булсын дәвам варисларың,
Һич исеннән чыгармасын
Илаһи зат - Аллаһ барын!

Намус саклап, өмет аклап
Бу тормышны дәвам итсен.
Халыкларга үрнәк булып,
Милләтебез ерак китсен.

Шушы булыр бурыч үтәү -
Яшәештә гамәл җәплә,
Һәркем хыялында йөрткән -
Гасырларга хәтер төплә!

август, 2015 ел.

И, мөкатдәс туган телем!

Атлар кешни, этләр өрә, кошлар сайрый,
Барысы да үз телендә аралаша.
Сәер булыр – кошлар өрсә, эт кешнәсә,
Әгәр атлар кошлар күк сайрый башласа.

Тик татарда сәер хәлләр гаҗәп түгел,
Татар белән татар сөйли урысча гел.
Татар теле – дәүләт теле аталса да,
Татарның ул үги теле – бичара тел.

Меңъмең еллар ата-баба сөйләшкән тел
Кирәк түгел хәтта авыл баласына.
Әби-чәби, бабай-агай тел сындырып,
Русча дәшә нәсел булып каласына.

И, мокатдәс ана телем, газиз телем,
Коръән сүзле, әлифбалы милли идең...
Державаның сәясәт корбаны булдың...
Пыскып янган учакларга охшап калдың.

Ләкин атлар кошлар булып сайрамастыр,
Кошлар өрмәс, кешнәмәсләр һич этләр дә.
Тел – Аллаһның мәңгелек акыл бүләге,
Ул калачак милләтпәрвәр иңсәләрдә!

Кыямәттә Аллаһ безләргә эндәшер
Мөэмин-мөселман кавемнәре телендә.
Телен хурлап, үзен зурлап йөргән адәм
Курчак сыман телсез калыр суд көнендә.

август, 2013 ел

Аллаһ мәхәббәте

Барыбыз да – Аллаһыдан
Барысы да Аллаһтан.
Аллаһының мәхәббәте
Яшәешне яралткан.

Аллаһының мәхәббәте,
Рәхмәте һәм шәфкате...
Галәмдәге дөньяларның
Мәңгелек хәрәкәте.

Аның серле мәхәббәте –
Яшәешнең юлдашы.
Җир-күкләрдәге тормышның
Юл ахыры, юл башы.

Әй, татарым, шөкер итеп,
Чиксез рәхмәтләр әйтеп,
Яшик Аллаһ хозурында
Ислами гомер итеп.

Мәхәббәтенә таяныйк,
Арканына тотыныйк.
Мәрхәмәте кодрәтендә
Фарыз намазда торыйк!

Аллаһының игелекле
Мәхәббәтендә булыйк!

Аллаһү әкбәр

Аллаһ Тәгалә бердәнбер,
Аллаһү әкбәр.
Ул – Ғаләмнәрнең хуҗасы,
Аллаһү әкбәр.

Табынып Аны зурлыйбыз,
Аллаһү әкбәр.
Аңа бар мактауларыбыз,
Аллаһү әкбәр.

Дан-дәрәҗәсе олугтыр,
Аллаһү әкбәр.
Аның һич тә тиңе юктыр,
Аллаһү әкбәр.

Ул – яшәеш бирүче дә,
Аллаһү әкбәр.
Ул – нигъмәтләр бирүче дә,
Аллаһү әкбәр.

Теләкләрне багышлыйбыз,
Аллаһү әкбәр.
Ғөзерләребез юллыйбыз,
Аллаһү әкбәр.

Хак мөселман аңа бага,
Аллаһү әкбәр.
Иманлы кальбе сафлана,
Аллаһү әкбәр.

Рәхим-шәфкатен бирмештер,
Аллаһыңәкбәр.
Җәннәтләреңә ирештер,
Аллаһыңәкбәр.

июнь, 2016 ел.

Мөнәҗәт


Әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ
Тәүбә вә әтүбүиләйһи.
Ғаләмнәрнең тиңсез син хуҗасы,
Син бердәнбер заттыр, Илаһи.

Өмет итеп Үзең ризалыгың,
Чын күңелдән, ихлас иманнан.
Фарыз булган гамәлләрен үти –
Ғыйбадәттә мөэмин-мөселман.

Яшәешнең асыл мәгънәсе дә:
Аллаһыга тәкъва булудыр.
Аңа чиксез рәхмәтләрне әйтеп,
Биш вакытта намаз кылудыр.

Аллаһының кушканнарын үтә,
Дин-иманлы булсын дәвамчың.
Яшәешкә мәңгелек җан өргән
Затка булыр түләү бурычың.

апрель, 2017 ел.


بسم الله الرحمن الرحيم
حديث شريف
أدمنث ياخشراغي
كشيكه فايد الى بولغانى

II бүлек

Кеше һәм хәят

Кешегә мәдхия

Кеше – аң-акыл иясе,
Җирнең-күкнең бизәге.
Ул барлык сәнгатьләрнең дә
Иң сәнгати үрнәге.

Ул – моңлы җыр, сихри шигырь,
Гүзәлдән-гүзәл рәсем.
Сокланып туймас искиткеч
Мәгърур гәүдәле җисем.

Җан иясе, үсемлекнең
Сыйфатын алган туплап.
Ул – мәңге укылып бетмәс,
Бик тә тылсымлы китап.

Ул күк йөзе кебек серле –
Үзенә тартып тора.
Күк йөзе сыман үзгәреп,
Фасылда тормыш кора.

Кеше ул – төсләр балкышы,
Җир йөзендә ул тиңсез.
Күңеле Галәм шикелле, –
Үзе киң, үзе чиксез.

Шул чиксез күңел күгендә
Кояшы бар, ае бар.
Йолдызлар кебек җемелди
Йөзендә якты нурлар.

Кешенең дә тормышында
Төн була һәм таң ата.
Күк күкри, яшеннәр яшьни,
Ут-ялкыннар уйната.

Кеше дә табигать сыман
Давыллап, дулап ала.
Аның да табигать кебек
Сытык көннәре була.

Йолдызлы күңел күкләрен
Болытлар каплый кайчак.
Уеннан уйлмак чыкканда
Ачылмый кала кочак.

Ул горур, кайчак тәкәббер,
Хөсетле, комсыз, көнчел.
Хикмәт иясе асыл зат –
Нәфсенә хуҗа түгел.

Кайгы-хәсрәт, борчулар да –
Кешеләрнең юлдашы.
Җирдә яшәү өчен көрәш –
Гәр кешенең юл башы.

Кеше мәшһүр, ул асыл зат,
Үзе бик итагатьле.
Уй-фикерле, саф күңелле,
Миһербанлы, шәфкатьле.

Ул тәртипле, тәрбияле,
Үрнәк гореф-гадәтле.
Әдәп-әхлак, оят-намус
Халкына җитәр хәтле.

Җир-әнкәбез шикелле ул –
Рәхимле, күркәм, юмарт.
Җир-күкләр шикелле, ул да –
Могҗизага ия зат.

Аны мәхәббәтле итә
Ислаһи сөю хисе.
Җирне, күкне, бар мәхлукны
Яратуында көче.

Җирдә тормыш барсын өчен
Булган аның кирәге.
Ул бөтен тереклекнең дә
Илтифатлы терәге.

Кеше, җир-күкләр шикелле,
Изге гамәлләр кыла.
Яхшылыгы һәйкәл булып,
Фани дөньяга кала.

Кеше – җир-күкләр бизәге,
Ул сәнгатьләр црнәге.
Аллаһ сыйфатлары булган
Хак Тәгалә црнәге.

февраль, 2009 ел

Кеше – сәнгать әсәре

Баш – гәүдәнең баш өлеше,
Башта кешенең йөзе.
Башындагы уе әйтә
Ул нинди кеше үзе.

Баш буллмаса, ике колак,
Борын да буллмас иде.
Ике күз дә нурлар бөркеп,
Кояштай тормас иде.

Керфекләр сирпелмәс иде,
Кашлар сикермәс иде.
Затны акылдан яздыргыч
Сихри хис кермәс иде.

Тылсымлы алсу иреннәр,
Энҗе-мәрҗәндәй тешләр...
Мәхәббәт кебек татлы тел
Башның әйткәнен эшләр.

Баш – гәүдәнең баш өлеше,
Алтыны һәм көмеше.
Башта – әгъзалар дәрманы,
Аяк-куллар йөреше.

Башта аң-акыл буллмаса,
Кеше дә буллмас иде.
Җирдә могҗизалар төзеп,
Тормыш та кормас иде.

Кеше ул – сәнгать әсәре,
Мөкәммәл җан иясе.
Батыр да, матурлык та...
Җирдә юктыр тиңдәше.

Кеше – җир-күкләр бизәге,
Ул сәнгатьләр үрнәге.
Аллаһ сыйфатлары булган
Хак Тәгалә бүләге.

февраль, 2009 ел

Адәми зат – акыл иясе

Хак Тәгалә Пәйгамбәрләр аша
Кануннарын җиргә иңдергән.
Адәмнәргә шиксез үтәргә дип,
Изге гамәлләрне күндергән.

Бу тормышта дөрес яшәр өчен
Йөздән артык китап җибәргән.
Тыйганнарыннан тыелып яшәү
Адәмнәргә фарыз диелгән.

Китапларның китабы – Коръәндә
Ике дөнья ишек ачкычы.
Аллаһының тиңсез нуры иңгән
Ислам, иман, әхлак яктысы.

Ике дөнья нигъмәтләрен татыр
Әгәр кылса Адәм гыйбадәт.
Игелекле изге гамәлләре
Әверелер булып сәгадәт.

Шушы хаклы хакыйкатьне әйтеп,
Мең-мең томнар яза кешелек.
Яхшы белән яман көрәшендә
Җиңгән кебек була изгелек...

Ләкин чорлар үткән саен адәм
Изге китаплардан тайпыла.
Азгынлыкны матур киендереп,
Афәтләрдән буллмак котыла.

Халык әйтә: "Матурлык ул, – дия –
Туйда гына кирәк буллмышта.
Оят-намус, әдәп-әхлак көн дә
Ипи-тоз күк кирәк тормышта".

Ике икең дүрт икәнен белгән
Адәми зат – акыл иясе.
Иксез-чиксез Галәм хуҗасына
Аның булыр җавап бирәсе.

июнь, 2007 ел

Акылга мәдхия

Акыл – үй, фикер хәлфәсе,
Тормышны алар кора.
Үй, фикернең гамәлләрен
Аллаһ күзәтеп тора.

Акыл – камил төгәллектә
Җисемнәр әйләнеше.
Могҗизалы яшәештә
Җир-күкләр бәйләнеше.

Акыл кояш булып балкый,
Төнлә ай булып калка.
Нур булып таралган саен,
Хикмәте аның арта.

Акыл бар җирдә тереклек,
Ул – рухи, матди байлык.
Ике дөньяны бар иткән,
Безне бар иткән барлык.

Акыл – тиңе юк кодрәт ул,
Мәңгелек илаһи көч.
Аллаһ – Галәмнәр хуҗасы –
Алар бер зат, бер үк ич.

октябрь, 2009 ел

Акыл кергән

Азыкка тиңдәш булырдай
Юк бу дөньяда байлык.
Җан иясенең куәте
Азыкта, дия халык.

Дөнья яралганнан бирле
Сугыш, үтереш бара.
Адәм затлары байлыкны
Бүлешәләр үзара.

Берәвенә азык кирәк
Берәүгә алтын-көмеш.
Энҗе-мәрҗән, асылташлар...
Байлык, дәрәҗә, имеш.

Ялтыравык сихри төсләр
Тылсымлый кешеләрне.
Азгын нәфес ерткыч итә,
Акылсыз ишеләрне.

Кан коела, җан кыела
Матди байлык хакына.
Матди байлыксыз яшәү юк
Бу дөньяның халкына.

Матди байлык – нигез ташы,
Тормышның чишмә башы.
Тик рухи байлык күңелнең
Мәңгелек йөзек кашы.

Рухи байлык – җан азыгы,
Матди байлык тәннеке.
Җаныбыз да, тәнебез дә...
Без Хак Тәгаләнеке.

Дөньяда тормыш барсынга
Ике байлык та кирәк.
Исламның биш баганасы –
Ике байлыкка терәк.

Җиңүләр, нәфес тә мөһим,
Тормыш кануны – ярыш.
Үзара ярыш булмаса,
Дәвамсыз калыр тормыш.

Хак Тәгалә һәммәсен дә
Мул итеп безгә биргән.
Чамасын белеп тотарга
Адәмгә акыл кергән.

30 май, 2008 ел

Кем син?

Күрәчәк тә һәм язмыш та түгел,
Син аларга нахак сылама.
Бәхетсезлек, иза, бәла-каза
Тәүфикъсызга килеп сылана.

Эш сөймәгән ялкау хөрәсәннәр,
"Бүген үтсә, ярар", – дигәннәр,
Очын очка ялгый аллый яши
Язмышыннан куркып йөргәннәр.

Ялкау – фәкыйрь, тырышта – мул тормыш,
Хезмәтенә күрә хөрмәте.
Сау-сәламәт акыл иясенең
Табынында хәләл нигъмәте.

Һәркем лаек тормыш кормышына:
Үзе нинди – шундый тормышы.
Һәр гамәле өчен тик ул үзе,
Бары үзе җавап тотмышы.

Тәвәккәллек – ярты бәхет, диләр
Гайрәтле һәм кыю булганнар,
Чал тарихта кала исемнәре,
Үзләренә һәйкәл куйганнар.

Кем син? Аң-акылың, үй-фикерең,
Холкың күркәм асыл бер затмы?
Әллә асыл, затлы гүзәллекне
Бозып торган ямьсез бер тапмы?

Кем син? Бәхет-шатлык булсын өчен
Җанын фида кылыр кешеме?
Әллә кан-яшь, тормыш газапларын
Китергәннәр синең ишеме?

Бәхет – акча, асылташ та түгел,
(Алары да кирәк тормышта).
Бәхет – Җирнең һәр җан иясенә
Игелекле Кеше булмышта.

Хак Тәгалә безгә, бүләк итеп,
Әеп биргән малны, байлыкны.
Җан өргәнгә җүн бирә дигәндәй,
Өлеш иткән барча барлыкны.

Шатлык, бәхет, гомер озынлыгы
Тора диләр, синең үзеңнән.
Үзең туеп, күзең туймый калса,
Күмеп китә байлык түбәңнән.

апрель, 2007 ел

Бер карасаң...

Бер карасаң, кеше кодрәтле зат.
Ул – иҗатчы, гомер бирүче.
Ул мәшһүр фән, гыйлем иясе дә,
Бөтен һөнәрләрне белүче.

Юк кулыннан килмәгән һич эше,
Гәрнәрсәгә таба әмәлен.
Су өстендә, су астында йөзә,
Иярчене чиксез Галәмнең.

Аның кулы, аның аң-акылы
Җәннәт итә сахра-чүлләрне.
Җир йөзенә шәрә килгән Адәм
Мал-мөлкәткә күмә илләрне.

Хирыслыгы, аның үҗәтлеге,
Хыяллары, хисләр, теләкләр...
Ихтыяры, көче, уй-фикере –
Яшәү өчен бик тә кирәкләр.

Җир йөзендә кеше иң камил зат,
Гүзәллектә аңа җитәр юк.
Зирәклектә, белем, галимлектә,
Галилектә аңа тиңнәр юк.

Ләкин яши алмый ул Хуҗасыз,
Бер хуҗасы булган Алласыз.
Хак Тәгалә аның таянычы,
Таянычсыз – кулсыз-аяксыз.

Көч-куәтле шушы акыллы зат
Хак ярдәмгә мохтаҗ һәрвакыт.
Җир җимертеп йөргән шул олпатны
Бәреп ега микроб бервакыт.

Кеше көчсез, гаҗиз, кимчелекле,
Ихтыяҗлы һәрчак Аллаһка .
Акыллы зат, Аллаһ яратсынга,
Якын килми хата, гөнаһка.

Бирелмичә шайтан коткысына,
Котырынма, кешем, бул сабыр!
Сабыр иткән – морадына җиткән,
Морадына җиткән – Әл-Кадыйр.

апрель, 2007 ел

Аңла, Кеше!

Бу дөньяга мәшһүр бөекләр килгән,
Кешеләргә хикмәти гыйлем биргән.
Исемнәре чал тарихта дан алган,
Мәңгелектә акыл вә хәтер калган.

Җиһанда ут – дәһшәтле ирләр булган,
Үзләрен Аллаһка тиң итеп тоткан.
Барысы да туфракта юкка чыккан,
Дәүләтләрне, кавемнәрне җир йоткан.

Бу дөньяга кеше ни өчен килә?
Хакыйкатьне бер Аллаһ кына белә.
Кешеләрнең йөздән тик икесенә
Кирәк кадәр генә мәгълүмат иңә.

Тереклекнең бөтен максаты шунда:
Тәмле ашап тамагын туйдыруда.
Кемнәр хәләл, кемнәр хәрам юл белән
Тормышта рәхәт яшәү булдыруда.

Тамак йөртә җирдәге бар мәхлукны,
Мәхәббәт яшәтә җан-тереклекне.
Җир-әнкәбез – җәннәтнең күчермәсе,
Аллаһ Тәгалә биргән иреклекне.

Яшә сөеп-сөелеп бу дөньяда,
Гәр гамәлең китерсен җиргә файда.
Көнчелекнең, нәфеснең чамасын бел,
Белемеңне эшкә җик изге уйда.

Китәргә дип килә кеше дөньяга,
Бик кыска гомер бирелгән шул аңа.
Гасырларның исендә калыйм дисәң,
Гәр гамәлдә Иман кирәген аңла!

Уй-фикер

Уй-фикер күзгә күренми,
Аны тотып та буллмый.
Ләкин ул бар. Бәндәләрдә
Уй-фикер бетеп тормый.

Уй-фикерләр, тойгы-хисләр
Көне-төне эшендә.
Хәтта йоклаган чакта да
Кешеләрнең төшендә.

Кеше дөньядан китсә дә,
Уй-фикер җирдә кала.
Игелекле уй-фикерне
Киләчәк буын ала.

Ала кулъязмалар аша –
Ике дәвер тоташа.
Тоташа Җир белән Күкләр
Якты уй-фикер аша.

Уй-фикер, хис-тойгы Күкнең
Җиде катына менә.
Асыл уйлар, затлы хисләр
Күкләрдән җиргә иңә.

Изгелек – изгелек булып,
Үз иясенә кайта.
Изгелек, игелек – бертуган,
Алар тормыш яңарта.

февраль, 2007 ел

Акыл белән яшәргә

Гәркемнең бар үз тормышы,
Гәр агачның – җимеше.
Гәр чиләкнең үз капкачы,
Гәр өлешнең көмеше...

Гәркем үзенчә көн күрә,
Сәләт хәленә карап.
Акыл иясе булып та,
Гәркемгә буллмый ярап.

Кемгә кояш та ошамый,
Елмаеп балкыса да.
Кем якты айга да гашыйк,
Җылысы буллмаса да.

Кемнәр игелек кылудан
Җанына ләззәт ала.
Җан кыючы булып кемнәр,
Тарих битендә кала?!

Тегесе дә, монысы да
Дөньяда сынау үтә.
Аллаһ хөкеменә китә,
Кемнедер җәннәт көтә...

Алла безгә гомер биргән,
Тел ачкычы – дәшәргә.
Гәр эшнең чамасын белеп,
Акыл белән яшәргә.

Иң мөһиме

Масайсак та, акыл иясе дип,
Ғез – бер гади адәм баласы.
Ғәркем изге эш-гамәле белән
Кешелектә истә каласы.

Табигатьнең кануннары төпле:
Кеше туа, яши, картая.
Ғериш яфрак көзгә кадәр яшел,
Ғеришләре – язын саргая.

Ғезнең тормыш – күзне ачып йому –
Мәңгелекнең асыл мизгеле.
Ғерәү җәяү, берәү очып бара
Ғер үк түгел гомер тизлеге.

Тик финишка алдан, арттан булып
Мөһим түгел килеп җитүең.
Иң мөһиме – изге ният белән
Дөньялыкта гомер итүең.

Ике юл

Каян килә кеше, кая китә?
Кая бара кеше, ни өчен?
Китәр булгач, ник табына малга,
Калҗа йолкый, биреп җан көчен?

Кайта кеше Аллаһ хозурына,
Мәңгелеккә торып калырга.
Әмма оҗмах әһле булыр өчен
Ни-нәрсәләр кирәк алырга?

Изге гамәл, тик саваплы эшләр –
Ахирәттә шулар бик кирәк.
Башкаларның хакын талап җыйган
Хәрам маллар анда ник кирәк?

Азган байлык – азгын нәфес малы,
Череп юкка чыгар фани мал.
Ул байлыкның хуҗасына бәхет,
Шатлык китермәве ихтимал.

Азган малдан килә сугыш-талаш,
Кан-яшь кою, үлем хафасы.
Хәрам байлык бәрәкәтсез була –
Куанычтан күбрәк җәфасы.

Фанилыкта, булсын ахирәттә –
Байлык өчен җавап бирәсе,
Дөньялыкта алдап котылсаң да,
Анда пешми ялган "өйрәсе".

Иң төгәл һәм гадел бизмәннәрдә
Гамәлләрең синең үлчәнер.
Фәрештәме сиңа юлдаш булыр,
Газазиллмы әллә көчәнер?

Барысы да тик үзеңнән тора,
Кайсы затны юлдаш итәрсең...
Яхшы юлдан – оҗмах тарафына,
Яман юлдан – тәмуг китәрсең...

май, 2006 ел

Гомер юлы

Кешеләрне акыл ияләре диләр,
Җир йөзендә юктыр башка аңа тиңнәр.
Миллиардлаган кеше туа, яши, үлә,
Миллиард еллар исә җилләр, үсә гөлләр.

Миллиардлаган кеше туа, яши, үлә,
Әйтерсең лә, төркем-төркем көтү килә.
Еллар буе бер көтүдә йөргән мәхлук
Тик камчылы көтүбашны гына белә.

Миллиардлаган кеше туа, яши, үлә,
Кемдер – илнең падишаһы, кемдер колы.
Ил-җирләрне иңләп йөргән көтү – олы,
Дан-шөһрәтле тик акыллы затның юлы!

Бар да әйләнештә...

Барысы да Җирдә әйләнештә...
Төн артыннан балкып көн туа.
Яз килүгә, сабан тургайлары
Күк иленнән җиргә моң коя.

Барысы да Җирдә әйләнештә...
Фанилыкта сынау үтәбез.
Сабый булып Җиргә киләбез дә,
Мәңгелеккә Җирдән китәбез.

Барысы да Җирдә әйләнештә,
Безнең гомерләр дә, әлбәттә...
Дөньялыкта изге гамәл кылган –
Иншә Аллаһ, булыр җәннәттә.

Икмәк исе

Исләрнең дә бар очысы, бар төчесе,
Рәхәт бирми тик аларның һәрберсе.
Бар исләрнең иснәп туймас иң тәмлесе –
Алсуланып яңа пешкән икмәк исе.

Өмет итик

Ашар-эчәр ризык, җтәсе юл
Җан иясен йөртә җиһанда.
Җәһәннәмне җәннәт итә кеше
Мәхәббәт һәм акыл булганда.

Мәхәббәт һәм акыл көнкүрештә –
Пар канаты, диләр кешенең.
Бәхетле ул, әгәр ачкыч тапса
Күңеленә үзе ишенең.

Тик мәхәббәт, кояш кебек балкып,
Сихри хискә урый иркәсен.
Тик илаһи акыл мәхәббәткә
Белсен кайчан кодрәт бирәсен.

Өмет итик – акыл, мәхәббәтнең
Безнең белән янә туасын,
Сөю дигән могҗизалы хиснең
Ике дөньяда да буласын.

Өмет итик – гөнаһ, хаталарны
Хак Тәгалә гафу кыласын.
Өмет итик – газиз җанкайларның
Мәңгелектә бергә буласын...

Үз юлы белән

Ир заты далага китә,
Хатын кала калада.
Дала – кала тамырларда
Каныбыз булып ага.

Дала – рухи тәнебезнең
Күзәнәкләре саен.
Татар җаны-тәне белән
Ярата дала ягын.

Күңелебез шау чәчәкле
Болын, дала, кыр сыман.
Бәхет-шатлык, яшәү биреп,
Изгелек кыла торган.

Йөзебездә иман нуры
Хак Тәгаләдән иңгән.
Коръәнле булып яшәргә
Ходай фатиха биргән.

Татар борын заманнардан
Дин, мәгърифәт тараткан.
Аллаһ аны халыкларга
Илче итеп яралткан.

Далада да, калада да
Халкыбыз тормыш кора.
Кыр-даладан куәт алып,
Үз юлы белән бара.

октябрь, 2007 ел

Һәркемнең үз өлеше

Һай, катлаулы, серле соң бу дөнья!
Асылына булмый төшенеп.
Бер карасаң, нурлар бөркеп балкый,
Бер карасаң, кара төн кебек.

Әле генә йөзе көләч була,
Әле генә төсе үзгәрә.
Имезлеген җуйган сабый кебек,
Бер чарасыз кала бичара.

Нәфеснең дә йөзе ике яклы:
Гәр ягында кеше көн күрә.
Бер ишләре төзи, Җирне бизи,
Басу-кырда иген үстерә.

Алар хәләл хезмәт белән тапкан
Мөлкәтеннән күрә хәерне.
Намус, әдәп-әхлак кануннарын
Изге санап яши гомерне.

Бер ишләре байлык өчен яши,
Фанилыкта мәхшәр тормышы.
Кан-яшь коя, булганын да җуя,
Яшәү белән үлем тартышы.

Үзе туйса, күзе туймас нәфес
Кешеләргә хуҗа дөньяда.
Комсыз ишләр аның колы булыр,
Фанилыкта яшәү булганда.

Ике дөнья дилбегәсен тотып,
Гомер итә берәү ярашып.
Бер кешедә ике кеше яши –
Намус, нәфес яши ярышып.

Кешеләрне сынар өчен Аллаһ
Биргән ирек, нәфес, байлыкны.
Гәркемгә дә әҗеренә күрә
Әзерләгән оҗмах, тәмугны.

июнь, 2007 ел

Карыныннан ук...

Иртә уңмаган кич уңмый,
Уңмаган эш – юньбулмый.
Коры кашык авыз ерта,
Коры кулга йон кунмый.

Тишек тагарак су тотмый,
Тешсез тарак тарамый.
Кәкре киртә тәртәгә дә,
Бернигә дә ярамый.

Изге теләк белән башла
Эшнең зурын, кечесен.
Карыннан ук тәрбиялә
Җирнең яңа кешесен!.

июнь, 2006 ел

Җир ярасы

Һинд океанында котырынган цунамидан соң.

Күк күкрәде. Ут-ялкынлы яшен
Диңгез төбен сугып сындырды.
Тәя котсыз, төпсез кара упкын
Чал диңгезне эчкә суырды.

Җир-Ананың ярсып тетрәвеннән
Таеп китте хәтта күчәре.
Котырынып өскә ташып чыкты
Катламнарның шашкан егәре.

Кайнады Җир упкын казанында,
Йә җәелде, йә ул кысылды.
Көч-куәтен җыеп, дәһшәт белән
Томырылып өскә ыргылды.

Давыл купты. Дулкын өермәсе
Бөтерелеп чыкты ярларга.
Әйтерсең лә, Җирнең албастысы
Үз ишләрен тели барларга.

Тамырлары белән умырылып,
Ыңгырашып ауды урманнар.
Шашып калды, хата-гөнаһ кылып,
Аллаһыдан читтә булганнар.

Ябырылып җирнең ярасыннан,
Ватып-тетеп ташкын су баса.
Гәлакәткә дучар булыр кеше, –
Тәүбә итәренә соцласа.

декабрь, 2004 ел

Бөек сер

Чиге буллмас Галәмнәр бар икән,
Ай, кояш, йолдызлар бар икән, –
Бөтен булган шушы барлыкларны,
Байлыкларны кем соң бар иткән?

Дөньядагы тиңсез гүзәллекне,
Чиксез Галәмдәге төгәллекне,
Җир, су һава дигән бәрәкәтне,
Бәрәкәттә булган хәрәкәтне...

Кем булдырган икән, кем бар иткән? –
Искитәрлек ямьгә бизәгән,
Кем ямь тапкан шушы дөньяларны
Камиллеккә төреп бизәүдән?

Гәр үсемлек – үзгә сихри дөнья,
Күпме серләр аңа сеңгәндер.
Бер туфракта мең төрле гөл үсә,
Гәрберсе дә затлы, бердәнбер!

Төрле җан ияләрен бар иткән,
Җир өстенә сибеп тараткан.
Гәрберсенә хокук, өлеш биргән,
Яшәр өчен ризык яралткан.

Кеше дигән акыл, көч иясе –
Аллаһының сәнгать әсәре.
Сыйган аңа Галәм сыйфатлары,
Ул Җир-күкнең асыл гәүһәре.

Тик кешегә Аллаһ акыл биргән,
Күңеленә салган изге хис.
Акыл белән хисләр гүзәллеге
Бирә аңа гыйльми сихри төс.

Җирдә, күктә яшәү бар икән лә,
Илаһи зат аны бар иткән!
Аллаһ бар һәм шушы барлыкларны
Бар иткән Ул – бөек сер икән!!!

февраль, 2007 ел

Манзара

Йөз пәрдәсен кояш көлеп ача,
Офыкларның чите агара.
Үләннәрдә энҗе чыклар уйный,
Бар тарафта тормыш яңара.

Әллә каян гына назлар табып,
Таң җилләре үбә гөлләрне.
Аһ, иртәнге шушы тәүге нурлар
Сихерләми микән кемнәрне?!

Бу – яңа көн! Бар тереклек, әнә
Уяна да җиңен сызгана –
Көн туганда тамчысы да каллый
Үкенүләрнең гомер узганга!

Таң нурында оеп, иркәләнеп
Шөкерана кыла Җир-ана.
Яңа көнгә бер мин генә түгел,
Бар табигать шулай куана...

апрель, 2006

Баш иямен

Җир-әнкәнең бишегендә гомер кичәм,
Тормышның юл-сукмакларын урап үтәм.
Бу дөньяның шатлыгын да, кайгысын да
Аллаһының сынавы дип кабул итәм.

Гәр көнемне Аллаһыга рәхмәт әйтеп,
Каршы алам алсу таңны төннән көтеп.
"Сөбхәналлаһ, күз тимәсен", – инде диям.
Кояш белән Айның кавышканын күреп.

Ач булсам да, тук булсам да, кем булсам да,
Мин яшимен җир-күкләрнең тылсымында.
Бу дөньяны бер күрүе – үзе бәхет,
Әсәрләнеп... гөлгә карыйм һич югында.

Тезләнеп тә, йөз куеп та, Җирне үбәм,
"Мең-мең рәхмәт сиңа, газиз әнкәм", – диям.
Кеше итеп мине яралткан Аллаһка
Намаз укып, сәҗдә кылып башым иям.

Туганлык

Ғәрәмләрнең данынан – кан,
Ғәрәмләрнең тир ага.
Кан да, тир дә агызганны
Ғер ата-ана бага.

Дан белән кан, тир белән дан –
Икесе дә бертуган.
Кан белән тир уклмашканнан
Җирдә тормыш яралган.

Аллаһ кемне ир-ат итеп,
Хатын итеп яралткан.
Җаны да, каны да тарткан,
Үзенең парын тапкан.

Ғәркемнең нәсел-ыруы,
Үз милләте, халкы бар.
Ғердәмлек ул – күптөрлелек,
Күңелләр буллмасын тар.

Милли холык

Кыпчак-татар Иртыш-Дунай арасында
Алтын Урда, Идел йорт дәүләте корды.
Татар булып гомер итү җиңел түгел,
Ата-баба дошманнарга каршы торды.

Татар булып гомер итү – җиңел түгел,
Сынауларда чыныгадыр милли әһел.
Татар булу – дәрәҗәле, затлы булу,
Горурлыктан балкып торыр безнең күңел.

Татар булу – икеләтә авыр бүген,
Илсез калдык, телсез калып бара халык.
Иншә Аллаһ, ил табылыр, тел дә кайтыр!
Җаныбызда саклансын тик милли холык.

июль, 2011 ел

Җавап

"Аерылганны – аю, бүленгәнне бүре
Ашар", – дигән борынгылар, хак кисәтеп.
Гүн бабабыз: "Бердәм булыгыз!" дип әйткән,
Бердәмлекне тал чыбыгында күрсәтеп.

Бөек Кубрат балалары юл чыкканда,
Истә тоткан аксакаллар әйткән сүзне.
Өермәдәй ябырылган дошманнардан
Зарур булган саклап калу милли йөзне.

Без – Татар, Болгар, Балкар бүгенге көндә,
Өч туганның нәселләре яши җирдә.
Туганлыкның чыбыкларын бәйлик бергә,
Үтә аллмас арабыздан хәтта җил дә!

ноябрь, 2010 ел

Бер киңәш

Ғыел җәй коры килде, һай,
Игеннәрне сусатты.
Яфраклар да саргаешты,
Үләннәр җиргә ятты.

Кибегеп калды инешләр,
Чишмәләр моңсыз калды.
Кошлар томшыкларын ачты,
Илне шом билән алды.

Ә беркөнне бала-чага
Ғулганын кұмәк җыйнап,
Ғер-беренә су сибеште,
Ходайдан яңгыр сорап!

Могҗиза булды шул кичне:
Кұктә болыт куерды.
Ғала-чага уйнашкандай,
Чиләкләп яңгыр орды.

...Ғәйсезлек тә үзе киллмәс,
Әйтче, халкым, теләгең!
Хак Тәгалә: «Ғирермен, – ди, –
Сорасыннар кирәген!»

Юл башы, юл азагы

Ата улны, ана кызны белми,
Җәмгыятькә менде азгынлык.
Алдау-талау, золым, ялган-яман...
Явыз булу – уңган-булганлык.

Яратышу, сөю, мәхәббәткә
Зиначылык килде аллашка.
Хәзер яшьләр җенси сынау үтеп,
"Яраклашып" керә тормышка.

Никахлашкан хәләл җефетләр дә
Яшәмиләр җаны хаҗәткә.
Килешүләр төзи, әйтерсең лә,
Тәнен бирә чикләп әҗәткә.

Оят-намус, сафлык, итагатьлек,
Әдәп-әхлак, тәртип-тәрбия...
Купшы сүзләр хиссез-төссезләргә,
Азганнарга түгел дирбия.

Халык сәрхүш, илдә фахишәлек,
Кая бара денсез кешелек?
Баткаклыктан чыгар әмәл бармы?
Бетәрме бу яман вәхшилек?

Кайда иман, күркәм изге гамәл,
Күктән иңгән ислам әхлагы?
Аллаһының кануннарын үтәр
Үз кыйбласы, дини мәсләге?

Кеше булып мәңге яратылмыш,
Тик юл башы, түгел азагы...
Фанилыкта кылган гөнаһларның
Кыямәттә булыр газабы!

февраль, 2005 ел

Өммәт

"Асыл булса да – карта,
Үз нәселенә тарта".
(Мәкаль)

Картамы ул, башкамы ул –
Җан иясе әгъзасы.
Тәндәге һәр әгъзаның да
Хак Тәгалә хуҗасы.

Ислам дине, өммәте дә
Төрле әгъзадан тора:
Сөнниләр бар, шигыйлар бар,
Суфыйлар тормыш кора.

Кеше тәнендәге кебек
Өммәттә дә бар юллар.
Ханәфи, маликн һәм дә
Ханбәли, шафигыйлар.

Бу мәзһәбләр һәммәсе дә
Ислам диненә илтә.
Изге Коръәнле һәр кавем,
Динне бербөтен итә.

Берәр әгъза чирләп китсә,
Бөтен бер тән хасталый.
Мөэмин-мөселман өммәтен
Канлы ызгышлар талый.

Кечкенәме, зурмы ул чир –
Әгъзалар зыян күрә.
Үй-фикергә, дин-өммәткә
Шайтан коткысы керә.

Чир – сырхауларның табибы,
Дин – иманлы җәмгыять.
Аллаһ кануннарын үти
Тик ислами шәригать.

октябрь, 2007 ел

Дисәк тә...

Дөнья чуар, төрлесе бар,
Бар яхшысы, яманы.
Кайберәүләр гомер буе
Белми яши чаманы.

Дөнья һәрчак хәрәкәттә,
Хәлләр үзгәреп тора.
Яшәештә көрәш бара,
Тормышны сүтә-кора.

Дөнья ямьле, ул сөйкемле –
Тылсымы күзне буа.
Адәм заты үлә-бетә
Дөнья артыннан куа.

Ә ул – вәсвәсәле шайтан,
Кызыктыра, котырта.
Җиде үлчәп кисмәгәнне
Төп башына утырта.

Кеше хакы, хәрам ризык –
Тыелган аш дисәк тә...
Гөнаһны кыла торабыз
Язуклыгын белсәк тә.

Тик терсәкне тешләп буллый
Мең үлеп терелсәк тә.

октябрь, 2013 ел

Җәза

Аллаһ Күкнең нурлы гарешеннән
Исе китеп Җирне күзәтә.
Татар иле ваем-мәшәкатьтә:
Бәрәң – вата, берәү – төзәтә.

Бәрәңләре, тырыш кырмыскадай,
Иртән торып эшкә керешкән.
Мөселманның биш фаразын үти,
Каллас өчен бакый өлештән.

Әнә берәү, юха елан сыман,
Бөтерелә тирә алдында.
Ләббәйкә дип, табан асты ялый,
Эш-гамәле "шеф"ның җаенда.

Улы – кияү, кызы – килен булып
Чит-ят белән никах бүлешә.
Милләтенең нәсел орлыкларын
Тәре такканнарга өләшә.

Ә берәүләр сугыш-үтерештә
Урлап, талап хәрам мал җыя.
Үзе туйса, комсыз күзе туймый,
Бәндәләрне суя, җан кыя.

Чиркәүләрдә сынга табыналар,
Мәчетләрдә – табыш бүлешү.
Гәр тарафта зина-фахишәлек,
Монафикълы тормыш сөрешү.

Аллаһының туземлеге бетте:
Ут-яшенле давыл, җил купты.
Денсезләрне мал-мөлкәте белән
Цунамилы диңгез, Җир йотты.

май, 2014 ел

Нәсихәт

Яраткан бәндәсен Аллаһ
Гөнаһтан тыеп тора.
Тәкъва затлар Ул кушканча
Иманлы тормыш кора.

Начар уйдан, эш-гамәлдән
Хак Тәгалә кисәтә.
Тормышның бу дөнья белән
Бетмәгәнен искәртә.

Азгын гамәлләре өчен
Тәмуг җәзасы ала.
Нәфесен тыя алмаган
Хур-мәсхәрәгә кала!

Әй татарым, Аллаһ сиңа
Акыл, мәшһүр тел биргән.
Күктәге ай, кояш кебек
Җирдә нурлар чәч, дигән.

Сиңа бер сүз

Пәри башка, җен башка дип әйтсәләр дә,
Пәри, җеннәр – Иблис токымы.
"Брат братның көтү көткәненә рад", – дип,
Кисәтәдер әби-бабайлар акылы.

Кемдер сине Аллаһының рәхмәтеннән,
Җәннәттәге нигъмәтеннән бит аермак.
Аңа кирәк синең газап чигүләрең,
Җәһәннәмдә телидер сине калдырмак.

Акылыңны җыеп, төптән уйлап кара,
Я нәшәңдә кемнәр синең белән бара?
Иманлымы, Коръәнлеме ул иптәшең,
Әллә синең Иблис белән якын ара?

май, 2010 ел

Хакыйкать

Хак Тәгалә әгәр буллмаган исәптә,
Уйлап табар идек Аны, күп йөрсәк тә.
Туган көннән алып, үлгән көнгә кадәр
Аллаһ яши җан-рух булып һәр йөрәктә.

Тереклеккә ут-су, сулар һава биреп,
Җир-ананы затлы нигъмәтләргә төреп;
Мәхлуклары дөрес яшәсеннәр өчен,
Хак кануннар, тәгълиматлар тора биреп.

Адәм заты җиргә килгән көннән башлап,
Ташны чукып, тузны ертып канун яза.
Акылга сай, тормышка җай түгелләре
Заман белән бергә уза, бергә туза.

Каракның да – бар гадәте, бар кануны,
Кайберләрен акылсызлар яза аны.
Өч тиенгә тормас андый кануннарның
Яшәр өчен, эшләр өчен юктыр җаны.

Дөньяларны юктан бар иткән Аллаһның
Тәгълиматы ике яклы: фәнни-дини.
Шәригатькә хәләл белән хәрам гамәл
Инсаннарның барлык хокукларын били.

Җирнең, күкнең, яшәешнең сихри серен
Хак Тәгалә киләчәк өчен яшергән.
Һәр чор өчен изге китаплары аша
Үзе кебек, мәңгелек канун иңдергән.

Хәдисләрдә, Изге Коръән-Кәримендә,
Адәменә белем-гыйлем, акыл биргән.
Тереклекнең тәкъдир-язмышын сер итеп,
Тик үзе белер мәңгелеккә яшергән.

Мин һман булып килгән адәм тыпырчына,
Галәмнәргә менәргә ул ният кора.
Аллаһысын югалткан динсез кешелек
Һәлакәтле чоңгыллар алдында тора...

май, 2010 ел

Ике көч

Бу дөньяда иң кодрәтле ике көч бар:
Аның берсе – тиңе буллмас Хак Тәгалә.
Галәмнәрне бар итүче, Ул – җитәкче,
Ни булганын, ни буласын тик Ул белә.

Икенче көч: ул – изге хис, ул – мәхәббәт,
Аллаһ биргән иң кадерле татлы нигъмәт.
Тапкан Ана, Ватан-Ана читтә кала,
Мәңгүн гашыйк өчен чөнки сөю кыйммәт.

Тик илаһи мәхәббәтнең бар төрлесе:
Бар Ватанга, бар ир-хатын мәхәббәте.
Ләкин тиңсез, һич кенә дә хыянәтсез
Аналарның балаларга мәхәббәте.

сентябрь, 2010 ел

Аллаһ һәм Коръән

Әйт, Кешелек! Дөнья яралганнан бирле,
Булды микән ил-җирләрдә минем ише?
Алтмыш дүрттә акыл белән хискә төреп,
Ел саен бер китап язган әдип кеше?

Хак Тәгалә илаһи көч, кодрәт белән,
Мин-фәкыйрен дүрт үлемнән алып калды.
"Яз" дип, минем кулларыма каләм бирде,
Күңелемә үй-фикерен тезеп салды.

Язганнарым вәхи булып иңде күктән,
Китап булып таралдылар инде күптән.
Изге Коръән ачты миңа үз серләрен,
Хак Тәгалә мәгълүм итте кайберләрен.

Тереклеккә Аллаһ сүзе һәрчак кирәк,
Дөньялыкта изге Коръән безгә терәк.
Аллаһ сүзен, Коръән сүзен канун итеп,
Яшәүчегә: Аллаһ – акыл, Коръән – йөрәк.

декабрь, 2010 ел

Тәүфыйк бирче...

Аеклар олы яшьтә дә
Тормыштан ләззәт ала.
Хәмер эчкән ир-егетләр,
Бөрешеп, шиңеп кала.

Ни Аллага, ни муллага,
Ни хатын, ни балага...
Әти-әни, бар туганнар
Тап булалар бәлагә.

Йа Раббым, үзең яраткан
Бәндәңә бирче тәүфыйк.
Фани дөньяның рәхәтен
Хәмерсез яшәп татыйк.

май, 2009 ел

Парлы-парлы

Бу дөньяда утсыз, сусыз яшәп буллмый,
Сулар да бит ут өстендә генә кайный.
Адаштырып, туры юлдан яздыручы
Шайтанны да Хак Тәгалә кирәк саный.

Чын дөреслек тик бәхәстә туган кебек,
Гәркем көрәш, тартышлар аша чыныга.
Утта янмас, судан коры чыкканнарның
Үй-фикере, хыяллары аша чынга.

Теге дөнья әкияттәй мактaлса да,
Кеше кеше булып яши фәкать монда.
Дөньялыкта файдалы мирас калдырсаң,
Яшәвеңнең мәгънәсе дә булыр шунда.

Хакыйкатьтә – кеше тәмуг кисәведер,
Меңнән берәү, бәлкем, җәннәткә дә керер.
Хайван кебек ашап-эчеп тик ятудан,
Эшсезлектә ирексездән газап күрер.

Ул җәннәттә хөсетлек, нәфселек буллмас...
Буллмас анда азгынлык та, явызлык та.
Димәк, анда яхшы-яман көрәше юк,
Димәк, кеше торып кала ялгызлыкта.

Үзарада тартыш юкта – тормыш та юк,
Яшәешнең асылы бит – бил аллмышта.
Аллаһы да бу тәртипне канун итеп,
Иблисне бит көндәш иткән бу тормышта.

Табигатьтә һәрнәрсә дә парлы-парлы,
Парлы булган җирдә генә тормыш бара.
Җәннәт белән тәмугны аллмашып тору –
Яхшы-яман арасыдай якын ара...

июнь, 2010 ел

Һәркемнең үз урыны

Коръән белән гамәл кылган хак мөселман
Хәләл хезмәт белән тормышын кормакта.
Аллаһ хакын, ятим хакын хаклаганның
Инша Аллаһ – урыны булыр оҗмахта.

Нәфесенә хуҗа буллмаган адәмнәр
Дөньялыкта җәннәттә кебек буллмакта.
Мал табуда ислам динен кәсеп итеп,
Бидгать гамәл кылганнар булыр сул якта.

июнь, 2010 ел

Дәлил

Бу дөньяга җанлы булып туган кеше
Гөнаһ кыллмый, фәрештәдәй яши аллмый.
Фани тормыш – яхшымы ул, начармы ул –
Хак Тәгалә аны шулай кирәк саный.

Җан иясе яшәр өчен Җиргә туа,
Бер-берләрен ише итеп дөнья куа.
Бөрчак цлә, череп бетеп туффрак була,
Үсемлекләр Җир-анадан азык ала.

Мең-мең еллар тормыш шулай дәвам итә:
Бөрәцләре килә, берәцләре китә.
Тик дөньяның серле-сихри гүзәллеге
Бер күрүдә затны цзенә әсир итә.

Акыл җитмәс иксез-чиксез Галәмнәрдә,
Көч-куәттә Аллаһыга тиңнәр юктыр.
Миллионлаган җан иясенең яшәве –
Аллаһының барлыгына дәлил-хактыр.

июнь, 2010 ел

Нигә?
(Табышмак)

Тамчы-тамчы булып яңгыр ява,
Бөртек-бөртек булып кар ява.
Тамчы-тамчы, бөртек-бөртек итеп,
Кем аларны ясый һавада?

Нигә яңгыр күктән ташып акмый?
Нигә яумый кар да кисәкләп?
Нигә болыт үзе җиргә төшми?
Аңлатыгыз әле исәпләп...

гыйнвар, 2010 ел

Беләсеңме?

Кояш яктырта, җылыта,
Төнгә айны калкыта.
Җир-анабыз мул табынын
Нигъмәт белән балкыта.

Кем җайлаган җир, кояшны
Тормышка уңай итеп,
Кояшның сихри нурлары
Торсынга җиргә җитеп?

Кояштагы ут-ялкынга,
Йолдызларга кем хуҗа?
Җирдәге илаһи тормыш –
Акыл җитмәс могҗиза!

Әй, кеше! Җир-күккә карап,
Гыйбрәтләр аласыңмы?
Бөләсеңме Аллаһыга
Җавапсыз калмасыңны?!

Якты кояш һәм Җир-ана
Тереклекне яшәтә.
Тормышны туктатыр өчен
Аллаһка мизгел җитә.

май, 2009 ел

Гөнаһлы уен

Римның изге синодында
Сәер утырыш бара.
Католик руханилары
Киңәш тота цзара.

"Хатын-кыз кешеме, юкмы?"
Бәхәс ут кебек кыза.
Бер тавыш өстенлек белән
"Кеше!" дигән сүз уза.

Югары Аллаһ хатын-кызны
Кеше итеп яралта.
Ул тапкан-баккан затларны
Җир йөзенә тарата.

Хак Тәгалә хатын-кызны
Илаһи итеп күрә.
Урынны да тыр башыннан –
Үзе яныннан бирә.

Тик балчыктан яралганнар
Хакыйкатьтә саташа.
Кабыргадан яралганга
Шик белдереп маташа.

Шул диндәге денсез затлар
Үзләрен хаклы саный.
Хатын-кызны курчак итеп,
Гөнаһлы уен уйный.

Кемне кем итеп ярату –
Анысы Ходай эше.
Үз анасын үз итмәгән
Була аламы кеше?

гыйнвар, 2009 ел

Бу дөньяның кеме юк

Ышану да, ышанмау да –
Гәркемнең тик үз эше.
Ышанганның өмете бар,
Ышанмаган – буш кеше.

Хак Тәгаләгә ышанган
Яхшыга өмет итә.
Өмет яшәтә кешене,
Тормышын алга илтә.

Табигатьнең үз кануны:
Җай белән бара тормыш.
Ышанган, ышанмаган да
Дөньяда сынау үзмыш.

Фәкыйрьлек тә, мал-мөлкәт тә
Адәм баласын сыный.
Тик иманы нык булганнар
Тормышта кала, сынмый.

Яшәүнең мәгънәсен белү
Гәркемгә бирелмәгән.
Иблис, акыллы булса да,
Җәннәткә кераллмаган.

Гәр кеше – бердәнбер данә,
Бу дөньяның кеме юк.
Уйласаң хәйран каласың,
Могҗизаның чиге юк.

Бериш кеше динен сата,
Бирише телен сата.
Фахишә дә товар итеп,
Үз тәнен сатып ята.

Товарлыклы сатлык җаннар
Шалкан бәясе торыр.
Алтын-көмешкә төрсәң дә,
Сатлык тамгасы калыр.

март, 2010 ел

Көтә

Кечкенә генә орлыкка
Аллаһ кодрәтен сала.
Дөньядагы цивилизацияләр
Орлыктан бит ярала.

Шул орлык җир-анабыздан
Көч-куәт алып үрә.
Җылыны, яңгыр, яктыны
Илаһи Аллаһ бирә.

Орлыклар бер үк туфракта,
Бер үк шартларда үсә.
Берсе камыл буе кадәр,
Берсе күкләргә аша.

Һәрберсенең үз төсе бар,
Үз гадәте, үз холкы.
Яшәү өчен азык ала
Орлыктан дөнья халкы.

Җан иясе дә орлыктан
Яралып гомер итә.
Олысын да, кечесен дә,
Мәңге яшәр җан йөртә.

Орлык белән мәңгелек җан
Тереклекнең дәвамы.
Изге җанны Аллаһының
Көтә оҗмах заманы.

Гәр тереклек яратылган
Нәсел калдыру өчен.
Аллаһка зекер итәргә,
Яшәүдә биреп көчен.

май, 2009 ел

Ахыры ничек бетәр?!

Дөньяның яшерен серен
Мөмкин тугелдер белү...
Кавемнәрне һәлак иткән
Тыелган җиргә керү.

Безгә кадәрле өммәтләр
Гыйбрәт алмаган һаман.
Тереклек кырылып беткән,
Башланган яңа заман.

Хәзерге денсез галимнәр
Галәм өчен көрәшә.
Ач күздәй күктәге айны,
Йолдызларны бүлешә.

Акылсызлык бәласенең
Ахыры ничек бетәр?..
Кешенең туймас нәфесе
Башына микән җитәр?!

май, 2009 ел

Тормыш

Җир-туфракка ни чәчсәң – шуны урасың,
Чәчми калсаң – фәкыйрьлектә ач торасың.

Күктә болыт йөзсен өчен җилләр исә,
Үсемлекләр шул ышыкта шытып үсә.

Җан ияләр ләкин искән җилдән тумый,
Укымаса, адәм заты галим буллмый.

Уйсулыкта тамчылардан күл җыела,
Тау-ташлар да бөртекләрдән хасил була.

Һәр эш-гамәл теләк-максатка яраша,
Үтсә алар бисмиллалы күңел аша!

Берәү изге ният белән эшен башлый,
Күкләр аңа хәер-фатыйха багышлый.

Берәү фани бу дөньяны кочмак була,
Урлый-талый, канлы-хәрам мөлкәт җыя.

Әйтерсең, ул мәңге яшәр өчен туган,
Әлмә ата-бабалары туфрак булган.

Черегәннең янә терелгәне юктыр,
Тик рәвешен алышуы гына хактыр.

Аллаһының кануннары хилаф кылмый,
Бернәрсә дә юктан бар – бардан юк буллмый.

Шушы хакыйкатьне аңлар вакыт җитәр,
Кеше заты Җир-ананы оҗмах итәр.

июль, 2010 ел

Заман фаҗигасе

Каршылыклар ерып тормыш алга бара,
Мең еллар да, миллионнар да тугел ара.
Явызлыкка, азгынлыкка, залимлеккә –
Тик цемдер әхлакый һәм гадел чара.

Замананың диннән язган һаруннары
Хәрам ашый, хәрам эчә, хәрам коча.
Алдап-талап кан коеп җыйган маллары
Уңга-сулга исраф булып җилгә оча.

Хайваннар да тамактан артканын аллый,
Кешеләрдән һичнәрсә дә артып каллый.
Дөнья малын урлый, җирне йолкый-талый,
Ә ул цзен фәрештәдәй итеп саный.

Нәфесенә кереп баткан һәрбер җаһил
Олы юлда балта-пычак тотып тора.
Аналарның, сабыйларның өлешеннән
Җирдә мәңге яшәр булып "тормыш кора".

Шайтаннарның коткысына кыткылдаучы
Комагайлар изге гамәл кылып йөрми.
Черер малга иманнарын сатканнарны
Туры юлга Хак Тәгалә һич кцндерми.

Бу дөньяда миллионлаган гөнаһ җыеп,
Имансызлар бакыйлыкка китеп бара.
Тәмуг кисәцләре булган денсезләрнең
Җәһәннәмдә чырайлары булыр кара.

Җир йөзеннән тереклекне юк итәрдәй,
Корал ясый, корал коя кеше һаман.
Коръән әйткән: "Кыя-таулар болытлардай,
Күктә очып йөрер заман җитә" сыман.

май, 2010 ел

Уенчык

Дөньядагы һәр тереклек, һәр мәхлук та –
Тик уенчык илаһи язмыш кулында.
Гәрбер гомер белән язмыш уйнап туйгач,
Тарих булып кала алар ил кырында.

Күкләр өчен Җир-ана да тик уенчык,
Сынау өтә анда кеше дигән орчык.
Әй, әйләнә – яшәү өчен бөтерелә!..
Төмуг газапларын узгач – өтерелә...

май, 2010 ел

Безнең хәят

Бу дөньяга миллиардлаган кеше килә,
Бик азлары дөрес итеп яши белә.
Ваемсызлар ашый-эчә, уйный-көлә,
Җир йөзенә ник килгәнен белми үлә.

Җир әйләнә һәрчак кояш тирәсендә,
Ай да калка караңгы төн өлкәсендә.
Сихри-тылсымлы йолдызлар сокландырып,
Җемелдиләр Ғаләмнәрнең җилкәсендә.

Җан ияләр: кош-корт, бөҗәк, ат-дөяләр,
Җәнлек-җанвар, биниһая су дөньясы...
Җиһандагы барлык тереклек иясен
Һазлап-иркәләп уята Күк кояшы.

Шаян җилләр тәрәз кага, йокы кача,
Караңгылык, керфек сирпеп, күзен ача.
Кем йөгерә, кемдер йөзә, кемдер оча,
Ғал кортлары чәчәкләрне назлап коча.

Ғаләмнәрне, җир-күкләрне, утны-суны...
Тереклекне җан-рух өреп, Ул бар иткән.
Дөньядагы булган бөтен барлыкларны
Хак Тәгалә Адәменә бүләк иткән.

Кунак ашы – кара-каршы булу күркәм,
Шул гадәттә ата-бабай гомер иткән.
Хак Тәгалә ризалыгы өчен диеп,
Таңнан торып намазына баскан иртән.

апрель, 2010 ел

Ахырзаман

Дөнья беткән икән, имеш,
Җир өсте тулы мәет.
Ерткычтай әшнә-дусларын
Төшендә күрде Зәет.

Исрафил сур өрде, шулчак
Ғарча мәет терелде.
"Мөселман булабыз" диеп,
Аллаһ каршына килде.

Кеше канын койганнарны
Аллаһ гафу кылмады.
Җир-ана да мөртәтләрне
Куенына алмады.

...”Шушы хәшәрәт комсызлар
Аяусыз талый мине.
Балаларым, диеп ничек
Атыйм денсез кавемне?”

Сыкранып әйтте Җир-ана,
Күкләр яшен уйнатты.
Хәшәрәтләрне шайтаннар
Тәмуг утына атты.

Җәзадан качмак Зәетне
Сабыйлар хакы тотты.
Хәрам мал-мөлкәте белән
Һәфесе кабып йотты.

декабрь, 2012 ел

Бердәнбер

Шаккатамын күреп чәчәкләрнең
Аллы-гөлле сихри төсләрен.
Тылсымланып һуш-акылдан язам
Иснимен дә хушбуй исләрен.

Чәчәк тажы – могҗизалар язы,
Акыл җитми моны аңларга.
Яфракларның бизәкләре серен
Тик Аллаһтан мөмкин табарга.

Чәчәк тажы, яфрак... Чиксез галәм –
Тик Аллаһның акыл хикмәте.
Чәчәк тажы, яфрак, галәмнәр дә
Акыл иясенең кодрәте.

Һәр цсемлек, һәрбер күзәнәккә
Хак Тәгалә яшәү иңдерә.
Тереклеккә сый-хөрмәтен биреп,
Яшәешкә нигъмәт күндерә.

Бу дөньяның барлык нигъмәтләре
Үсеп чыга адәм-балчыктан.
Кешенең дә яшәү мәңгелеге –
Җир һәм күкләр белән тоташкан.

Җир-күкләрне юктан бар итүче
Хак Тәгалә бар һәм бердәнбер.
Ул – мәңгелек нурлы балкыш булган,
Акыл җитмәс гүзәл бөек сер.

август, 2014 ел

Бер кебек

Икесе дә алар илаһидыр,
Икесе дә тормыш куәсе.
Икенә дә бердәй табынабыз –
Алар безнең тормыш иясе.

Икесе дә алар көч-куәтле,
Дөньяларны юктан бар итә.
Җир-күкләрдә тормыш, яшәешне
Кануннары белән беркетә.

Бар тереклек яши парлы-парлы,
Парлылыкта сере яшәүнең.
Тик һәркемнең тәкъдир-бизмәне бар,
Бер чиге бар ләкин үлчәүнең.

Тик Аллаһның башы-ахыры юк,
Мәхәббәт тә шулай мәңгелек.
Икенең дә бер үк сыйфатлары –
Икесе дә алар бер кебек.

февраль, 2013 ел

Кардәшкә эндәшү

Күкне – ата, Җирне – ана, диләр,
Шөкер, бар үз ата-анабыз.
Җирдән-күктән, эти һәм әнидән
Бу дөньяда яшәү алабыз.

Әби-бабам, мең-мең еллар буе
Милли рухын чарлап яңарткан.
Татар булып мәңге яшәешен
Ислам дине белән ныгыткан.

Аллаһ сүзе безнең телгә күчкән,
Гореф-гадәт моңга әйләнгән.
Изге диннең асыл сыйфатлары
Тормышыбыз белән бәйләнгән.

Акыл ала халкым үткәненнән,
Коръән төпкеленнән – хикмәтне.
Ата-баба, эти-әниләргә,
Динебезгә булыйк рәхмәтле.

Ә син, кардәш, күзең карасыдай
Саклыйсыңмы халкың мирасын?
Җир-күкләрнең, әти-әниләрнең
Әманәтле изге догасын?!

сентябрь, 2013 ел

Риваять

Хаин татар, толерантлыкка сыенып,
Үз нәфесе комсызлыгын өскә куяр.
Халкын сатып, телен-динен, үзен сатып,
Хәрамләшер, сабыйларның яшен кояр.

Телсез калган, динсез калган татарларның
Урыс телле оныклары тәре үбәр.
Милләтенә хыянәтче денсезләргә
Кыямәттә җавап тотар вакыт җитәр.

Җавап бирер сатлык җаны, фәхеш тәне
Хак Тәгалә, ата-бабасы каршында.
Юксынудан нәсел-нәсәпләре елар
Табаллмагач үзен оҗмах бакчасында.

август, 2013 ел

Чорнап ала язмыш

Көзге сары яфракларны куып,
Җилләр уйный, ясап туңгәрәк.
Ботагыннан аерылган яфрак –
Илсез-җирсез калган күбәләк!

Кешене дә язмыш чорнап ала,
Чужа куа тормыш юлыннан.
Кемне җилләр, кемне михнәт куа –
Фани дөнья шулай корылган.

ноябрь, 2011 ел

Каһәрле кавем

Гәр кавемдә яхшысы бар, яманы бар,
Бар имансыз монафикъ һәм кяфер кавем.
Аллаһның хак ислам динен инкарь иткәч,
Киллмешәккә калды алар, җуеп илен.

Тәкәббер һәм денсез булган бу кавемгә
Бер-бер артлы пәйгамбәрләр җибәрелде.
Кадакланган Гайсә пәйгамбәр тәрегә,
Залимнәрнең тәхете дә җимерелде.

Җир йөзенә таралышкан шушы кавем
Дәүләтләрне бер-берсенә каршы куя.
Дөньядагы халыкларның канын коя,
Ил-җирләрнең байлыкларын җыя-җыя.

Кан-яшь сеңгән, хәрам кергән мал-мөлкәтнең
Игелеген күргәне юк һичбер кавем.
Иблис белән алар Аллаһ каһәрендә...
Адәмнәргә мәхшәр ясап яши бүген.

декабрь, 2011 ел

Могҗиза

Дөньяның бер кыйтгасында
Могҗиза оран салды:
АКШның дәүләт тәхетен
Обама яулап алды.

Чегр ил башы булганда
Ак йорт ни төскә керер?
Мөселман булган католик
Кайсы дин юлын йөрер?

Сэм агай кебек дөньяның
Җан җиреннән алырмы?
Хөрлек символы булырмы?
Зәңги булып калырмы?

декабрь, 2008 ел

Мөселманнар, берләшегез!

Мөселманнар, берләшегез!
Сынау сәгате сукты.
Илебезне, динебезне
Аллаһ сакларга кушты.

Мөселманнар, берләшегез!
Тәре коллары килә.
Кардәшләрне юк итәргә,
Илләрне туный, телә.

Мөселманнар, берләшегез!
Террорны сылтау итеп,

Бетермәк алар Исламны
Дәһшәтле утта өтеп.

Мөселманнар, берләшегез!
Бу – Ходайның әмере.
Нефть өчен ябырылды
Илбасарлар өере.

Мөселманнар, берләшегез!
Нияте без мөкатдәс.
Коръән-Кәримле өммәтне
Аллаһ үзе ташламас!

Елады, галәм, елады...

Шигый җәлладлары аңа:
"Җәһәннәмгә олак!" – диделәр.

Кемнәр ул тантана итә,
Бүйракта мылтык атып?
Маймылдай сикерешәләр,
Сәддамны куйгач асып.

Тетрәнеп елады Галәм
Бу фаҗигане күреп.
Хак мөселманның ныклыгын
Көчәйтте Сәддам үлеп.

Илбасарлар, илсатарлар
Корбан иттеләр кемне?!
Канлы мәхшәргә әйләнде
"Мең дә бер кичә" төне.

Ватанпәрвәр кеше китте
Сөнни мөселман булып.
Фәрештәләр җиргә төште,
Аллаһ рәхмәтен кылып.

Баш имәде, тез чүкмәде
Башкисәрләр каршында,
Намаз укып, Коръән тотып,
Бакты ул Хак каршына.

Шәһид үлемле, ил улы
Көрәшкә өндәп торыр,
Сәддам Хөсәен мәңгелек
Илбашы булып калыр!

Намаз укып, Коръән тотып,
Бакты Аллаһ каршына,
Мөхәммәд пәйгамбәр алды
Аны җәннәт ашына.

4 гыйнвар, 2007 ел

Көрәш

Явызлык өстен чыгамы?
Яхшылык өстен чыга!
Котырынган явызлыкны
Биленнән алып ега.

Җәннәттән сөрелгән Адәм,
Нәфесеңә кем хуҗа? –
Явызлык өстен чыга шул,
Яманлык өстен чыга.

Ғил алышып, чат ябышып
Мәхшәргәчә барасы –
Явызлык та, яхшылык та –
Фани Адәм баласы.
Кайсы өстен каласы?..

февраль, 2006 ел

Бәхәс

Җомга, шимбә һәм якшәмбе
Бәхәс кылды бермәлне.
Якшәмбе байтак кызмача –
"Манчый" җомга, шимбәне.

"Мин, – ди, атнаның хуҗасы,
Көннәргә рухи ата".
Тәре таккан Мәрьям улы
Дулый, йодрык уйната.

"Гөнәрем – талау, үтерү...
Мин – җиһанның чуртаны.
Хәрам ашыйм, зина кылам
Кочып бөтен дөньяны.

Ғармагым кызыл төймәдә,
Ракеталар очырам.
Миңа каршы кешеләрнең
Җанын күккә ашырам".

Тыңлый җомга. Йөзендә нур,
Үзе горур, бик сабыр.
Ялгышмассың, кабатласаң
Җомга сүзен мең тапкыр:

“Әстәгъфирулла, Илаһым,
Рәхмәтеңнән ташлама.
Кадерле Җир-Анабызны
Җомгаң белән ашлама.

Илдә дошман эзләмибез,
Ният – изгелек кылу.
Дус-тату яшәү үзара,
Галәмгә ипле булу.

Һәр көнеңә насыйп әйлә
Хәләл маллар, хәләл аш.
Күркәм холык, рухи сафлык
Булсын тәреңә юлдаш.

Исламга, иман китереп,
Адашканнар хаҗ кылсын.
Ракета, бомба урнында
Әдәпле әхлак торсын.

Бала газиз анасыннан
Иманлы булып туа.
Адәм галәйһиссәләм дә
Ислам динендә була”.

“Күрше хакы – Алла хакы, –
Ди шимбә, итагатьле.
Үземә файдасы тисә,
Бирәм каныма хәтле.

Тик сер һәм милли хис миңа
Күкән булып әманәт.
Без – шимбәләр, әманәткә
Итлибез һич хыянәт.

Шуңа да без дөнья тоткан
Пәйгамбәрләр кабеме.
Хак Тәгалә үзе белә
Хуҗа итәргә кемне".

Җомга, шимбә, якшәмбе –
Иланһының бүләге,
Һәркөн Галәмнең тылсымлы,
Кабатланмас бүләге.

июль, 2003 ел

Чиге бармы?

Залимнәрнең кылган явыз гамәлендә
Гафу итәр, гафу итмәс золымнар бар.
Коръән әйтә: үтерүдән үч алу –
Мөселманга рөхсәт ителгән хак карар.

Ирек өчен шәһид киткән ир-атларның
Хатыннары яңь-яшь килеш ирсез кала.
Дошманнардан канга-кан дип үч алырга
Җефетләре билләренә җиһад сала.

Шартлый йортлар, вокзал, мәктәп, тимер юллар,
Зур калалар тузан булып күккә оча.
Тупрәләрнең тәкәббер кирелегеннән
Бер гөнаһсыз сабыйларны үлем коча.

Бу мәхшәрнең фанилыкта чиге бармы?
Кешеләрнең гамь-афәтен аңларлармы?
Әллә адәм – Иблис – уттан алданамы?
Әллә тәкъдир яшеннәргә ялганганмы?

Хатын-кызлар ут кабызсын учагында,
Бала-чага булсын табын кочагында.
Явызлыклар кылып йөргән залимнәргә
Яшәү тәмуг уты булсын һәрчагында.

май, 2011 ел

Дәшсен өмет!

Караңгылык таҗын сала,
Җиһанга ут атыла.
Бар тереклек каерылып,
Чурга таба тартыла.

Бисмилласын әйтеп иртән
Җан иясе күз ача.
Күк йөзеннән кара болыт,
Җир йөзеннән төн кача.

Кара төн күрмәгән белми
Якты көннең кадерен.
Яманны җиңгәннәр татый
Яхшылыкның әҗерен.

Байлык

Матди байлык,
Рухи байлык...
Кайсы байлык кадерле?
Кайсы байлык бәрәкәтле,
Була озын гомерле?

Кайсы байлык кешеләрнең
Җанына ләззәт бирә?
Кайсы байлык күз йомгач та
Җаныңны нурга төрә?

Кеше китә... Әманәтен
Яңа буыннар ала.
Асыл затның игелеге
Чүр булып җирдә кала.

Кала аның изге уе,
Кала рухи байлыгы.
Байлыкның заты – иманлы
Үз нәселең барлыгы.

Дөньяның сигез могҗизасы –
Алар да рухи байлык.
Могҗизалар иҗат итмәс
Рухи байлыксыз халык.

Дәверләр һәлакәтеннән
Чал һәйкәлләр югала...
Дөньяның рухи байлыгы
Мәңгелек булып кала.

апрель, 2006 ел

Саклап тора җәза

Кемдер затлы ризык ашап чәй эчәдер,
Тәм-томнардан ләззәт алып наз кичәдер.
Ә берәүләр ипи белән сөтле чәйгә
Аллаһыга шөкер итеп көн күрәдер.

Табындагы ризыклары хуҗасының
Чынбарлыгын чагылдырып, тасвир итә:
Кеше талап мал җыючы башкисәрме,
Әллә гади адәм булып гомер көтә.

Бу икенең азыклары ни исемле?
Кайсы хәрам ризык булып, кан ислеме?
Иясенең эш-гамәле көн төслеме?
Әллә айсыз һәм йолдызсыз төн төслеме?

Әниләрнең, сабыйларның күз яшьләре...
Юкмы каргыш, ачы каһәр тәгамендә?
Тамагына таш булып утырыр мәгәр,
Я манатлы эшләр булса гамәлендә.

Бәхет-шатлык, исән-саулык юлдаш булыр,
Аш-сулары бисмиллалы хәләл булса.
Гаҗәп түгел: кеше хакы җәза булып,
Җан коючы киллер кебек саклап торса.

июнь, 2014 ел

Димәс идем...

Ваклыкларга башым имәс идем,
Әрәм үтте гомер димәс идем,
Бәрәкәтле булса хезмәтем,
Хөрмәтенә илнең лаек булсам,
Аңа лаек эшләр генә кылсам,
Рәхмәт әйтсә газиз милләтем.

Мин болай ук янмас-көймәс идем,
"Кайәр суксын инде!" димәс идем,
Явызлыкның күреп кодрәтен.
Ах-зарларын аның үземә алыйм,
Авыр йөген үз иңемә салыйм,
Юллар сайлыйм сиңа, милләтем.

Шулай дим дә... Менә шунда бәла:
Җирдә золым һаман исән кала,
Милләт-ана, без һаман да бала.
Саклап кала мине милләтем.
Әле ярый, тик ул йолып ала,
Мин аның бер улы булып калам,
Яклый мине газиз милләтем.

октябрь, 2006 ел

Сыерга сыену

Сыер – Аллаһның бүләге,
Ул хәләл, изге хайван.
Гомер буе кешелеккә
Игелек кыла һаман.

"Зәмзәм чишмәсе күк бул!" – дип,
Аллаһ аны яралткан.
Хәер-фатихасын биреп,
Җир йөзенә тараткан.

Абзарда сыерың торса,
Өстәлдә булыр сыең.
Сыер – ярты әнкә, ләкин
Тапкан әнкәңә сыен.

Сыер сөте җәннәттә дә
Елгалар булып агар, –
Изге гамәл кылган адәм
Җәннәт йөзенә багар.

Сыерга ыңгырчак салма,
Аңа дага да какма.
Ул изге Коръән сүрәсе,
Коръән күк итеп сакла!

май, 2006 ел

Маймыл бизмәне

Маймыл берәүнең букчасын
Кулыннан тартып алган.
Хуҗасы нишләргә белми
Авызын ачып калган.

"Маймылкаем, – дип ялына, –
Бирче минем букчамны,
Хаҗга барырга дип җыйган
Идем бит мин акчамны".

Маймыл күз кысып шаярта:
"Акчаң хәләлме? – дия, –
Хәләл булмаган акчага
Төшүнән була көя".

Көтелмәгән бу хәлләрдән
Хуҗа аптырап калган.
Ә маймыл, акчасын санап,
Яртысын суга салган.

Гәм әйткән: "Калганы – сиңа,
Яртысын – суга аттың,
Сөтеңә су кушып саткан
Акчаңнан колак кактың!.."

14 февраль, 2007 ел

Мәхлук

Куян төсен үзгәртсә дә,
Исем-җисеме кала.
Ә төлке җиде бүрене
Җитәкләп йөри ала.

Мәче дә юлбарыс түгел,
Кыяфәт охшаса да.
Шакал бүрегә тиң түгел,
Үләксә ашаса да.

Карга, үлеп терелсә дә,
Сандугач була алмый.
Бөркет оясы – кыяда,
Ул шуны лаек саный.

Кеше барын да булдыра:
Җир астында да тора.
Агач башларына менеп,
Үзенә оя кора.

Явызлыкта аңа тиң юк,
Хәйлә-мәкердә – төлке.
Акылыннан чыгып китсә,
Котырган аю төсле.

Рәхмәтле дә була белә:
Тапкан-бакканын бүлә.
Актык телемен дә бирә,
Хәтта ярдәмгә килә.

Тик үзенә хуҗа түгел,
Нәфесе аңа хуҗа,
Нәфесен шайтан котыртса,
Зиһенен-аңын җуя.

Ғайлык өчен үз анасын,
Иманын, җанын сата.
Имансыз-җансыз гәүдәсе
Тәмуг төбендә ята...

сентябрь, 2006 ел

Бакыр казан, җиз комган

Ғезнең борынгы бабалар
Далада тормыш корган.
Ғакыр казан, җиз комганы
Яшәү рәвеше булган.

Тирмәнең затлы түрендә
Ғакыр казан, җиз комган.
Дини йола, гореф-гадәт
Шуларга бәйле булган.

Аларны сылу киленнәр
Ком белән ышкып юган.
Алар кояштай нур бөркеп,
Ай кебек балкып торган.

Догалы бакыр казанда
Туй ашлары кайнаган.
Бисмиллалы җиз комганда
Иман нуры уйнаган.

Ата-баба тирмә корып,
Казан аскан колгага.
Калҗа исе кунак дәшеп,
Җәелгән бар далага.

Корбанга чалган елкының
Саваплы ите пешкән.
Бертуганнар, канкардәшләр
Сыйлы кунакка төшкән.

Көмеш сулы җиз колганнан
Тәһарәт алган алар.
Намаз укып, дога кылган
Төрки-татар бабалар.

Бакыр казан, җиз колганнар
Халкымның йөз аклыгы.
Хак динебезнең пакьлеге,
Әдәп, әхлак сафлыгы.

10 июнь, 2008 ел

Элгәреләр һәм бүгенгеләр

Адәм заты алгарышка дип ашкына,
Бәлмәк була галәмнәрнең яшеренен.
Якынайган саен сергә – ул кыскарта
Кешелекнең бу дөньяда яшәр көнен.

Изге Коръән китабында Аллаһ әйтә:
"Элгәреләр сездән зирәк булдылар", дип.
Аллаһ – гыйлем, белеменә якын килгән
Кавемнәрне һәлак итеп бетерде бит.

июль, 2013 ел

Нигә шулай?

Горур дибез, бик еш, мактанабыз,
Милләт җанлы дибез татарны.
Кем дип атыйк, катнаш гаилә корып,
Милләт мәнфәгатен сатканны?

Ир-егетләр маржа кочагында,
Хыянәткә кереп, җан сата.
Кызларыбыз, егетләрне узып,
Тәре такканнарны ярата.

Татар кызы, татар егетләре
Ник үзара никах корышмый?
Егет кызны, кызлар егетләрне
Ник эзләми, нигә табышмый?

Ат кешнәтеп, ә этләр иснәшеп
Табышалар кирәк булганда.
Эт бүрене, атлар да ишәкне
Пары итми нәсел корганда.

Хайваннар да, кошлар, балыклар да,
Үз каныннан нәсел калдыра.
Кош-корт – оя, бүреләр өн кора,
Гәр тереклек тормыш булдыра.

Катнаш гаилә – сыныкка сылтау ул,
Үзләштерү башка халыкны.
Тик берәү дә яулап ала аллас
Күңелдәге милли холыкны.

июнь, 2013 ел

Чигүле дөнья

Хак Тәгалә бу дөньяны
Сөю белән сугарган.
Гашыйкларның якты нуры
Төшкән, димәк, югардан.

Яшәеш белән мәхәббәт –
Әйтерсең бер иҗектән.
Арба да ялгыз кузгалмас,
Аты булмаса җиккән.

Җирдә хәят булсын өчен
Кирәк кояш җылысы;
Мәхәббәт назлы булсынга –
Үй-хисләрнең чынысы.

Гәр нәрсәнең, һәркемнең дә
Пары бар бу тормышта.
Җир-күкләр дә бер-берсенә
Багланышлы булмышта.

Хак Тәгалә бу дөньяны
Мәхәббәт белән чиккән.
Менә шушы тибрәнештә
Яшәп ятабыз икән.

август, 2013 ел

Байлык белән сынау

Энҗе-мәрҗән диңгез төпләрендә ята,
Алтын-көмеш җир астында посып ята.
Энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш хуҗалары
Ғалчык сыйфатына кайтып – гүргә ята.

Энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш кебек затлы
Ғайлык өчен кан коела, җан кыела.
Адәми зат җиргә килгән көннән алып,
Сугыш бара, үлем аша мал җыела.

Энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш биниһая,
Тик аларга акчалы бәндәләр ия.
Кан койган һәм җан кыйганның варислары:
"Бу байлыклар безнең шәхси милек", – дия.

Ялтыраган һәр нәмәстә алтын түгел,
Пыяланы энҗе дип алдану җиңел.
Тышкы ягы ялтыравык адәмнәрнең
Дөньялыкта гамәлләре изге түгел.

Алтын-көмеш бер сыныкмәккә тормый,
Шулар өчен ил-җирләрдә талаш тынмый.
Нәфес колы булган комсыз бәндәләрне
Хак Тәгалә ялтыравык белән сыный.

Энҗе-мәрҗән, алтын-көмешнең тылсымлы
Җемелдәвеннән берәүләр аңын җуя.
Нәфес колы, байлык колы булганнарны
Маймылдан да түбән дәрәҗәгә куя.

Көне-төне корал коя денсез илләр,
Үз-үзләрен юк итәргә җитә булыр.
Кан-яшь сеңгән барлык-барлык байлыклар да
Диңгез асты, җир астында булып калыр.

гыйнвар, 2012 ел

Өмет

Уйный кайчак баш очында Язмыш,
Уйный ачы көлеп –
Яшәремә өмет каллмас дисең,
Юк, югаллмый өмет.

Өмет яши... Өмет исән кала
Кеше исән чакта –
Кыз дә йоммый, һәрчак уяу булып,
Өмет тора сакта.

Син үзең дә аның кадерен бел,
Якла көне-төне!
Учак көленнән дә аралап ал
Сүнгән өметеңне...

август, 2005 ел

Изге нур алып

Татар илен саклап, динен яклап,
Сакка басты сигез каһарман.
Кыккә ашкан көмеш сөңгеләре
Кодрәт ала тиңсез Алладан.

Гасырларны үтеп, чыкты үсеп,
Тамырлары җиргә берегеп.
Мәрмәр кыя булып басты алар,
Сигез ае тора нур бөркеп.

Сигезе дә, илем белән бергә,
Мәңгелеккә баккан карашын.
"Сөембикә" – горур манарабыз –
Сәлам бирә чөеп ай башын.

Чал Кремль ак күлмәген киде,
Егет көткән кәләш шикелле.
Күктә, җирдә ике зәңгәр гөмбәз –
Игезәкләр алар сөйкемле.

Кояш көлә, мәчет балкып тора,
Аллаһыдан изге нур алып.
Күккә ашкан "Кол Шәриф"кә карап,
"Сөембикә" бара тураеп.

июнь, 2005 ел

* * *

Үз иленә хуҗа илбашлары –
Дан-хөрмәткә лаек юлбашчы.
Хак Тәгалә фатихасы белән
Акыллы ир була илбашы.

Ирсез хатын – үксез тәрбияли,
Затлы буллый сәрхүш баласы.
Оясында күргән гадәтләре –
Буыннарның йөрәк ярасы.

Яман гадәт, кара сакал кебек,
Синең белән гомер кичерә,
Кем булсаң да, шушы "кара сакал"
Күңел ятагында көн күрә.

Бала чактан алар синең белән
Кочаклашып үскән гадәтләр.
Гореф-гадәт, ата-бабаларның
Каннарына сеңгән таләпләр.

Син хуҗамы, кешем, язмышыңа?
Йә, язмышны кемнәр үзгәртә?
Язмыш кануннарын бозганнарны
Тормыш кыйный-кыйный өйрәтә...

февраль, 2005 ел

Фәлсәфи яңгыр

Күк тутырып тансык яңгыр ява,
Күкләр тетри, яшен ук ата.
Чыңлап торган яңгыр тамчылары
Җирдә яшәү ямен яңарта.

Яңгыр ява, дөнья сихәт ала,
Басу-кырлар ямьгә төренә.
Чәнечкеле шайтан таягы да
Чәчәк аткан кебек күренә.

Ак болытның ачык "тәрәз"еннән
Йөгереп чыга кояш нурлары.
Яңгыр суын госел иткән гөлләр –
Җир-ананың җәннәт хурлары.

Аллы-гөлле салават күпере
Офыкларны кочкан дугалап.
Бер ягында кояш, ә бер якта
Болыт тора күкне томалап.

Шаулап килгән яңгырлары белән
Ачык дәрес бирә табигать.
...Хатын-кызның – болыт,
Гаярь ирләрнең яшен
Икәнлеген белдем, ниһаять!

Табигать һәм кеше – тугандашлар,
Бер үк холык, бер үк шөгыльләр.
Табигатьне җан дустыдай күрсә –
Мәңге яшәр җирдә кешеләр...

август, 2013 ел

Әйләнеш

И гомеркәй, болыт арасыннан
Балкып чыккан кояш шикелле,
Ялт иттең дә, инде йомыласың,
Ак нурларың җиргә сибелде.

Кеше дигән затны миллион еллар
Иҗат иткән Кодрәт иясе.
Җир йөзендә юктыр аңа тиңнәр,
Дөньяларда юктыр тиңдәше.

Сокландыргыч шушы адәми зат
Комсызланып җыя мал-мөлкәт.
Ул тәкәббер. Имеш, акыллы зат
Гәм бер мизгел... Алда – һәлакәт.

Галиҗәнап вакыт һәм бер мизгел:
Кемдер туа, кемдер юк була.
Тән туамы, җан туамы бүген,
Йа Илаһым, әйтче, кем туа?

Гәм ул булыр нинди кыяфәттә,
Калырмы ул Кеше төсендә?
Нинди гамьнәр аны әйдәп йөртер,
Ни майтара алыр эшендә?

Ахирәттә беркем колач җәеп,
Чәк-чәк тотып безне көтмидер.
Гөнаһ берәү дә, ашап-эчми генә,
Эш-гамәлсез гомер итмидер.

Хак Тәгалә безгә акыл биргән,
Үз көнеңне үзең күр, дигән.
Мәңге яшәешкә юл күрсәткән,
Изге китапларын иңдергән.

Җәннәттә дә акыл һәм хис булса...
Бу дәвамы, димәк, тормышның.
Маңгайларга алдан язылгандыр
Гөнаһ гамәле безнең язмышның...

Аллаһ безгә серле мәгънә салган,
Акыллы һәм асыл зат кылып.
Юкса, яшәр идек ерткыч булып,
Йә кемгәдер азык, аш булып.

Әбез – Кеше. Адәм, җиргә килеп,
Тау-ташларда тормыш башлаган.
Җир-Ананы сөеп, рәхмәт диеп,
Зиһен, белем, фикер туплаган.

Иксез-чиксез Галәм бакый икән,
Тормыш вә Яшәеш мәңгелек.
Сулар да бит, парга әйләнә дә,
Җиргә ява яңгыр, кар булып.

Бу – илаһи вакыт әйләнештә,
Бар нәрсә дә тора алмашып.
Яшәешнең серле агымында
Калма, кешем, калма адашып.

Сөйлим ихластан...

Авылымның гүзәллеге белән,
Көтү көткән чакта таныштым.
Болыннарда койрык чәнчеп чапкан
Яшь бозаулар белән ярыштым.

Тугайларны, су буйларын иңләп,
Казлар белән җәйләр кичердем.
Какы өзеп каптым, борчак салып,
Кузгалаклы ашлар пешердем.

Ун яшемнән дүрт ел көтү көттем,
Чишмәләрдән ятып су эчтем.
Җир-әнкәнең сыйлы хөрмәтенә
Бисмилламны әйтеп ирештем.

Субаш-Атым! Кендек каным тамган,
Ата-бабам торган туган җир.
Мәңге сиңа гашыйк улың итеп,
Куеныңнан миңа урын бир.

июнь, 2014 ел

Күктән иңде

Могҗизалар, сәер хәлләр булып тора,
Күңел күзе, маңгай күзе күреп тора.
Ат типкәннән мием читкә тайпылса да,
Акыл эшли, кулым һаман язып тора.

Бу сәер хәл үзе могҗиза түгелме?
Язганнарым күңелемә күктән иңде.
Хак Тәгалә: "Акыллы сүз, фикерләрне
Чәчми-түкми адәмнәргә җиткер", – диде.

октябрь, 2010 ел

Әнкәм васыяте

Әнкәм миңа әманәтле васыять әйтте,
Аллаһның бер һәм барлыгын исбат итте.
Ышану да, ышанмау да – һәркем эше,
Ләкин тел-теш тидермәсен Аңа кеше.

Хак Тәгалә берәүгә дә мохтаҗ түгел,
Тик Аллаһсыз яшәүнең дә юклыгын бел!
Әнкәмнең бу васыятен әйтеп үтәм,
Изге әманәтен сезгә биреп китәм.

май, 2010 ел

Әнием Хәбибҗамал

Аллаһ миңа әниләрнең
Игелеклесен бирде.
Әни гомере буенча
Изгелек кылып йөрде.

Утыртты тайган буынны
Тажәп осталык белән, –
Савыгып китте өенә
Култык таякта йөргән.

Аның нәфис бармаклары
Тылсымлы иде сыман.
Төзәлде сырхау-сызлаулар
Кулы орыну белән.

Җан газабы кичергәнне
Терелтте дога укып.
Эчендәге чир-зәхмәтне
Әйтерсең алды йолкып.

Рамазан, мәүлид аенда
Тансык абыстай иде.
Иң Алласыз заманда да
Дин сабаклары бирде.

Әйтә иде: яхшылыкның
Очы-чиге юк, диеп.
Гәр изге эш-гамәлләрне
Башкарды ихлас сөеп.

Халкым табибәсе идең,
Әнием – Хәбибҗамал.
Аллаһ сөеклесе булып,
Мәңгелек җәннәттә кал.

сентябрь, 2013 ел

Гафу ит...

Анасын күтәреп Хаҗга
Алып барса бер бала,
Анасының бер тулгагы
Әҗерен генә ала.

Әнием, мин сине Хаҗга
Күтәреп бараллмадым.
Хәер-догаңны алсам да,
Җан сакчың булалмадым.

Иртән эшкә йөгергәндә
Син калган идең йоклап.
Тиз генә кире борылып,
Кайтуым булды соңлап.

Син, әни, китеп баргансың
Аллаһның хозурына.
Соңгы сулышың алганда
Булалмадым яныңда.

Авыз, иренең чылатыр
Су каптыра алмадым.
Мәңге үкенечтә калды,
Бәхилләшә алмавым.

Яныңда була алмадым,
Гафу ит мине, анам.
Гомер буе җаным әрни,
Гомер буе сыкранам.

май, 2009 ел

Татарыңа акыл иңдер

Адәм затын акыл иясе дисәк тә,
Башкалар күк, ул да мәхлук, җан иясе.
Имансызлар – Аллаһыны инкяр итеп,
Сын-потларга, рәсемнәргә баш июче.

Җирне-күкне, ай-кояшны, йолдызларны
Тиңсез Аллаһ гыйльме, акылы бар иткән.
Ул – хикмәти бердәнбер илаһи кодрәт,
Акыл көче ике дөньяга җиткән.

Кайсы сын-пот бер тереклек булдыра ала,
Черегәнне нинди көчләр терелтә ала?
Сыннар, потлар, рәсем, икона – үзләре
Җансыз-өнсез кеше ясаган алдама.

Мөшрикләр табыналар шул сыннарга,
Монафикълар буталалар икеарада.
Ярты милләт – катнаш никах җәтмәсендә,
Ярым татар торып калды ике ярда.

Заманабыз динчеләре сәүдә итә,
Мәчетләрдә коммерция чәчәк ата.
Акча җене кагылган мулла-абыстай
Хак динен дә, иманын да уптым сата.

Һәзарәтне басып алды монафикълар,
Мөшрикләрне кочып-сөеп яши алар.
Динне кәсеп иткән җаһилләрне күреп,
Аптырашта калды мөэмин-мөселманнар.

Бер-беренә яла яга, нахак тага...
Мәчетләрдә динче кортлар мал бүлешә.
Төркем-төркем оешкан "дини өерләр",
Урын өчен, керем өчен чәкәләшә.

Динем өчен түгел, көнем өчен диеп,
Яши бүген кайбер мулла-абыстайлар.
Һәфесләренә ияреп адашканнар –
Сын да, пот та, икона да хәзер алар.

Йә, Аллаһым, рәхмәт – мәрхәмәтең киңдер,
Татарыңа милли-дини акыл иңдер!

май, 2010 ел

Изге Болгар җирендә

Күкнең йөзе сүрән, пәрәвәзле,
Булмаса да көне болытлы.
Илбасарның канлы вәхшәтендә
Әйтерсең лә күкләр җаваплы.

Әйтерсең лә кояш оятыннан
Йөзен пәрдә белән каплаган.
Кылыч аша үткән болгарларны
Хәтерендә янып саклаган.

Саклаган ул – өер-өер килеп
Ябырылган дошман яуларын.

Хәтерли ул сабый балаларның
Елга булып аккан каннарын.

Ач-ялангач, чабаталы дошман
Болгар малын күреп шашына.
Халкын кырып, илен-җирен талап,
Ганимәтләр өчен ашкына.

Баскынчылар, тимер богау салып,
Кол итмәкче болгар улларын.
Ерткычланган кяфер кавемнәре
Мәсхәрәли ислам кызларын.

Һәр тарафта – иңрәү, каргыш, ләгънәт,
Галәмнәрдән ташый бәддога.
Һәр тарафта янгын котырына,
Шәүләсеннән күкләр яктыра.

Җирдә барган бу мәхшәрне күреп,
Күзен йомды кояш офыкта.
"Кан коюлы кыргыйлыктан мине
Яшер", – диде Ай да болытка.

Илне җиһад көрәшенә дәшеп,
Быргы уйный, кылыч ялтырый.
Болгарларга илаһи рух биреп,
Изге азан моңы яңгырый.

* * *

Болгар җирен тездән үлән япкан,
Күләгәсе җирдә дым саклый.
Изге җирдә сәждә кыла татар,
Бисмилласын ихлас кабатлый.

"Йә Аллаһым, шәһид киткәннәрне
Шәфкатеңнән бирүк ташлама:
Әл-Коръәнле изге Идел-Йортны
Адәм каны белән ашлама.

Илгә-җиргә исән-имин лек бир,
Бәрәкәт бир татар иленә.
Ата-баба әманәтен үтәп,
Өммәт булсын ислам диненә.

Болгар җирен, Идел-Йортны саклап
Корбан булганнарны ярлыка.
Дине белән хак мөселман булып,
Мәңге калсын халкым барлыкта!"

Татарларның гозер-гыйбадәтен
Җиде күкләр тынып тыңлады.
Фәрман иңде гареш киңлегеннән,
Фәрештәләр сүзсез аңлады.

Күк капусы ачылгандай булды,
Якты нурлар җиргә сибелде.
Аллаһу әкбәр дип тәкбир әйтеп,
Меңъ-меңъ башлар җиргә иелде.

Татар җаны әби-балаларның
Рухи җаны белән тоташты.
Буыннарның иман бердәмлеге
Күңелләргә кереп урнашты.

Җир катламын үтеп бабамнарның
Хәер-фатыйхасы яралды.
Тәнебездә йөреп, йөрәкләрдә
Мәңгелеккә иман яңарды.

Рәхмәт әйтеп нәсел-нәсәпләргә,
Хәер дога юллыйк Болгарга.
Каһарманнар рухын байрак итеп,
Алып барыйк шанлы елларга!

* * *

Йөзен кулы белән каплап,
Үкси татар баласы.
Йөрәгенең тирләрендә
Әрнеп сыкрый ярасы.

Үксеп елый: "Мин карт инде,
Еллар алды көчемне.
Шушы җирдә шәһид киткән
Ата-бабаларым өчен
Алалмадым үчемне.

Бугазларын чәйнәр идем,
Тешләрем төшеп беткән.
Кан хакы тулянми кала...
Куллардан дәрман киткән.

Үкенеп узды гомерем,
Эшләнмәде шул эшем.
Ата-баба әманәтен
Үтәп иде өлешем.

Язмыш хатасын төзәтү –
Ир-атка лаек бурыч.
Җиһад өчен әзерләнгән
Кынында кала кылыч.

Изге җирне дошманнардан
Азат итү – фарыз эш.
Чебешләр яшәсен дисәң –
Козгын очмаска тиеш.

Бала – элгәреләр өчен
Җавапсыз дисәләр дә...
Баскынчыларның гадәте
Хәзерге кемсәләрдә.

Бүген Күк капусын ачты,
Галәмнәр карар итте:
Илбасарның варисларын
Илдән куар чак җитте.

Васыять итеп әйтәмен:
Татар үз-үзен тапсын.
Ил-җиребез, хак динебез
Хөрлектә чәчәк атсын!"

Барысы да Аллаһ кодрәтендә

Барысы да Аллаһ кодрәтендә, –
Ул хуҗасы чиксез Галәмнең.
Ләүхелмәхфүз тактасында булыр,
Язмышлары һәрбер адәмнең.

Татарның да тәкъдир-язмышында
Язылгандыр ниләр күрәсе.
Мәсхәрәгә калып, чит дәүләткә
Һәүмиз халык булып керәсе.

Мәшһүр Баһадурны, Атиланы
Терелтәсе иде бер көнгә.
Карасыннар иде илен саткан,
Урыс телле татар мескенгә.

Гәм күрсеннәр иде умырылган
Уч төбедәй татар ил-җирен.
Парә-парә килеп телгәләнгән
Чын татарның канлы бәгырен.

Татар данын Гарешләргә чөйгән
Каһарманнар калыр шаккатып.
Биниһая татар дәүләтләрен
Бетерде соң кемнәр таркатып?

Барысы да Аллаһ кодрәтендә,
Безнең тормыш – Аның карары.
Мәңгелектә калыр кавемнәрен
Тәкъвалыкта сынап каравы.

Аллаһ безгә хәер-фатихасын,
Иман нурын биргән яшәргә.
Үткәннәрдән кирәк гыйбрәт алып,
Гөнаһлардан тәүбә итәргә.

май, 2016 ел.

Татар язы килер...

Җир-күкләрне көн дә нурга төреп,
Кояш чыга, төнлә ай калка.
Аллаһының рәхмәт йолдызлары
Ғаләмнәрдән сәлам балкыта.

Чурлы кояш, якты ай, йолдызлар
Җир-әнкәне сөя иркәләп.
Аллаһыга шөкерана кылып,
Ғар тереклек яши бергәләп.

Тик берәүләр үзенеке итмәк –
Ғасып алган чит-ят җирләрне.
"Российская нация" ясап,
Ғетермәкче милли телләрне.

Тик кояшны, ай һәм йолдызларны
Ғүрек белән буллмый томалап.
Хак динебез – Кояш, телебез – Ай,
Ә йолдызлар – халык, миллионлап.

Кышлардан соң язлар килгән кебек
Татар язы, аяз көн килер.
Ғарысы да Аллаһ рәхмәтендә, –
Ирек яулап халык сөенер.

март, 2017 ел.

Иҗат газабы

Ғәргәләнәм, җаным ирсәләнә,
Күңелемне борчу кимерә.
Әсәрләрем, гүя, тәмен җуйган
Майсыз ботка сыман күренә.

Сызам, бозам. Юкса, язган булам –
Хыялымны чынга ашырмак.
Әй, тырышам. Килер буыннарга
Рухи мирас булам тапшырмак.

Язганнарым өчен оялсам да,
Уй-хисләрем ихлас күңелдән.
Җан авазым булган фикерләрем
Изге ният белән ирелгән.

Ләкин алар чиле-пешле кебек,
(Ғәлкем миңа шулай тоела).
Китапларым укып карыймын да,
Күңелемә шикләр уела.

Тик никадәр инде пошынсам да –
Әманәтем чорлар чатында.
Булыр алар газиз милләтемнең
Исән-имин леге сагында.

Сезне сөеп язган әсәрләрем –
Нәселемнең бәгырь җимеше.
Татарыма булган мәхәббәтнең
Җир-күкләрдә гомер сөреше.

декабрь, 2011 ел

Дин – тиңдәшсез Аллаһының
Фәлсәфи уй-фикере.
Адәмнәргә яшәештә –
Ике дөнья күпере!


إنك على صراط مستقيم
إني توكلت على الله
Аллага таяныдым..., чонки Раббем туры жолда.
Коръэн, 11/56.

III бүлек

Әй син, татар! Асылыңа кайтып,
Илне-динне сакла, горур бул!

Әсәрләр тажы

Җан ияләр, цсемлекләр
Бизи барча дөньяны.
Илаһи зат күркәм итеп
Иҗат иткән аларны.

Хайван, җанвар, бөҗәк, кошлар
Беләләр цз бурычын.
Адәм – Аллаһның вәкиле –
Көйли тормыш барышын.

Һәркем, һәр нәрсәгә мәгълүм
Яшәү һәм цсү сере.
Дөнья нәүмиз булып кала,
Югалса шуның бере.

Һәркем, һәр нәрсә тормышта
Җай гына гомер итә.
Яшьнәргә, яшәү башларга
Зарыгып язны көтә.

Язын гөлләр чәчәк ата
Мең төрле төскә кереп.
Табигатьнең гүзәллеген
Туймыйсың мең кат күреп.

Кем бизи икән аларны
Тылсымлы зәвык белән?
Бу кадәрле төгәллекне,
Камиллекне кем биргән?

Иң гади әйберләрдә дә
Ул затның бар кодрәте.
Галәмнәрнең барлыгында
Аның тиңсез куәте.

Гәрберсе сәнгать әсәре,
Кеше – әсәрләр тажы.
Акыллылык, галимлектә
Илаһи зат авазы.

Җан иясе, һәр цсемлек
Яшерен сер оясы.
Җир-ана – цзе сихри моң,
Могҗизалар дөньясы.

Ә син, кешем, Илаһ Затның
Кодрәтен сизәсеңме?
Тормыш биргән Җир-ананың
Кадерен беләсеңме?!

8 май, 2007 ел

Васыять

Сафьян тышлы Коръән тотып,
Әнием төшкә керде.
Болгар бабаларыңнан, дип
Ошбу Китапны бирде.

Һәм әйтте васыять итеп:
Милләтем бәйсез булсын!
Асыл ирләр вә кызларым
Халкыма хезмәт кылсын.

Эшләнгән һәр эшләреңдә
Изгелек булсын юлдаш.
Бәхетле итмәс һичкемне
Хәрам маллар, хәрам аш.

Коръәнле халык яшәсә,
Илгә бәрәкәт иңәр.
Ул илдә яшәгән халык
Бар авырлыкны җиңәр.

Яшәү шарты

Хак Тәгалә алтмыш дүрт яшемдә
Тойгы-хисләремне уятты.
"Яз!" дип әйтте Җәбраил фәрештә, –
Күңелемдә шигъри таң атты.

Табигатькә гүя әверелдем:
Кышым, язым, җәем, көзем бар.
Үй-хисләрем ташкын булып ургый,
Милләтемә әйтер сүзем бар.

Бу дөньяга кеше булып килү –
Галәм кебек серле могҗиза.
Җирдәге бар нәрсәгә җаваплы,
Галәм кебек син дә бит хуҗа.

Күр әле син, иртән нурлар бөркеп,
Көләч йөзле таңнар атканын.
Офыкларны алсу төскә манып,
Чурлы кояш туып яткынын.

Күр әле син, җирнең шатлануын,
Ул күпвакыт күркәм, сөйкемле!
Җир-күктәге сихри гүзәллекләр
Сокландырмый калмас һичкемне.

Табигатьнең юмарт табынында
Мөлдерәмә тора сый-хөрмәт.
Шөкерана кылып яшә, кешем,
Синең өчен барлык мал-мөлкәт.

Барысын да Аллаһ бүләк иткән,
Синең тарафыңа тапшырган.
Җир-ананы фани җәннәт итеп,
Теләгеңне чынга ашырган.

Тик Аллаһның канун-тәгълиматын
Үтәү фарыз гамәл кешегә.
Саф намуслы, пакь күңелле булу –
Яшәү шарты адәм ешегә.

Эш-гамәлең игелекле булсын,
Бәхет-шатлык, хөрлек китерсен.
Ата-баба яшәгән ил-җирне
Мәңгелеккә Йортың иттерсен!

ноябрь, 2007 ел

Оныгым Шамилгә

Торып-торып уйланам да, сыкранам,
Аяныч хәлемне күреп, ут янам.
Җиргә килеп, ни игелек кылдым мин?
Кемнәр белән, нинди тормыш кордым мин?!

Яшәүләрем, эш-гамәлем дөресме?
Әллә яман юл-суккакка керешме?
Уен итеп карадыммы тормышка,
Минме гомер елгасында йомычка?!

Гореф-гадәт, динем илемдә тынды,
Чит куенга бала-оныклар шылды.
Буыннарның бәйләнеше өзелде.
Әби-бабай учагыннан бизелде.

Корт ашаган агачтай калдык корып,
Урыс телле балалар алды сырып.
Ата-баба бүләк иткән әманәт,
Онытсаң әгәр – милләткә хыянәт.

Чишләргә дә белми бүген баш орам,
Дин-имансыз варислар белән торам.
Җиһан хәрам, фәхешлек белән тулды,
Оят-намус, хәләл гамәл онытылды...

Улым, Син ышанычым, синдә өмет,
Бул мөселман! Бул үзебезнең егет!
Алла бирсен сиңа тәүфыйк-сәгадәт,
Тик иманлы булып яшәү чын рәхәт.

Әеңдә Коръән нуры-моңы булсын,
Әби-бабам әләме балкып торсын!
Бу минем иң мөкатдәс васыятем,
Нәсел-ыру әманәтен сиңа әйттем.

Оныкларым!

Дөнья гүзәл, сихри, дибез... Ләкин
Төрле чагы була аның да.
Гомер буе яхшы белән яман
Җитәкләшеп бара яныңда.

Яхшы гамәл черем итә калса,
Яман нәфес алдап аздыра.
Җан-күңелгә шайтан коткы сала,
Туры юлдан сине яздыра.

Азмас өчен, юлдан язмас өчен,
Кирәк рухи иман мәсләге.
Ата-баба гореф-гадәтләре,
Изге Коръән Кәрим әхлагы.

Хак Тәгалә Адәм һәм Хәваны
Хәләл җефет итеп яралткан.
Хәва ирен, Адәм үз хатынын
Мәңгелеккә диеп яраткан.

Бу дөньяга кеше булып тусаң,
Шул сыйфатта калу мәслихәт.
Адәм-Хәва кебек итеп ярат,
Гаиләңә кыл син илтифат.

Мин дә җефет булдым, тормыш кордым,
Варисларым туды дөньяга.
Мең-мең рәхмәт әйтәм – балаларны
Багып үстерүче Саниягә.

Ул ир итте мине. Шатлыгымнан
Башым тиде җиде күкләргә.
Тату гаилә корып яшәдек без,
Үрнәк булдык илдә күпләргә.

Оныкларым! Ата-бабаларның
Югалтмагыз калеб аклыгын.
Тамырлардан татар каны аксын,
Саклагыз сез нәфес сафлыгын!

4 апрель, 2008 ел

Онытымның онытына

Онытымның син оныты,
Сиңа әйтер сүзем шул:
Исламның бар кануннарын
Ихлас үтәүчесе бул!

Күктән иңгән иман нуры
Әңдә балкып торсын.
Әдәп-әхлак, оят-намус
Күңел түреңдә булсын.

Шәфкатьле бул, изгелек кыл,
Илдә игелек артыр.
Яхшылыгың бише белән
Кире үзеңә кайтыр.

Яман сүз кеше үтерә,
Беркемгә яла якма.
Нахак әйтмә, гайбәт сатма,
Шаһитсез гаеп такма.

Бабалар тамырын сакла,
Нәсел шау чәчәк атсын!
Нык, таза кәүсәләреннән
Тик татар каны аксын!

20 апрель, 2008 ел

Догалы тамга

Татар кашага башына
Дага кадаклап куя.
Дагалы йортның хуҗасы
Бабалар рухын тоя.

Ат дагасы – йорт тамгасы,
Ул бәрәкәт билгесе;
Гореф-гадәт, миллилекне
Саклап яшәү өлгесе.

Дивардагы шамаил дә
Күңелебезне аклый.
Ишек өстендәге дога
Иманыбызны саклый.

Моның шулай икәнлеген
Мин гомер итеп белдем.
Дүрт мәртәбә чын үлемне
Үз күзем белән күрдем.

Дүрт яшемдә дагалы ат
Миңа тамгасын салган.
Сул як битемә тибүдән
Жан-тәнем тынсыз калган.

"Һәсел тамгасы булсын" – дип,
Дага эзен калдырган.
Әти-әнием дәвалап,
Көн-төн дога укыган.

Шул тамга оныкларыма,
Чорларга мирас булсын.
Дага, догалы нәселем
Мәңге яшәүдә калсын!

гыйнвар, 2009 ел

Аллаһ әмере белән

Читтән могҗиза эзләмим,
Мин үзем – бер могҗиза.
Бу дөньяда яшәвемә
Мең шөкермен, мең риза.

Дүрт тапкыр үлемнән калдым,
Памирда сырхау алдым.
Бергә хезмәт иткәннәрдән
Беүзем торып калдым.

Аллаһым мине яшәтә,
Акыл, фикер, уй биреп.
Шул акыл, фикер, уйларны
Бәндәләргә әйт, диеп.

июнь, 2009 ел

Тиңсез бүләк

Мине зат итеп яраткан
Аллаһка диям әкбәр!
Бала итеп тапкан-баккан
Әнкәйгә мең рәхмәтләр.

Дөнья дигән могҗизаны,
Серле күкләрне күрдем.
Искиткеч сихри, тылсымлы
Җир җәннәтендә йөрдем.

Аллаһның тиңсез бүләге –
Яшәүдән ләззәт алдым.
Хак Тәгалә каршысында
Мин кеше булып калдым.

июль, 2009 ел

Илче булсын

Алтмыш дүрт яшьтә Аллаһтан
Мөбарәк вәхи иңде.
Кулыма ул каләм биреп:
"Яз әйдә, бәндәм!" – диде.

Аң-акылым, зиһенемә
Белем, гыйлем, дәрт салды.
Аның илаһи көченнән
Күңелем илһам алды.

Фикеремдәге бөртекләр –
Кодрәтле Аллаһныкы.
Шулай дип кабул итегез
Сүземне, җиһан халкы!

Хисап тоту

Берәүгә дә яман кылып яшәмәдем,
Беркемгә дә зыян-зарар мин салмадым.
Язмышыма нәрсә язган – шуны күрдем,
Яшәү – намус билгесе диеп санадым.

Дошманнарым, көндәшләрем юктыр минем,
Башкалардан мыскал артык юктыр җирем.
Барлыгым да артык түгел, ким дә түгел,
Ходай биргән ризыкларга җитә керем.

Тормышымнан канәгатьмен, бик тә шөкер,
Ятсам-торсам – җаным тыныч, күңел актыр.
Хәрам эштән ерак торам – чөнки безгә
Тынычлыктан кадерлерәк нәрсә юктыр.

Карт көнемдә күңелем пакь, уйларым ак,
Аллаһ биргән ризык белән туктыр тамак.
Чәфес колы, корсак колы булганнарга
Тормыш һәрчак биреп тора ачы сабак.

декабрь, 2013 ел

Мин – татармын!

Бар иткәнсең мине, иләһи зат!
Башым иеп әйтәм рәхмәтне.
Яшәү дигән могҗизаны күрдем –
Җир йөзендә булган җәннәтне.

Рәхәтен дә, михнәтен дә гиздем,
Тыелганга кайчак үрелдем.
Тормыш дигән диңгез дулкынында
Күбекләнеп ярга сөрелдем.

Ләкин Күкләр мәрхәмәтле булды,
Җир-әнкәбез сөйде иркәләп.
Инде дөнья белән хушлашырга
Үз вакытым килә "үрмәләп".

Язмышыма һич тә үпкәләмим,
Халкым белән үтте гомерем.
Үзем булып рухи сүзем кала,
Утлы күмер булып – шигырем.

Тик таңнарда бик еш моңсуланып,
Сагынырмын гаярь чакларны.
Сагышларга үрләп сарылырмын,
Юксынырмын асыл затларны.

Колагымны куеп мин тыңлармын,
Тирбәлермен татар моңында.
Халкым кебек күркәм туган телем
Зеңләп торыр күңлем кылында.

Горурланам татар булуыма,
Шул сыйфатта китәм дөньядан.
Аллаһ кушса, фәкать татар булып
Туар идем җиргә яңадан!

Бәхетем әлифбасы

Бәхетле, бәхетсез булу –
Әйтәләр: "Язмыш эше".
Тик язмышка өмет баглап,
Яшәмәс тырыш кеше.

Үз тормышын үзе корыр
Хәләл хезмәттән үреп.
Бәхетле гомер кичерер,
Тормыштан рәхәт күреп.

Эш-гамәлен башкарыр ул,
Тәүфыйк яменә төреп.
Бәрәкәтле итеп яшәр,
Барның кадерен белеп.

Дан-дәрәҗә, мал-мөлкәтләр
Бәхетле итми затны.
Хатын-кызга коткы салыр,
Кол итәр ул ир-атны.

Кеше хакы, хәрам байлык
Албасты булып басар.
Нәфес корты кимергәннән
Татлы йокысы качар.

Шат-бәхетле булу өчен
Кирәкми титул, тәхет.
Игелек кыла белүең –
Үзе илаһи бәхет!

март, 2014 ел

Әманәт

Тормыш минем баштан сыйпамады,
Әеп бирде газап-михнәтен.
Тугыз яшьтән инде ятим калып,
Эшләп үстем ирләр хезмәтен.

Күтәрәмнән чыккан атлар белән
Язын йөрдем сука-тырмага.
Көзен кибән, эскертләр салыштым,
Көлтә төяп илттем ындырга.

Кырык дүртнең җәйге челләсендә
Ачлык килде илгә ишелеп.
Барган җирдә мин дә егылганмын,
Хәлем бетеп, ачтан шешенеп.

Аннан соң да җан алучы белән
Кара-каршы килеп очраштык.
Күзне-күзгә төбәп, бар көчемә
Яшәү даулап билләр алыштык.

Күп тапкырлар хаста бәгыремнең
Янып торган шәме түгелде.
Инде сүндем, беттем дигән мәлдә,
Шәм җебенә очкын үрелде.

Нәкъ кырык ел инде йөрәгемдә
"Сайрап" ята күкрәк бакасы.
Борчый калсам, тыным кысып ала,
Баш күтәрә башка хастасы.

Сырхауларны ипләп, дару көйләп,
Кыл өстендә яшәп торышым.
Ялгыш кына читкә тайпылсам да,
Гомеремне чикләр ялгышым.

Аш ашадым, яшь яшәдем диеп,
Шөкерана кылам Аллаһка.
Нәфес колы булып, хәрам җыеп,
Яшәмәдем кереп гөнаһка.

Намусым саф, күңелем пакь булды,
Беркемгә дә зыян салмадым.
Ил-җиремә игелекле булу –
Изге эшем итеп санадым.

Әй, милләттәш! Еракларга карап,
Васыятемне сиңа ашырам.
Милли рухлы татар – мөселман бул!
Халкым әманәтен тапшырам.

ноябрь, 2007 ел

Тартыш

Бер башында бауның – җәһәм золым,
Дөм хөсетлек, мәкер, явызлык.
Бер башында – оят, намус, әдәп.
Явызлыкка алар – авызлык.

Тартыш бара. Җирдә һәр ике як
Тарта бауны бөтен көченә.
Алла ярдәм бирсен бу тартышның
Үҗәтлеген тойган кешегә.

Бу тартышны кеше гомерендә
Тәкъдир кыктән торып кузәтә,
Шушы тартыш безне ялгыштыра,
Хаталарны тартыш төзәтә.

Гадәт белән гадәт, көч белән көч,
Хаклы, хаксыз маллар бүлешә.
Тартыш бара җирдә... Залимнәргә
Ишләсә дә бүген килешә.

Бәлки әле шуңа бу дөньяда
Әдәп-әхлак җиңә алмыйдыр? –
Бәлки шуңа азгын яманлыкны
Тамырыннан йолкый алмыйдыр?

Бу тормышта кем дә читтә түгел,
Шул тартышны тоеп уй корам:
Кай башында бауның син торасың?
Уң башында аның мин торам!

февраль, 2007 ел

Татар язмышы
(Атлар елына)

Дүрт яшемдә битемә ат типкән,
Кырык көнгә миннән аң киткән.
Һәм кырык көн авыл зиратында
Казып куйган кабер-йорт көткән.

Һәлакәткә мине дучар иткән –
Я ратмаска, бәлки, атларны?
Тик сокланып, ихлас күңелемнән
Сөеп гомер итәм аларны.

Балачактан инде җәйге төндә
Болын-тугайларда ат көттем.
Тугры атым белән чик сакладым,
Ташлы сукмакларны мин кичтем.

Әлмисактан бирле төрек телле
Кабиләләр атны – зат иткән.
Атлы кеше – затлы кеше булган,
Ир-ат булып илдә җитлеккән.

Далаларда скиф, һуннар булган,
Кемнәр килеп, кемнәр китмәгән.
Атлар калган офык эргәсендә,
Һәселләре корып бетмәгән.

Атлар белән без дә исән калдык,
Аерылгысыз булып дуслаштык.
Татар – атсыз, ат – татарсыз калып,
Үзебезне әллә югалттык?

Ә бит җәйрәп яткан далаларда
Ата-баба хайван-мал тоткан.
Ғаскынчылар, ач шакаллар кебек,
Калҗа чәлдерергә яу чапкан.

Көтү-көтү утлап йөргән атлар
Каршы алган дошман яуларын.
Әй син, татар! Изге көрәшләрдә
Ияреңдә кала алмадың?!

...Ғәр татарның холык-фигылендә
Дала рухы, атлар хәяты.
Ғез – барыбер атлар нәселеннән!
Җан-рухымда атлар аяте.

декабрь, 2013 ел

Атлар чаба

Атлар чаба, кешнәп аваз сала –
Туган җирләрендә адашкан?!
Койрык чәнчеп чапкан малкайларның
Нәселенә кергән катнаш кан.

Атлар чаба борын заманнардан
Урап-урап таныш юлларны.
Атлар белә – кыргый бабалары
Утлап йөргән дала-кырларны.

Атлар чаба ярсып, томырылып
Урман, елга, күлләр буена.
Ғаярь ирләр ат уйнаткан җирдә
Киллмешәкләр бүген туена.

Тормыш йөген тарткан эш атларын
Котырынып талый ач этләр.
Кыргый этләр... Алар калҗа көтә,
Шул этләрдә – вәхши этлекләр.

Кемнәр анда тышау-богау салып,
Ашсыз тота атлар көтүен.
Атлар сизә: илдә таң атуын,
Каһарманнар килеп җитүен.

Ата-баба яккан учакларның
Гәр тарафта яна утлары.
Ялкын булып аягүрә баса
Җил канатлы татар тулпары.

Атлар чаба далаларны иңләп,
Сабантуйга бара әзерлек.
Мәйдан тотар ярсу атлар кирәк,
Утны-суны кичеп үтәрлек.

26 апрель, 2009 ел

Ат һәм Кеше

Безнең язмышлар, һай, охшаш –
Бу бер дә гаҗәп түгел.
Язмышларны уртаклашкан
Атка тартыла күңел.

Шул ат инде – кеше белән
Дуслашып яши торган,
Кеше дигән хуҗасына
Җанын бирергә торган!

Ат инде ул – узмышларда
Уйнаган яшен ташы,
Шул ат инде – бу тормышта
Кешенең йөзек кашы!

Атлар гел шулай: узышта
Сулышын киңәйткән бит,
Юккамыни халык безгә
Ир-ат диеп әйткән бит?

Атка һәм без – ир-атларга
Беренче булу – канун!
Аллаһ безгә акыл биргән,
Атка – әл-Бәракъ[9] канын.

апрель, 2006 ел

[9] Әл-Бәракъ (Яшен) – Мөхәммәд пәйгамбәрне Мәккә шәһәреннән Иерусалим шәһәренә күз ачып йомганчы илткән ат.

Нигә?

Татар бүген ник чукына?
Кем мәҗбүр итә моңа?
Нигә газиз динен сата?
Чи җитми бүген аңа?

Дошман безне чукындырды,
Канга батырып илне.
Мәселманны тончыктырды
Тутырып елга-күлне.

Татар бүген ник чукына?
Ятларны нигә коча?
Бисмилласыз Идел-йорттан
Милли бәрәкәт кача.

Татар нигә үзен сата,
Сатлык җан – хуҗа малы.
Катнаш гаиләләрдә үсә
Имансыз кызы-улы.

апрель, 2006 ел

Җитәр вакыт...

И, татарым, байтак ялгышлыклар кылдың,
Милләтеңә чөнки син битараф булдың.
Варисларың бисмилласын әйтә белми,
Чукынырлар урыс телле оныкларың.

Синең инде нәсел-нәсәбең дә бетәр,
Оныкларың чиркәүләрдә тәре үбәр.
Үлермен дә котылырмын дип уйлама,
Аллаһыга җавап бирер вакыт җитәр.

июль, 2013 ел

Үзең хуҗа бул!

Уй-фикерең, гамең бармы синең,
Әйт әле син, газиз татарым?
Телсез, динсез, илсез каласың ич,
Бармы синең гаярь улларың?

Үтиләрме ата-бабаларның
Коръән тотып әйткән васыятен?
Дәште-кыпчак, Идел-Йорт җирләре,
Берләшсеннәр булып бербөтен.

Алар скиф, һуннар, хазарларның
Әманәтле туган җирләре.
Шул җирләрдә әби-бабай торган,
Төрки булган ана телләре.

Милләтемнең изге мирасына
Хуҗа булды комсыз бер кавем.

Безнеке ди алар, яулап алган
Ата-бабаларның җирләрен.

Әй син, татар! Даула үз хакыңны,
Орыш-бүлеш барган дөнья бу.
Вакыт җитте: газиз ватаныңа
Син – татарым, үзең хуҗа бул!

Син белеп тор

Булып скиф, булып хәзәр һәм булып һун,
Әби-бабам ил-җир иңләп күргәннәр көн.

Без борынгы алан, бәҗәнәк, сармат та,
Гәр төрки кавемдә каныбыз акмакта.

Мең-мең еллар дала балкып чәчәк аткан,
Дошман килсә, ата-бабам ат уйнаткан.

Чал тарихта мәгълүм мәшһүр исемнәре,
Гәм үзгәрми калган төрки җисемнәре.

Соңрак без болгар, кыпчак дип аталган,
Варислары булып җирдә татар калган.

Шәп саклана төрки хәтер безнең канда –
Без зур халык, без бер төрле, без күп санда!

Мишәр, типтәр, мажгар, нугай вә керәшен,
Кырым, Себер татары, диләр бер ишен.

Аллаһ безне җир йөзенә мулдан чәчте,
Кыйтгаларны урап татар гомер кичте.

Себер, Кырым... Гәммә урталык җирләре...
Идел-Урал – татарларның үз илләре.

Ул җирләрдә түгел без киллмешәк, диаспора...
Ул – борынгы безнең ил-җир, син белеп тор!

Бергә булыйк, бердәм булыйк!

Бергә булыйк, бердәм булыйк, кардәшләрем
"Бердәмлектә – көч" дип әйткән ата-баба.
Җир-күкләрне тоташтырып яңгыр ява,
Дөньяларны иңләп– буйлап сулар ага.

Иксез-чиксез далаларда, ил-җирләрдә
Ат уйнатып гомер иткән төрки-татар.
Яшәгәннәр кыйтгаларны берләштереп,
Тик берләшкән халык бәйсез дәүләт тотар.

Бергә булыйк, бердәм булыйк, милләттәшләр!
Бердәмлектә халкыбызның милли багы.
Җанны-тәнне, күңелләрне берләштерик,
Татар халкы үз дәүләтен барлар чагы.

август, 2013 ел

Дәүләтеңне торгыз!

Хак Тәгалә һәр кавемен сөеп,
Акыл, сәләт, рухи көч биргән.
Дәүләт тотар затлы милләтләргә
Изге вәкаләтләр иңдергән.

Татарга да хәер-фатыйхасын,
Байлыкларын биргән җиһанның.
"Җир-суыңны, ил-халкыңны сакла,
Яклаучысы бул!" – дип инсанның.

Гаярь татар! Сине мәйдан көтә,
Тулпар атың көтә далада.
Дан-шөһрәтле дәүләтеңне торгыз!
Хөр-ирекле яшә дөньяда.

Татар рухы, татар горурлыгы,
Милли хисе җанны яуласын.
Ата-баба ил-җирләрен иңләп,
Азан моңы мәңге яңрасын!

5 февраль, 2008 ел

Кайда ялгыштың?

Кайда болай ялгыштың син, татар?
Аллаһының алдың каһәрен...
Илсез, җирсез, хөрсез яшә диеп,
Сукты мәллә сиңа мөһерен?

Кайда болай ялгыштың син, татар?
Үгънаһсызга кемне рәнҗеттең?
Сабыйларны, бабай-әбиләрне...
Аш-су бирми әллә тилмерттең?

Кемнең каргыш, ләгънәт, бәддогасы
Киртә булды барыр юлыңа?
Исәннәрдән сора ярлыкауны,
Мәрхүмнәргә юлла бер дога .

Тәүбәгә кил, кайт син асылыңа,
Күңелеңне чистарт актарып.
Хак динеңә кайтсаң, Аллаһ сиңа
Ил-дәүләтең бирер кайтарып.

30 март, 2008 ел

Күңел очынганда

Далаларны, чүл, кырларны иңләп,
Төрки егетләре ат чапкан.
Скиф, хәзәр, болгар, кыпчак, һуннар
Кыйтгаларны кочып ил тоткан.

Кемдер әйтер: "Ул заманнар узган,
Кәперәймә, итмә тантана".
Әмма булган алар! Әнә, кемсә
Буллмаганы белән мактана...

Хак варислар – без – татарлар калдык,
Хәтер калды, булып әманәт.
Төрки бабаларның ниятенә,
Әманәткә итмик хыянәт.

Канга – кан, үлемгә – үлем безгә,
Афәтле юл, милли фаҗига.
Яшен яшнәмичә күк күкрәми,
Милләтебез калка, хәл җыя.

Борынгыдан насыйп көлешебез –
Иртыш белән Дунай арасы –
Казаныбыз – илнең башкаласы,
Безгә анда мәңге буласы!

Өмет

Илне-җирне кара болыт каплап китте,
Милләтебез актык чиккә килеп җитте.
Ай, кояшсыз һәм яңгырсыз яшәүләрдән,
Чүлдә үскән кылган сыман корып кипте.

Хак кыйбласын җуйган татар маңкортлары
Толерантлык базарында үзен сата.
Илсез, җирсез, телсез калган шәрә татар,
Хөр-ирексез һәм ваемсыз яшәп ята.

Телен тешләп толерантлык саклый татар,
Икенче сорт халык булып гомер итә.
Ислам динле, ана телле, милли моңлы
Ил-җиребез кануни хуҗасын көтә.

Әби-бабай мең-мең еллар кыр-далада
Кыйтгаларны иңләп-буйлап гомер иткән.
Ил-җирләргә белем һәм мәгърифәт илткән,
Дан-шөһрәте дөнья буйлап ерак киткән.

Без – борынгы скиф, хәзәр дәвамында,
Гүн, бәҗәнәк, сармат рухы безнең җанда.
Шан-дәһшәтле дәүләт-каганатлар тоткан,
Болгар, кыпчак өлеше бар безнең канда.

Әй татарым, нәсел-нәсәбеңне барла,
Аллаһ язган мәңгелегең көтә алда.
Дәүләт тоткан, дәүләт тотар горур халкым –
Башын иләс дошманнарга һичкайчан да!

май, 2013 ел

Төерле татар

Адәмнәрнең төрлесе бар,
Этләрнең дә төрлесе.
Салкын табада сикерә
Татарның "төерле"се.

Динебезне санга суклмый
Тцрәнең эре-вагы,
Шәригатьчә киенгәннең
Эштән куылган чагы.

Яулык япкан кыз-хатыннар
Саруларын кайната.
Этләрнең иң ялагае
Печән өстендә ята.

Инквизатор балта тотып,
Канлы кулын уйната...

июль, 2010 ел

Мокыт турында

Коръән уку мәҗлесенә
Чакырган иде дустым.
Мул итеп сәдака җыйды
Хәзрәт дигән бер мыштым.

Тубәтәй кигән шул абзый
"Хаҗ кылып кайттым", – диде.
Урыс телен вата-сыта
Кысыр сүз, вәгазь өйде.

Тубәтәй кигән артист та
Йөри тамаша куеп.
Ул чукына, ширек кыла,
Образга керәм, диеп.

Сәхнәгә шәрә чыкканнар
Үзләрен "йолдыз" саный.
Кичәге авыл әбие
"Агай" телен сукалый.

Кеше хакы, хәрам белән
Кай татар сәүдә кора.
Кызларны "досуг" йортында
Клиент көтеп тора.

Бер иш татар, акча бирсәң,
Газиз анасын сатар.
Аңа тел дә, дин дә артык,
Чөнки ул – мокыт татар.

февраль, 2009 ел

Татарлык билгесе

Динебез кайта читләрнең
Гореф-гадәтен алып.
Асыл затларыбыз йөри
Милли киемсез калып.

Джинсы чалбары өстеннән
Итәксез күлмәк кия.
Башына яулык урый да,
Мөселман булдым, дия.

Кайда соң асыл күлмәкләр –
Хатын-кыз хозурлыгы.
Чигүле ап-ак яулыклар –
Татарның горурлыгы.

Юктыр баш түбәләрендә
Татарыбыз калфагы.
Калфак – милләтебез тажы,
Дәрәҗәбезнең багы.

Асыл затларыбыз йөргән
Чиккән читекләр киеп.
Сокланып караган халык
Затлылыкка баш иеп.

Безнең әбиләр яшәгән
Мөселман әби булып.
Жаннарында иман нуры,
Милли рух торган тулып.

Инде юк чиккән күлмәкләр, –
Күз яуларын алырлык;
Алъяпкычлар аклыгына
Аккошлар таң калырлык.

Әнкәемнең ак яулыгы
Җырларда гына калды.
Каш ясыйк дип күз чыгардык,
Милләт йөзе югалды.

...Энҗе-мәрҗәнле калфаклар –
Милләтебез өлгесе.
Тарих кичкән ак яулыклар
Татарлыкның билгесе.

Булма гафил!

Гәр кавемдә гыйбадәтле урыннар бар,
Халык барып Коръән укый мәрхүмнәргә.
Искә ала ата-баба үткәннәрен,
Әманәтли бу мирасны бүтәннәргә.

Мөселманның зәм-зәм сулы Кәгъбәсе бар,
Иң мөкатдәс кадерле Мәккә җирендә.
Дөньядагы мөэминнәрне берләштереп,
Саф иманлы өммәт итә һәр төрен дә.

И кардәшем, дөньялыкта яшәгәндә,
Исламның биш фарызын кыл. Булма гафил!
Корбан чалган, ихластан хаҗ кылганнарга
Аллаһының җәннәтенә булыр хак юл.

май, 2014 ел

Вакыт!

Милли җыен – Сабантуе
Мең еллар белән яшьтәш.
Халкыбызның яшәеше –
Гәрвакыт булган көрәш.

Көрәш һаман дәвам итә,
Тик заманалар үзгә.
Ата-бабалар дәүләтен
Торгызу фарыз безгә.

Хөрлек безгә үзе килмәс,
Көрәштә калсак ятып.
Милли рухыбызны барлап,
Мәйдан тотарга вакыт.

Азатлык өчен көрәштә
Милләтеңә бул терәк.
Сабантуйларда сайрашып,
Берләшү безгә кирәк!

Милли корт

Коръән тотып ант итсә дә
"Хак татармын мин" диеп...
Баласының исеменнән
Кеммеген була белеп.

Кайсы халык исмен таккан
Кызына һәм улына.

Ул сатылып, шул халыкның
Әверелгән колына.
Заманга җайлашып яши,
Чәкъ хамелеон төсле.
Ул – татарның милли корты,
Ул мөртәт – икейөзле.

гыйнвар, 2013 ел

Метаморфоза

"Балта биреп шөшле алдым", –
Дип әйткән ди бер юләр.
Юләр дә мөгезле түгел,
Татар шикелле, диләр.

Татар дигән ир-егетнең
Хатыны кяфер-маржа.
Татар исемле кызга да,
Тәреле урыс хуҗа.

Маржаның ире – басурман,
Урыс хатыны – "чапый"[10].
Татар кияү, татар килен –
Аталалар "поганый".

Шул "поганый" килен, кияү,
Урыска хезмәт итә.
Дөньяга урыс үрчетеп,
Бар гомерләре үтә.

Кайда татар горурлыгы,

[10] Чапый – чаплашка сүзен мыскыллап әйтү.

Рухи иман ныклыгы?

Кайда дини әхлагыбыз,
Милләтебез аклыгы?

Юкса, кяфер бу халыкның
Элгәре бабалары,
Ата-баба башын кискән –
Мәсхәрәли уллары.

Халкыбызның канын тыккән
Бу кавем безгә хәрам.
Урыс кармагына капкан
Балаларыбыз әрәм.

май, 2013 ел

Бер кыйтга

Бу кадәрле гамьсез битарафлык
Каян килде сиңа, татарым?
Тараканнар кебек посып калдың,
Шуллмы синең татар булуың?

Юкса скиф, хәзәр, һун бабалар
Безнең кебек денсез буллмаган.
Кыйтгаларны кушып яшәгәннәр,
Ил-җирләрне иңләп буйлаган.

Без аларның кардәш варислары –
Дәвамчысы кандаш токымның.
Синнән, миннән – һәр татардан тора
Яшәеше чорлар халкының.

сентябрь, 2013 ел

Уйлан, Кеше!

Акыл, фикер иясе булса да,
Ләкин кеше мохтаҗ ярдәмгә.
Илаһи зат диеп табына ул
Җансыз сынга, потка, рәсемгә.

Берәүләре үзен "алла" дия,
Сыерга да берәү баш ия.
Табынулар ялган "алла"ларга –
Бидгать гамәл, бозык тәрбия.

Хак Тәгалә рәсем, пот та түгел,
Соры сыер кебек мәхлук та.
Ул мәңгелек дөньяларны төзи,
Сый-нигъмәте хәят кормакта.

Тик адәмнең мөртәт галимнәре
Хакыйкатьне инкяр итмәкче.
Галәмнәргә үзен хуҗа итеп,
"Җир чите"нә барып җитмәкче.

Ә хыялый-акыл ияләре
Двигатель тапмак мәңгелек.
Тумаган һәм тудырмаган Аллаһ –
Тик бердәнбер тере мәңгелек!

Ул илаһи кодрәтенә төреп,
Галәмнәрне юктан бар кылды.
Хак Тәгалә – мәңгелек хәрәкәт,
Хәрәкәттән – яшәү бар булды.

Дин – иманлы, игелекле булсын,
Хәрәкәтләр бирсен бәрәкәт!
Бисмилласыз, денсез кавемнәрне
Хәрәкәтләр итте һәлакәт.

август, 2014 ел

Хисап

Кеше – табигатьнең тажы,
Акыл-фикер иясе.
Гамәлләре өчен аңа
Булыр хисап бирәсе.

Аллаһының кушканнарын
Үтәдеме хак диеп?
Яшәдеме тереклекне
Үзен шикелле сөеп?

Нинди изге гамәл кылды
Хак ислам динен яклап?
Бәлагә дучар бәндәнең
Калдымы берсен саклап?

Канга-кан, үлемгә-үлем –
Гаепсез җаннар кыю.
Дөнья балкып торсын дисәк,
Кирәк нәфесне тыю.

май, 2014 ел

Буталган мәгыйшәт

Гәртөр хайван, балык, кош-кортлар да
Бердәм булып яши дөньяда.
Гәммәсе дә аек, бер-берсенә лаек
Үз кардәше белән һәркайда.

Парлашмый һич карга чәчкә белән,
Эт бүрегә чыкмый кияүгә.
Гәммәсе дә нәселдәше белән,
Бер гаилә булыр яшәүдә.

Ә татарның ир һәм хатын-кызы
Ятлар белән ятак бүлешә.
Халкыбызның милли хәзинәсен –
Мәни орлыкларын өләшә.

Акча бирсә, алар риза булыр,
Ни теләсә – шуны бирергә.
Үзе белән иманын да сатып,
Шайтан куенына керергә.

Күркәм әхлак, әдәп, гореф-гадәт,
Әби-бабаларның сафлыгы...
Татар белән бергә бетеп бара
Борынгының рухи байлыгы.

Үзен сөйгән горур татар идек,
Сыртсыз токым килде аллашка.
Дәүләтебез торгызылган чакта,
Авыз ачып иде калласка.

июнь, 2013 ел

Кемгә нинди бәхет?

Бу дөньяда һәр җан иясенә
Яшәр өчен кирәк өч нәрсә:
Ашау-эчү, торак, кием-салым,
Башкасы да мөһим – кирәктә.

Ризыкны мин инде тугыз яшьтән,
Көтү көтеп, таптым үземә.
Калганнары – яши-яши килде,
Кызыл китермәдем йөземә.

Кирәклесен хәләл көчем куеп,
Эшләп таптым, малга ирештем.
Өч мөһимнең – һәммәсе дә булды,
Нәфес белән чикләр бүлештем.

Мин бәхетле – бар булганым белән,
Булдырганым белән шатланам.
Тыйнак кына фатирымда яшәп,
Хәләл ризык белән тукланам.

Ә берәүләр яши хан-сарайда,
Эче-тышы тора ялтырап.
Талап җыйган хәрам малын кочкан,
Җәза көнен көтә калтырап...

декабрь, 2013 ел

Була – булмый

Гаепне ялганга төреп,
Яшереп калып була.
Мең төрле сылтаулар табып,
Башкага тагып була.

Тик яңа туган баланы
Булмый яшереп калып.
Чыплеккә ташлап китсәң дә,
Кешеләр ала табып!..

Ни өчен яшисең?

Бу дөньяга кемнәр килми,
Кемнәр генә яшәми:
Кем – яшәү кадерен белеп,
Кем үз кадерен белми.

Берәүләр ихлас тырышып,
Дөньяда тормыш кора.
Берәүләр шушы тормышны
Ватып-җимереп тора.

Икесен дә табып-багып
Үстерә ата-ана.
Хәер-фатыйхасын бирә –
Изге теләк юлына.

Буыннарның әманәтен
Бирәләр мирас итеп.
Түкми-чәчми тапшырырга
Варисчыларга илтеп.

Акласын милләтебезнең
Мөкатдәс ышанычын.
Әләмне югары тотып,
Үтәсен үз бурычын.

Игелекле гамәлләре
Ил-җиргә бирсен шатлык.
Яктыртсын караңгылыкны
Дөньяга балкып аклык.

Йә, әйт, кешем! Бу тормышта
Ни максатта яшисең?
Ашар өченме? Әллә соң...
Ил тотып яшәр өчен?!

июнь, 2007 ел

Лаекмы син?..

Халык әйтә: "Тиле таш җыяр" дип,
Оятсызлар хәрам мал җыя.
Әйтерсең, ул мәңгелеккә килгән,
Чәфесенә белми чик куя.

Урлый, талый, канлы акча саный,
Кеше хакы йолкып кинәнә.
Йөзәр, меңәр гектар җир чәлдерә,
Өч аршин җир... җитә үзенә.

Әнә, кош-корт, терлек һәм җанварлар
Көнлек ризык белән көн күрә.
Запас җыймый, зрәгә кан коймый,
Көн биргән Зат җанга юнь бирә.

Дөнья малы – дөньялыкта кала,
Патшалар да берни аллаган.
Элгәреләр акыллырак булган,
Аларның да эзе каллмаган.

Матди байлык череп юкка чыккан,
Инсаннарын җуйган чал тарих.
Мирас булып илаһи сүз калган,
Китапларда калган хак Әлиф.

Әй син, адәм! Уй-фикерле инсан!
Лаеклы син кеше затына?
Барлы изге-дини гамәлләрең?
Кермәдеңме кеше хакына?!

Әй син, Адәм! Санлы акыл заты!
Миллиордермы, фәкыйрьме, ханмы...
Мәхшәр көнне сине җитәкләргә
Фәрештәме, Иблис килерме?!

октябрь, 2014 ел

Зиратларда...

Таладылар... Байлык, мал җыйдылар...
Кешеләрне алар үтерде.
Нарасыйлар меңләп ятим калды,
Кайгы-хәсрәт илгә китерде.

Урладылар... Илне урадылар
Коралланган банда – төркемнәр.
Кан коелды, җаннар кыелдылар,
Югалды шул эзсез кайкемнәр.

Талау, урлау, кыйнау, үтерүне...
Кәсеп итте күрше егете.
Иномарка алды, коттедж салды...
Депутатлык иде өмете.

Терсәк тиен канга баткан кулы
Хөкүмәткә барып тоташты.
Галиҗәнап кебек үзен тотты,
Тик әҗәле белән очрашты.

Зиратларда рәт-рәт тезелгәннәр
Кара йөзле мәрмәр һәйкәлләр.
Әйтерсең лә алар көндәшләрдән
Үч алырга әмер көтәләр.

Буе ике метр бу һәйкәлләр
Күңелләргә курку, шом сала.
Мәетләрнең өрәкләре булып,
Күз алдында кайчак сын ала.

Каннар коеп, җаннар кыеп йөргән
Төркемдәшләр монда җирләнгән.
Кеше талап йөргән бу явызлар
Кара мәрмәр ташка әйләнгән.

Мәетләрнең кабер әйләнәсе
Калын бетон белән төрелгән.
Әйтерсең лә анда Чернобльнең
Атом һәлакәте күмелгән.

Сәясәтнең мескен корбаннары –
Һәфес колы, байлык коллары.
Ике тамчы су шикелле охшаш
Гәммәсенең үткән юллары.

Адәм кылган явызлыклар куктә
Давыл булып айкый Галәмне.
Кочагына ала ул умырып,
Яман юлда йөргән адәмне.

Авыр сүзләр, начар үй-теләкләр
Давылларга куәт, көч өсти.
Кабахәтлек, җаһил икейөзле
Җир йөзендә гөнаһ эш эшли.

Байлык – хәрам маллар белән
Буйсындыра затны шул давыл.
Нәфес колына әйләнә кеше,
Оят-намус калмый бер камыл.

Азгын үйлар аны урап ала,
Булган малы аңа аз сыман.
Дөньяларны кочып аллмак була,
Комсызлыгы ашкан башыннан.

Кан коела, җирдә җан кыела,
Башкисәрнең кулы балтада.
Байлык өчен, тәкәббер дан өчен
Миллионлаган башлар алтарьда.

Корал ясый сугыш чукмарлары,
Галәмнәргә хуҗа буллмакчы.
Ракеталар атып, утка тотып,
Хөр тормышны җирдә бумакчы.

Мәкер белән, хәйлә, ялган белән
Яла яга, ясап мең яра.
Нахак сүзләр, гайбәт тараткаННан
Ызгыш-талаш китә үзара.

Туган белән туган бугазлаша,
Кан дошманнар була кардәшләр.
Алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән өчен
Корбан була якын дус-ишләр.

Зиратларда рәт-рәт тезелгәннәр
Кара йөзле мәрмәр һәйкәлләр.
Әйтерсең лә алар көндәшләрдән
Үч алырга әмер көтәләр.

Кара көчләр, кара энергия
Бу тормышны алган кулына.
Шайтан коткысына бирелгәннең
Келәм җәя барыр юлына.

Комсыз байлар, аумакай тұрәләр
Ил байлыгын тоткан кочаклап.
Бөрәңләре илне уптым сата,
Бөрәңләре сата тураклап.

Каргыш-ләгънәт, рәнҗү хәвеф булып,
Йөзеп йөри илнең күгендә.
Ач-яланғач калган хәерчеләр
Үлем белән яшәү чигендә.

Кеше кылган мондый яман эшләр
Кавемнәрне юкка чыгарды.
Тормыштагы котсыз эш-гамәлләр
Бәла-каза булып уралды.

Бетте илләр, бетте ул кавемнәр
Исемнәре эзсез югалды.
Гыйбрәт өчен, хак кисәтү булып,
Әл-Коръәндә изге сүз калды.

Тик һаман да фани дөнья малы
Һаман уйный курчак уены.
Дан-шөһрәттән башы әйләнгәннең
Бушап кала акыл табыны.

Җирдә тормыш башланганнан бирле
Яман белән яхшы көрәшә.
Эт белән мәче шикелле, алар
Яши аллый торып янәшә.

Фанилыкта берәү байлык җыя,
Хәрам ашап берәү кинәнә.
Ахирәткә буш кул белән килгән
Тәмуг кисәвенә әйләнә.

Зиратларда рәт-рәт тезелгәннәр
Кара йөзле мәрмәр һәйкәлләр.
Әйтерсең лә алар көндәшләрдән
Үч алырга әмер көтәләр.

2 август, 2008 ел

Әй, җир-әнкәм...

Әй, җир-әнкәм, чал башымны иеп,
Мең рәхмәтләр әйтәм мин сиңа.
Аллаһ мине синнән яралткан, ди...
Кайтыр өчен кире куйныңа.

Әй, җир-әнкәм, яшеллекләр иле,
Үсемлекнең иге-чиге юк.
Мәрхәмәтең, сый-хөрмәтең мулдан,
Тирекләрең яши синдә тук.

Әй, җир-әнкәм, синең кочагыңда
Җан-иянең эре, вагысы.
Хозурыңда бар да парлы-парлы,
Зекер әйтә сиңа барысы.

Әй, җир-әнкәм, тиңсез Аллаһ кебек,
Син илаһи, көчле-куәтле.
Ғаләмнәрдә синең кебек гүзәл,
Юктыр җәннәт синдәй зиннәтле?!

октябрь, 2014 ел

Фаҗига

Ғаласының үле гәүдәсенә
Капланган да үкси бер ана.
Улы асылынган бауны селкеп,
Кешеләрне каргый, каргана.

"Кемнәр сине, балам, харап итте,
Ғәгыремнең асыл кисәген?
Ғердән-берем идең..." Ғуе җитми
Тешләр иде ана терсәген.

Агачына күрә алмасы шул,
Анасына күрә баласы.
Агачыннан ерак китми икән
Җиргә төшкән кортлы алмасы.

Ятим үсте, сукбайлыкны кичте,
Ғала артык булды анага.
Ирләр белән эчеп көн үткәрде,
Сөяк-санак ташлап балага.

Ул кирәксез артык кашык булды,
Ишек арты булды урыны.
Көннәр, айлар, еллар буе аның
Өзгәләнде ачтан карыны.

Анасына артык бахыр бала
Үз ишләренә шул иярде.
Урлау-талау кәсеп булып китте,
Яман гадәтләргә өйрәнде.

Төрмә халкын гаиләседәй күреп,
Кат-кат кайтты таныш нарага.
Дәва буллмый хәмер, героиннар
Сабый чакта алган ярага.

Баласының гәүдәсенә багып,
Үзеплене эзли, җан яна!
Тик дөньяда нигә яшәгәнен
Аңлый алыр микән бу ана?

15 май, 2007 ел

Бәрәкәтле хәрәкәт

Күктә ай, кояш балкышы,
Йолдызлар елмаеша.
Җир-күкләр бергә тоташа
Илаһи нурлар аша.

Тоташа җаннар, җисемнәр –
Тормыш шулай ярашкан.
Яшәеш, мәңгелек булып,
Дөньялардан оешкан.

Үй-хисләргә киртәләр юк,
Мәхәббәттә юк ара.
Дөньяларны берләштереп,
Җаннар йөри үзара.

Бәрсе килә, берсе китә –
Яшәеш дәвам итә.
Гыйбадәтле булганнарны
Игезәк тормыш көтә.

август, 2014 ел

Шулай булыр!

Кешеләр дә, җәнлекләр дә яши,
Мең төрле кош оча һавада.
Ләкин алар, комсыз кешеләр кук,
Запас азык тотмый ояда.

Ашау өчен түгел, яшәү өчен
Көн күрәләр җирдә – юнь табып.
Табигатьнең кануннарын тоткан –
Яшәештә кала сокланып.

Ләкин кеше – акыл, хис иясе,
Үлә-бетә байлык бүлешә.
Гәрчә аның, башка мәхлуклардан
Юктыр артык хакы, югыйсә.

Байлык өчен, җир-су өчен кеше,
Үлем чәчә – атып як-якка.
Үзе кебек, миллионлаган затлар,
Башын сала канлы туфракка.

Җирнең астын өскә китерсә дә,
Явызлыгы булыр заядан.
Анасыннан шәрә туган бәндә –
Шәрә китеп барыр дөньядан.

декабрь, 2013 ел

Әгәр...

Кешеләрдә нәфес дигән хаҗәт бетсә,
Туктап калыр иде безнең җирдә яшәү.
Чәчмәс иде, иген икмәс иде кеше,
Булмас иде ясау, төзелештә эшләү.

Бәлкем әле балалар да тумас иде,
Кайгысы да, хәсрәте дә булмас иде.
Бәхет-шатлык, көлү-елмаюларны да...
Сөю дигән ләззәтне дә белмәс иде.

Яшәр иде хайван сыман ашап-эчеп,
Хис-тойгысыз, мәхәббәтсез гомер кичеп.
Битарафлык, ваемсызлык кочагында,
Хәерчелек, бөлгенлек хәленә төшеп.

Нәфес юкта – әхлак та юк, әдәп тә юк,
Тәртип-тәрбия дигәннең – кирәге юк.
Өс-башларың алама, тәнең дә шакшы,
Аяк асты ризыгыннан тамагың тук.

Шуңа Аллаһ адәменә нәфес биргән,
Бу хаҗәтне тик чамалап тот син, дигән.
Булганына шөкер итеп яшәгәннәр,
Аллаһының ике дөнья ямен күргән.

Алгарыш та, яңарыш та – нәфес эше,
Көч-куәте дөнья шарын тәгәрәтә.
Көнчелек, нәфес, хөсетлек тә булмаса...
Яшәп калыр иде кеше мәгарәдә.

август, 2011 ел

Бертуганнар

Сихри-серле, балкып торган нурлы
Күк йөзе дә, кеше йөзе дә.
Күктә – кояш, ай, йолдызлар нуры,
Иман нуры кеше йөзендә.

Күк йөзе дә безнең йөзгә охшаш:
Күзләре бар, кашы, керфеге.
Ястыксыман сәйяр болытлары,
Миң бөртеге, сипкел бөртеге...

Әйтерсең лә алар игезәкләр –
Күк йөзе дә, кеше йөзе дә.
Ә илаһи рухи сыйфатларны
Күктән ала кеше үзенә.

Күкләрнең дә төрле чагы була –
Таплар бар иҗ кояш, айда да.
Кешеләр дә гөнаһ кылмый гына
Яши алмый фани дөньяда.

Яхшы-яман безне сынап тора,
Шулай язган тәкъдир-язмышта.
Күк йөзедәй кеше үзгәрүән,
Алмашынып тора тормыш та.

Балкып кояш чыкса, ай калыкса,
Дөньяларга нурлар сибелә.
Ай-кояшлы йөзләр еллайганда
Шиңеп калган гөлләр терелә.

Табигать тә, кешеләр дә җанлы,
Бер үк безнең фигыль-холыклар.
Табигать һәм кеше – бертуганнар,
Бер Кодрәттән безнең барлыклар.

ноябрь, 2011 ел

Кемдә гаеп?
(Уйнап яки уйлап шаяру)

"Аллаһ теләгән кешесен ялгыш юлга кертә,
теләгәненә туры юл күрсәтә", –
диелә Коръәндә.

Бер илаһи куәт-көчкә бәйле
Тереклекнең җирдә яшәве? –
Лампа янсын өчен, шиксез, кирәк
Трансформаторларның эшләве.

Чиксез Галәмдәге тиңдәшсез зат
Җисемнәргә бирә хәрәкәт.
Зирәк халкым бик тә белеп әйтә:
"Хәрәкәттә, диеп, бәрәкәт".

Илаһи көч, димәк, кабыза да,
Сүндерә дә ала дөньяны.
Изге гамәл белән тулмасаң,
Туктатып та куя ул аны.

Тиңдәшсез зат изге Коръәнендә
Адәмнәргә дәшә: "Колым", – дип.
Бер уйласаң, без аңарга – курчак,
Алдан тышауланган колын бит.

Ничек тели, шулай "күңел ача",
Безнең белән уйный-шаяра.
Тәҗрибәләр ясый, сынау өчен
Яшәү бирә җирдә берара.

Ә беркөнне... Төрле сәбәп табып,
Газраилдән вафат иттерә.
"Суд" буласы котсыз мәхшәр көнен
Газап бирә-бирә көттерә.

Кыска гына бу гомердә яшәү
Бик кыйммәткә төшә түгелме?
Адәм затның монда ни гаебе,
Кем соң яза безгә тәкъдирне?

Бу дөньяда күргән борчу-хәсрәт,
Күз яшьләре хәттин ашкан бит.
Мәңгелектә газап чиксеннәр дип,
Тәмугына ут та яккан бит.

Нинди гөнаһ шомлыклары өчен
Иблисне дә безгә ник таккан?
Туганчы ук инде хөкем итеп,
Ник хокуксыз итеп яралткан?!

ноябрь, 2006 ел

Үз җаенда...

Аллаһ хәрам кылган хайван
Адәмнең холкын белгән:
Дуңгызлыгын иткән дуңгыз,
Аңны икегә бүлгән.

Ул берәүнең – табын тәме,
Сатып файда күргәне.
Ә берәүнең җәһәннәме,
Шайтан малы дигәне.

Ул – галимнәр бәхәсендә,
Ул – дин, ул – фән телендә,
Бик зәхмәтле бер хәшәрәт
Бар ди аның тәнендә...

Бу сүзләр юкка түгелдер,
Бардыр яшерен сере,
Аллаһ тыйганнан тыелу –
Фараз канунның бере.

Тик Адәм дуңгызны тота,
Ашый итен, маен да.
Дуңгызлыгын файда итә,
Дуңгызлык – үз җаенда.

декабрь, 2006 ел

Ялгышты

Денем өчен тукгел, көнем өчен...
Диеп татар дуңгыз үрчетә.
Сарыкларын суеп, тунын ягып,
Бу бичара беткә үк итә.

Дуңгыз ите сатып, хәмер йотып,
Татар кайтып килә, күңеле шат.
Гаваларда торна очып бара...
Кемдер орды башка җан сорап.
Хәрам акча торна булып очты.
Тунын ягып, татар ялгышты.

сентябрь, 2004 ел

Мода корбаннары

Әлифне таяк дип белмәүче,
Почык борнын күккә чөерә.
Үзен бик тә культуралы санап,
Татарлыктан качып йөгерә.

Камиләсен йөри Камилла дип,
Арысланы күрә Русланга.
Милләтеннән йөз чөергән бала,
Әверелә маңкорт дошманга.

Арысланга тиңләп зурлаган бит
Газиз халкым гаярь улларын.
Камил-Камиләләр аша белгән,
Камиллеккә бару юлларын.

Җәза

Билен ачып, кендек чокырын курсәтеп,
Кәттә буллмак кәпрәеп йөргән кызлар,
Ана булып, балалар тапты бер заман, –
Хәмер эчеп, тәмәке тарткан "йолдыз"лар.

Дөньяларны басып китте гарип бала,
Ата-ана арлы-бирле инде чаба.
Бик азлары мескеннәрен дәваларга,
Ил халкыннан хәер сорап, акча таба.

Табигатьнең кануннары кырыс аның –
Үтәмәсәң – җәзасына тарыр җаның.

август, 2012 ел

Тәкъдир

Бер чытлык кәнтәй мактана:
"Кеше көен көйләмим.
Ирем дә юк, балам да юк,
Тик ирсез дә яшәмим".

Картлар йортында бер әби:
"Ялгызым яшәп ардым.
Ирем дә юк, балам да юк,
Кадерсез көнгә калдым".

Аналар күрке

Ат башында чуклы нукта,
Кызлар күзе шул чукта.
Чуклыга кызыга кызлар
Фикерләве сай чакта.

Чит ил кызларына охшап
Кәттә буллмакчы мәгәр:
Яшерен җирләрен ачып,
Үзен "миссис"ка тиңләр.

Мода диеп, яфрак койган
Агач шикелле кала.
Кендек күрсәтеп йөргәннән
Үзенә каза ала.

Хатын-кызны күркәм итә
Кулындагы баласы.
Ихтирамга лаек була
Тик сабыйлар анасы.

Артка таба йөгерү

Яшьлем елны – тычкан урчи,
Коры елны – куян күп.
Монда нинди бәйләнеш бар,
Бәйли моны нинди җеп?

Тычкан күп урчегән елны
Чик илдә туклык була?
Ел коры килгән чакларда
Ил-җиргә куян тула?

Табигатынең сере булып,
Каян килгән бу канун?
Ничек ул җан ияләре
Белә табигать җаен?

Кеше дигән акыллы зат
Мәхрүмме бу өлештән? –
Табигатынең серен белми,
Сабак аллый бу эштән?

Афәт киләсен белсә дә,
Гәлакәтле эш кыла.
Усал, явыз ниятеннән
Ил-җирдә кан-яшь коя.

Талап хәрам мал җыйганнар
Төште гөнаһ базына.
Халыклары кереп батты
Әхлаксызлык сазына.

Мәрхәмәт, шәфкать, рәхимлек
Бу халыклардан китте.
Әдәп-әхлаксыз калганнар
Упкын читенә җитте.

Кыйбласын җуйган дәһриләр
Уйнашлыкта көн күрә.
Кыргыйлыкка таба чаба,
Мәгарәгә йөгерә...

апрель, 2006 ел

Бурыч үтәү

Җирән әтәч тавык, чебиләре белән
Яши иде Орыш дигән авылында.
Чебиләрне берәм-берәм манчыды ул,
Пычрак сулы ишегалды улагында.

"Кикрикүк" дип, тамак ертып аваз салды,
Әтәчләнеп, канат җилпеп, күкрәк какты.
Гәрчәк үзе эшләгән яман этлеген,
Ялган сөйләп, башкаларга яла якты.

Кычкырасың вакытсыз, диеп тавыклар
Баш әтәчне вазифасыннан алдылар.
Ал кикриге ныгып бетмәгән булса да,
Бер әтәчнең башына таҗны салдылар.

Монысы да кетәклеккә хуҗа булгач,
Гайрәтләнеп тирә-якка төкрек чәчте.
Мөстәкыйльлек даулап йөргән әтәчләрдән
Көч кулланып үч алырга антлар эчте.

Кетәклекне дер селкетеп шартлау орды,
Яшь әтәчләр томшыкларын ташта кырды.
Ике якта йолкым-йолкым каурый коеп,
Изге китап тыйган эш-гамәлләр кылды.

Җан иясе золымлыктан зыян күрсә,
Тәкәбберлек белән чыкса талаш-орыш...
Илен саклау, үзен яклау, хакын хаклау,
Дин – исламда һәркем өчен изге бурыч.

май, 2010 ел

Сәрхүшлекне яңгыр юмакчы...

Күкнең йөзен болыт каплап алган,
Шыпырт кына ява вак яңгыр.
Гүәр тарафта шомлы, серле тынлык,
Изрәп калган урман, басу-кыр.

Яңгыр ява, җиргә леп-леп тама,
Җирләр, күкләр гүя тоташтан.
Яңгыр ява, гөрләвекләр ага,
Ике дөнья бергә тоташкан.

Яңгыр ява, күз яшьләре ага,
Яфракларга тама тамчысы.
Күлдәвектә хатын аулап ята,
Җир, күкләрдә хәсрәт ачысы.

Аунап ята хатын... Бергүләрнең
Кадерлесе, әни дигәне.
Мәхәббәтнең сихри алиһәсе,
Кешелекнең энҗе-мәрҗәне.

Яфракларга леп-леп итеп тама
Болытларның ачы күз яше.
Сәрхүш хатын җирдә аунап ята,
Табигатьнең тере җимеше.

Сәрхүш хатын җирдә аунап ята,
Кузгаталмый хәлсез гәүдәсен.
Күзен ача. Күрә: башын иеп
Китеп барган бер ир шәүләсен.

Дәһшәт белән ялт-йолт яшен яшьни,
Җир тетрәнә, күкләр сыкрана.
Фәрештәләр канатларын җәеп,
Сакка баскан хатын янына.

Яңгыр ява, ташны тамчы яра,
Язмышлар да таштай ярыла.
Болытлар да яңгырларын коеп,
Офыкларга таба агыла.

Дөньяларны, кара болыт кебек,
Саранчадай басты сәрхүшләр.
Адәм заты сантыйлана бара,
Сәрхүшләрдән тумый шәхесләр.

июль, 2013 ел

Сабырлык турында

Сабыр гына кояш бата,
Ай-йолдызлар төн ката.
Сабыр гына ал таң ата,
Җир-әнкәгә көн кайта.

Дөнья шулай дәвам итә,
Кем килә, кемдер китә.
Сабырлыгын җуйган затны
Ай-кояшсыз төн көтә.

Ә сабырлар атын җигәр,
Үз юлы белән китәр.
Тәкъдире белән җайлашып,
Барыр җиренә җитәр.

Сабырлык ул аять булып,
Коръәнгә күктән иңгән.
Сабыр булуны бабамнар
Алтыннан өстен күргән.

ноябрь, 2014 ел

Теләк

Картайган саен телисең
Гомерне озайтырга.
Иртән кояшны каршылап,
Кич җиткәч озатырга.

Әҗәл якынайган саен
Яшәү кадере арта.
Үткәннең бар ямьсезлеге
Өзелеп кала артта.

Бәхәс, ызгышлар кубарган
Хәлләр чип булып кала.
Аек акыл, сау фикерләү
Инде өстенлек ала.

Яшәүнең һәрбер мизгелен
Мәгънәләргә төрәсең.
Күңел күзе белән җирнең
Гүзәллеген күрәсең.

Башкалар кадерен белсәң,
Тормыш бәхетле итә.
Изге эш-гамәлләр кылып,
Яшәүләргә ни җитә!

Ләкин... Ләкин кояш бата...
Иртән таң кызмә нурга!..
Картайган саен телисең
Гомерне озайтырга.

февраль, 2009 ел

Яшәеш кануны

Ничә тапкыр инде очрашсак та,
Үзара без таныш булсак та...
Син эшеңне төгәл башкарачак,
Гомер ахры җиткән берчакта.

Дөнья шулай итеп яратылган, –
Һәрбер килгән тиеш китәргә.
Фанилыкта яшәү мизгелләрен
Мәхәббәтле гомер итәргә.

Исән чакта кылган гамәлләрең
Лаек булсын данлы мактауга.
Гасырларны кичәр игелекнең
Бәрәкәтен күреп саклауга.

Яхшылык та, явызлык та бергә -
Янәшәдә бара тормышта.
Икесе дә һәр җан иясенең
Тормыш иярчене буллышта.

Җир-әнкәгә вәкил булып килгән
Кешеләргә акыл бирелгән.
Вәсвәсәдә гөнаһ кылганнарга
Җәза каты булы, диелгән.

Ике юлны сайлау хак-хокукын
Хак Тәгалә затка юнәлтә.
Бирәү хәләл, бирәү хәрам белән
Яшәештә булып көн итә.

Гомер үтә. Әҗәл килеп җитә,
Башкарырга теләп үз эшен.
Адәм заты диеп аталганның
Туктатырга йөрәк тибешен.

Әйе, Әҗәл куркынычлы кодрәт,
Һәркемгә ул беркөн киләчәк,
Һәркем кылган эш-гамәле өчен
Ахирәттә җавап бирәчәк.

Гамәленә күрә сые булыр –
Саваплыкның җаны тып-тыныч.
Сәждә китеп, гыйбадәтләр кылам,
Булмасынга әҗәл куркыныч.

сентябрь, 2015 ел.

Албасты

Бисмилла әйтмәгән булган
Йоклар алдыннан татар.
Дин-догасыз бу бәндәне
Явыз албасты басар.

Борын куышының берсен,
Йә икенчесен каплый.
Тончыга татар – һич кенә
Сулыш алыр җай тапмый.

Авызын томалап куя –
Өне чыкмасын, диеп.
Албасты шат, бу адәмнең
Тынсыз калганын күреп.

Ул терсәктән канлы кулын
Татарга саллмак булды.
Алланың каһәре сукты –
Үзе җан тәслим кылды.

Уянды татар, явызны
Өстеннән алып атты.
Офыкларда нур балкытып
Татарның таңы атты.

май, 2014 ел

Тансыклаган төш

Мин төшемдә таулар гизеп йөрим,
Гаҗәеп бер халәт кичерәм.
Шул төшемне инде ничәнче кат
Кабат-кабат искә төшерәм.

Һавасы саф, рәхәтләнеп сула,
Һәммә тараф серле тынлыкта.
Кояш та юк кебек, ләкин дөнья
Сөт шикелле ап-ак чынлыкта.

Җан-тәнемне тылсымлы наз коча,
Ләззәт алам хискә уралып.
Урманнар сихри кошлар моңы,
Тыңлап торам уйда таң калып.

Үзәннәрне билдән үлән баскан
Чәчәкләре ала күз явын.
Рәт-рәт басып алар каршылыйлар
Табигатьнең кырыс сынавын.

Тау бөркете сыман, ташка басып,
Күзәтәмен таулар тормышын.
Кәүсәр чишмәседәй көмеш сулы
Шаулы елгаларның агышын.

Кышын яңгыр, җәен карлар ява,
Түгелдер бу сәер тамаша.
Таулар урап ак болытлар ага –
Җир белән күк бергә тоташа.

октябрь, 2013 ел

Исеңдә тот!

Өзгәләнмә паспортыңда
Я зыллмаса милләтең.
Асылың кәгазьдә түгел,
Өммәтеңдә кыйммәтең.

Сандугачның милләте юк,
Тик белә һәммә кеше.
Аның моңлы сайравыннан
Гүшсыз кала бер ише.

Дуңгыз да милләтсез калган,
Ул да иселсез-сансыз.
Дуңгыз дуңгыз булып калыр...
Чөнки дуңгыз имансыз.

Мәсьәлә иселдә түгел,
Иң мөһиме – җиселдә.
Милләтең татар икәнен
Гәрвакыт тот исеңдә!

июль, 2013 ел

Синең барыр юл

Ғик борынгы заманнардан алып,
Төрки кавемнәре яшәгән.
Ғиши мең еллар элек татарлар да
Алтай далаларын иңләгән.

Төрки кавемнәре арасында
Ата-баба шөһрәт казанган.
Каһанатлар, бөек Ғолгар илен,
Дәште – кыпчак төзеп дан алган.

Тик таркалган, ханлыкларга калган,
Татар башын гайбәт ашаган.
Тәкәбберлек, хөсетлек, көнчелек...
Татарларны рухсыз ясаган.

Ғертуганнар туганлыктан бизгән,
Чит җирләргә киткән ил ташлап.
Сак, хуҗасыз калган туган җирен
Дошман яулый, илне ботарлап.

Тамырларын агач җиргә җәя,
Кеше илгә җәя тамырын.
Җир үтәли, ил үтәли үтә
Тамырында иле барлының.

Татарның да җирдә тамырлары
Кыйтгаларны урап алганнар.
Тик татарлар исем-җисем җуя,
Милли рухсыз, телсез калганнар.

Телсез милләт, димәк, үле милләт,
Тарих белә андый хәлләрне.
Совет халкы ясап, бетерделәр
Халыклары белән телләрне.

Халык кадәр халык юкка чыкты,
Эче-тышы башка төс алды.
Нурлар бөркеп торган асылташлар
Тарих чоңгылында югалды.

Телсез халык – корбан булыр сарык,
Муенына элмәк эленгән.
Илен, динен, үзен сатканнарга
Аллаһ җәза бирер, диелгән.

Илсез-җирсез, дәүләтсез дә калу –
Аллаһының безгә җәзасы.
Тик Коръәнле халык булсак кына
Булырбыз без дәүләт хуҗасы.

Җиһангир[11] хан, бердәм булыгыз, дип
Васыятен әйтеп калдырган.
Далаларда татар Илбашлары
Илләр төзеп, шәһәр салдырган.

Кан-кардәшләр, кул-аягың булса,
Бармак арасына ит үсми.
Карендәшләр булган кавемнәрнең
Арасыннан яман җил исми.

Үзеңнеке гел үзәктә була,

[11] Җиһангир хан – һуннар юлбашчысы Атилла.

Ай булып ул күзгә күренә.
Дошман белән бил алышкан чакта
Кан-кардәшлек яуда беленә.

Чит-ят кеше үз туганың булмас,
Якын-ерак кавем бер түгел.
Дус-ишләр дә тик таяныр таяк,
Таякларны ташлау бик җиңел.

Кардәшлеккә бүген сынау үтә,
Карендәшләр, төрки кардәшләр.
Калабызны исән, бетәбезме?
Кемнәр дошман, кемнәр үз ишләр?

Бер тырмага баскан бабалар күк,
Мал бүлешеп ятар чак түгел.
Мал-дау, бәхәс, ызгыш сәбәпчесе
Дошманлыкка илтә безне гел.

Мәнфәгатьлек, товар ише булу –
Төркемнәргә бүлә халыкны.
Иманыннан, рухи бердәмлектән
Читләштерә үйсыз халыкны.

Сәүдәгәрләр ярсып байлык җыя,
Түрә халкы илне бүлешә.
Икейөзле сатлык әфәнделәр
Сөяк бәясенә килешә.

Денем өчен түгел, көнем өчен,
Диеп яши акча коллары.
Дине булмаганнар – милләт түгел,
Хуҗа түгел илдә уллары.

Далаларның көч-куәтен җыеп,
Фатыйхасын алып Кукләрнең,
Идел-Йортны дәүләт итү уе
Күңелендә булсын күпләрнең.

Әй син, татар! Асылыңа кайтып,
Табигать күк көчле, горур бул!
Иман, Ислам, дини Әхлак булса,
Мәңгелеккә барыр синең юл.

сентябрь, 2007 ел

Болгар җыенында

Мин изге Болгар җирендә
Гыйбрәтле язмыш күрдем.
Бабамнарның ядкәрләрен
Сыкранып карап йөрдем.

Ун-унбиш гасырлар элек
Төзелгән таш биналар...
Нигез ташлары тараллган,
Ятим калып тораллар.

Чиркәү нигезендә ята
Бабамның кабер ташы.
Әйтерсең, чиркәү чатына
Кысылган бабам башы.

Таланганнан, урланганнан
Тиңсез истәлек калган.
Алар безнең күзгә карап,
Ярдәм сорыйлар сыман.

Ишелгән, ауган диварлар
Тик хәрабә хәлендә.
Ак пулат, кара пулатлар
Горур тора әле дә.

Меңьеллык корылмаларны
Тарих тузаны баскан.
Манараларның башлары
Зәңгәр күкләргә ашкан.

Башларындагы айлары
Иман нурлары сирпи.
Әйтерсең, болгар бабамнар
Сәламләп кулын селки.

Керфекләремдә күз яше,
Күңелемдә горурлык.
Болгарыбызның һәр ташы
Баш бәһасе торырлык.

Изге Болгар җирен ап-ак
Кыр чәчкәләре сырган.
Әйтерсең, басу-кырлары
Ябынган атлас юрган.

Әйтерсең, бабамнар рухы
Чәчкә булып калыккан.
Шәһид киткәннәрнең җаны
Чәчкәләр булып кайткан.

Әйтерсең, алар җилфердәп
Сәламли оныкларын.
Әманәт итеп тапшыра

Меңьеллык орлыкларын.
Миллион чәчкәләрнең таҗын
Талгын җил йөри тарап.
Өйлә намазына басты,
Халык кыйблага карап.

Изге теләкләр багышлый
Ата-бабай илендә.
Илле мең зат сәждә кыла
Изге Болгар җирендә.

Дөньяга сибелгән татар
Болгарга дәррәү килде.
Ата-баба ядкәрләрен
Торгызырга сүз бирде.

Каһарманнар каны тамган
Бу җирләр – изге җирләр.
Сугыш кырында меңләгән
Ятып калган чын ирләр.

Шәһид киткәннәрнең рухы
Шат һәм догалы булыр.
Халкыбыз Болгар җирендә
Иланы һәйкәл корыр.

Без тарихта илләр белән
Рухи байлык алышкан.
Бабаларның гамәлләре
Җир-күк белән тоташкан.

Болгар. 18 июнь, 2011 ел

Аллаһ юлы

Озак еллар хак-хокуксыз калган татар,
Йокымсырап ятлар катасында ятты.
Ул уянды. Тирә-якка аваз салды –
Таралышкан кардәш-туганнарын тапты.

Бөрләштеләр милләтебез әдипләре,
Алсуланып халкыбызның таңы атты.
Алгарышта милли хисе, милли рухы...
Бәрәкәтле тормышыбыз канат какты.

Татарымның сабантуе, җыры-моңы,
Ил-җирләрне сокландыра кызы, улы.
Кешелеккә игелекле милләт булу –
Аллаһының безгә сызган тугры юлы.

Татар булып гомер итү – җиңел түгел,
Сынауларда чыныгадыр милли әһел.
Татар булу – дәрәҗәле, затлы булу,
Горурлыктан балкып тора безнең күңел.

июль, 2011 ел

Ә син беләсеңме?

Уйлан, Кешем!
Нәрсә өчен,
Килгәнсең син бу дөньяга?
Нәрсә кылдың,
Ни кыласың?
Бармы синнән берәр файда?

Бу дөньяда синнән башка
Бөяҗәкләр бар,
Бар җанварлар,
Бар кош-кортлар,
Бар ерткычлар,
Янәшәңдә бар хайваннар.

Бар диңгез һәм океаннар -
Искиткеч зур,
Серле алар.
Һәркайсында яшәү җаннар -
Меңнән-миллион төрле алар.

Һәркемнең бар үз дөньясы:
Кайсы оча,
Йөзә кайсы.
Кайсы җир өстендә йөри,
Тәҗәп җан ияләр барсы.

Һәр тереклек дөньясының
Бар Ходай вазифасы,
Һәрнәрсәнең,
Һәркемнең дә
Бер-беренә бар файдасы.

Әсин, Кешем,
Җир-әнкәдә,
Аллаһының Хак вәкиле.
Синең эш-гамәлләреңдә
Мәхлукларның тормыш хәле.

Сиңа Аллаһ акыл биргән,
Файдасын күр аның, дигән.
Акыл, фикер, уйлы затлар
Яшәеш канунын белгән.

Дөньядагы җан иясен
Бердәй күреп, хөрмәт иткән.
Табигатьнең байлыклары
Яшәр өчен мулдан җиткән.

Тиңе итеп кадерләгән
Җирдәге һәр җан иясен.
Күз карасыдай саклаган
Үсемлекләрнең дөньясын.

Ошбу байлыклар хуҗасы -
Аллаһыга сәҗдә кылган.
Чиксез рәхмәтләрен әйтеп,
Һәрчак гыйбадәтле булган.
...Гомер үтә искән җилдәй,
Җил белән бит син дә бердәй!

О син, кеше!

О син, кеше! Үтә гаҗәп заттыр,
Күркәм сыйфатларны җыйгансың.
Мәңгелектә истә калыр итеп,
Син үзеңә һәйкәл коясың.

Бу дөньяда сиңа тиңдәшләр юк.
Син бердәнбер акыл иясе.
Җир-әнкәдә гыйбадәтле булыр
Аллаһының асыл нөсхәсе.

Әдәп-әхлак, тәртип кәлимәсе
Язмышыңа анык язылган
Гамәлләрең ихлас булсын өчен.
Сиңа белем, гыйлем хас булган.

Хак Тәгалә һәр кавемгә атап,
Үз холкына ярак тел биргән.
Үй-хисләрен яңгыратыр өчен,
Күңелләрдә сихри моң ургән.

Беркемдә юк синдәгедәй серле
Күз карашы, көлү-елмаю.
Болар бар да Аллаһ нигъмәтләре:
Бәхет-хәсрәт, шатлык-моңаю.

Хак Тәгалә сине төгәл, камил,
Могҗизаи итеп яраткан.
Үй-фикерле, хикмәти затына
Муллык биргән азык-ризыктан.

Тик шулай да, син тәкәббер затсың,
Масаясың, борның чөясең.
Инкяр итеп Аллаһ кушканнарын
Җан-тәнеңә гөнаһ өясең.

Син үзеңне мәңге яшәр кебек,
Кодрәт ияседәй тоясың.
Үзең ише адәмнәрне талап,
Үлә-бетә байлык җыясың.

Саташкан бер залим аркасында
Миллионлаган җаннар кыела.
Нәфесләре туймас ач күзләрдә
Биниһая байлык җыела.

Бар да кала. Череп юкка чыга
Хуҗалары - Аллаһ каршында,
Һәр мыскалы өчен җавап тоту
Кирәк булыр тәмуг утында.

О син, Кеше! Аң-акыл иясе,
Бөрәкләрең синең – асыл зат.
Бөрәкләрең – байлык колы булган,
Кеше төсен җуйган кәбахәт.

Шул денсезләр, яралганнан бирле,
Риза булмый Аллаһ ашына.
Кан-яшь коя, хәрам мөлкәт җыя, –
Кешелекнең җитәр башына.

июль, 2015 ел.

Хак Тәгалә кирәк кадәр итеп,
Адәменә биргән акылны.
Чикләмәгән яшәү рәвешен Ул,
Ләкин җуйма, дигән, асылны...


لله
رب العالمين


الله جل جلاله
الذي يشفع الملائكة بين يديه
محمد عليه السلام
بسم الله الرحمن الرحيم
عمر ابو بكر رضي الله عنهما
عثمان علي رضي الله عنهما
حفظها الله العلي العظيم

IV бүлек

ПОЭМАЛАР

Аллаһка мәдхия

I

Дөньяларны иңләп давыл купты,
Бөтерелде утрау тузаны.
Күккә ашты, туфрак өермәсе,
Хасил булды диңгез казаны.

Томырылып искән шашкын җилләр
Җирнең өстен алды умырып.
Су төбеннән Дәҗҗал күтәрелде,
Ут-ялкынын аска томырып.

Күк күкрәде. Яшен кылычлары
Тишеп үтте күкнең гөмбәзен,
Көн яктысын кара болыт япты,
Караңгылык йотты Җир йөзен.

Исрафиллы сур бургысын өрде?
Утрау очты булып түгәрәк.
Асты-өскә килеп капланды ул,
Утраудан калды тик тумгәк.

Үле диңгезнең шул урыны
Батып калды өч йөз метрга.
Адәмнәргә Аллаһ гыйбрәт өчен
Әйләндерде аны чокырга.

Диннән, деннән, юлдан язганнарга
Хак Тәгалә бирә җәзасын.
Искәртә ул гөнаһ кылганнарның
Иң газаплы җәза аласын.

Бу дөньяның тормыш серләренә
Адәм балаларын өйрәтә.
Индереп ул изге китапларын
Пәйгамбәрләр аша сөйләтә.

Җәннәт кебек гүзәл Җир-Анада
Әйтә ничек яшәү кирәген.
Кушканнарын үтәп яшәүченең
Кабул кылыр һәммә теләген.

II

Адәми зат әйтерсең лә сукыр,
Әйтерсең лә чукрак, ишетми...
Аллаһ биргән ачы гыйбрәтләрдән
Нәтиҗәләр ясап эш итми.

Ул тыңламый Җирнең ыңгырашканын,
Күрми хаста хәлдә яткынын.
Байлык өчен барган сугышларның
Ярасыннан каннар акканын.

Ул битараф, гамьсез, ул ваемсыз,
Күңел күзе аның дөм сукыр.
Җир-Ананың җаны чыгар итеп,
Җәфалады инде күп тапкыр.

Җир өстендә, булсын җир астында
Гәлакәтле корал сынала.
Дәһшәт белән аның шартлавыннан
Яшәү тына, хәят югала.

Умырыла, җәрәхәтләр ала,
Гүзәлләрдән гүзәл Җир-Ана.
Әйтерсең лә изге эш кылалар –
Адәмнәре итә тантана.

Кемнәр саклар, кемнәр яклар Җирне,
Ил сөймәсә аны, ир какса?
Кем Анасын усал рәнҗетер соң, –
Хөрмәт итсә, аны яратса?!

Елга-күлләр, урман һәм болыннар
Агуланды йөзәр елларга.
Нурланышның яман авыруы
Ябырылды басу-кырларга.

Чернобльнең нурлы балкышыннан
Меңәрләгән кеше чир йотты.
Җир җимертеп яшәр, эшләр халык
Кабер дәрьясына юл тотты.

Ләкин кеше – аңлы җан иясе
Афәтләрдән гыйбрәт аллыйдыр...
Ничә тапкыр Җирдән сөрелсә дә,
Тик бу аңа сабак буллыйдыр.

Сыкраулары һаман арта барган,
Ишетми ул Җирнең авазын.
Яман эшләр белән якынайта
Гәлакәтле тормыш азагын.

Ул үзенең Җиргә вакытлыча
Килгән икәнлеген оныта,
"Табигатьтән хәер көтмибез" – дип,
Аслы-өсле аны корыта.

Кемдер тишеп, бик тирәнгә төшеп,
Газын, нефтен аның суыра.
Кемдер өстен, сихри гүзәллеген
Урлый, талый, ерта, умыра.

Кемдер казый, гәүһәрләрен ташый,
Ташкынмерен өскә чыгара.
Йолыкканда үзәк тамырларын
Түземлеге каллмый чыдарга.

Ут-табага салып кыздырылган
Сызык сыман булып кала ул.
Гүя сират күперендә тора...
Әзелмәсме икән нечкә кыл?

Тыны бетә, шашар хәлгә җитә,
Калтырана бөтен гәүдәсе.
Вакыт-вакыт якты йөзен каплап,
Үтә кебек үлем шәүләсе.

Көчсез, гаҗиз, кимчелекле кеше –
Явызлыкта аңа тиңнәр юк.
Акыл белән яшәр тиеш затның
Бер нәфесен тыяр егәр юк.

Җир ялварып якты күккә бага,
Ярдәм сорый тиңсез Алладан.
Миңа хуҗа иткән колың – Адәм
Алдады – ди, сине яңадан.

Җәннәттә ул алма өзеп капты,
Колак саллмый Синең сүзеңә.
"Чир китсә дә, гадәт китмәс", – диләр,
Гадәтсезлек һаман үзендә.

Көне-төне саулыгымны талый,
Кат-кат кисәтүгә карамый.
Азгынлыгы үз башына җитәр,
Актык чиккә җитү ярамый.

Бер-беренә ачу, канлы җилек,
Каян килгән кеше холкына?
Бер-берләрен өзгәләргә әзер
Череп бетәр байлык хакына.

Бер ишләре алтын, асылташлар...
Миллиардларның булды хуҗасы.
Ахирәттә ләкин байлыгымның
Адәмнәргә юктыр нужасы.

Ә берәүләр (алар миллионнар!)
Ачлы-туклы гомер кичерә.
Аналарны, сабый балаларны
Саран байлар ачтан җтерә.

Ихтыярсыз, аң-акылсыз кеше
Була аллый хикмәт иясе.
Акыл чиген нәфес узып китсә,
Хәрам малның төшә бәясе.

Җир-Ананың дәгъва, моң-зарлары
Күк әһелләренә иреште.
Җирнең хәлен, тормыш, көнкүрешен
Өйрәнергә күкләр кереште.

Агач чапсаң – йомычкасы оча,
Гөл утыртсаң гына гөл үсә.
Күңеленә коткы кергән адәм
Шайтан капкынына бер төшә.

Гәм җәннәттән сөрелгән бу Адәм
Шайтан коткысына бирелеп,
Яши изге кануннарны бозып,
Күз яшенә, канга төренеп.

Аяныч хәл кҧргән фәрештәләр
Сөрән салды, калды шаккатып.
Диде алар: "Бу Адәмне Аллаһ
Хаталанды бугай яралтып."

Ґҧзәлләрдән гҧзәл бу изге җир
Агуланган, йөзе каралган.
Кҧл-диңгездә, океан төпләрендә
Яши торган затлар югалган.

Әйтерсең лә Яэҗҧҗ-мәэҗҧҗ йөргән –
Җирнең астын, өстен актарып.
Дала-кырлар, шан шәһәр, авыллар
Өнсез-җансыз калган таптылып.

Кҧркәм гадәт, әдәп, саф сыйфатлар
Онытылган, исраф ителгән.
Эчҧлелек, азгын фахишәлек
Әхлаксызлык канун ителгән.

Ил башында алтын, асылташлар
Илләр, җирләр калган имансыз.
Көче барның – канун ҧз кулында,
Акчасы юк кеше – ул җансыз.

Ґаләмнәрнең бер хуҗасы – Аллаһ
Әһелләрне дәште янына.
"Ґәлак итмә адәмнәрне", – диеп,
Фәрештәләр сыктап ялына.

"Ак ат менгән, ак җиләндә итеп,
Иңдерегез безне яңадан.
Адәмегез кҧндәм тормыш башлар...
Туган кебек Мәрьям анадан".

Давыл купты. Тузан өермәсе
Күккә ашты, каплап кояшны.
Илаһи көч Җирдән йолкып алып,
Ап-ак болыт итте тау-ташны.

Җир тетрәде. Дулкын күтәрелде,
Ярсу ташкын алга ыргылды.
Дәҗҗал токым Галн кылычыннан
Куз ачып йомганчы кырылды.

Җир-Анабыз тынып, торып калды...
Мәһди килде иман, хак алып.
Галәмнәрнең гүзәл бер почмагы
Азгынлыктан калды бушанып.

III

Аллаһ тиңсез кодрәт, көч иясе,
Яралткан ул җанлы-җансызны.
Иксез-чиксез Галәмнәрдә гизгән
Ай, кояшны, миллиард йолдызны.

Ул – хуҗасы җирдә тереклекнең,
Галәмнәрдә барган тормышның.
Тик Аллаһның кул ихтыярында
Төп нәсхәсе һәрбер язмышның.

Аллаһ мәшһүр, тиңсез идарәче,
Көч, хәрәкәт биргән җисемгә.
Галәмдәге барлык нәрсәләр дә
Сәждә кыла Аның исемгә.

Иксез-чиксез Галәм киңлекләрен
Кочып алган Аның егәре.
Шул егәрнең камил төгәл эшен
Үти һәрбер җисем күләре.

Җисемнәрнең тизлек хәрәкәте
Микрон үлчәмнәрдә ярашкан.
Барысы да үз юлында йөри,
Юк адашкан, юк бер саташкан.

Монда тәртип, һәрбер нәрсә белә,
Төгәл үти фарыз гамәлен.
Тик бер Аллаһ үзе генә белә
Галәмнәрнең йөреш әмәлен.

Бу серләрне белү, төшенүләр
Бирелмәгән Адәм затына.
Тырышса да, керә алмас фәннең
Ишерелгән серле катына.

Аллаһының гыйльми тәгълиматы
Синдә, миндә – барлык нәрсәдә.
Бер күзәнәк теректән башланган
Галәм дигән серле әсәрдә.

Миллиардлаган йолдыз, йолдызчыклар
Күк йөзендә балкып җемелди.
Әллә Аллаһ куәт, кодрәтеннән
Курыкканга шулай дерелди?

Кешене дә шулай куркыталар,
"Курык! – диләр, – Тәңре – Аллаһтан!"
Тик аңардан курку мәҗбүриме?
Әллә кирәк курку – гөнаһтан?

Аллаһыны яратырга кирәк,
Ул илаһи, ул тик бердәнбер.
"Гыйбадәтле булса, сәждә кылса, –
Җәннәтемә дигән шул керер".

Ярышырга кирәк Аллаһының
Хәер-фатыйхасын алуда.
Мәрхәмәтен күреп мәңгелектә
Сөеклесе булып калуда.

Хак Тәгалә рәхмәт-шәфкатьле зат,
Кирәкмидер аннан куркырга.
Тиңсез нурын, көч-куәтен тоеп,
Хак мөселман булып калырга.

Куркак җаннар – сатлык җаннар бит ул,
Мохтаҗ түгел Аллаһ аларга.
Мохтаҗ түгел потлар, рәсемнәргә,
Буй сындырып торган колларга.

Үзле кызыл балчыктан бар итеп,
Адәменә акыл, хис биргән.
Яратылган уттан иблистән дә,
Нурлы фәрештәдән хуш күргән.

Галәмнәрнең акыл, рух хуҗасы
Адәменә гашыйк бәгырьле.
Мәрхәмәтле, ул рәхим-шәфкатьле,
Гәр мәхлүкат аңа кадерле.

Барысын да аталарча саклый,
Аналарча кыла тәрбия.
Галәмдәге барча әйберләрне
Ул ярата, бердәй Ул сөя.

Ул ишетә, күрә, сизгер тоя
Гәрнәрсәнең күңел халәтен.
Гәркем Аның ярдәменә мохтаҗ,
Гәрчак көтә рәхим-шәфкатен.

Иксез-чиксез галәм киңлегендә
Ғез белмәгән җаннар яшидер?
Ғәлкем, бардыр безнең ишеләре,
Кешеләргә, бәлкем, охшыйдыр.

Ғолар әле Аллаһының сере,
Адәменә әле билгесез.
Аның рөхсәт-фатыйхасы булса,
Инша Аллаһ, бәлкем, белербез.

Аллаһның юк тәрҗемәи хәле,
Ул тумаган һәм Ул мәңгелек.
Тик мәнсезнең, тәкәббернең моңа
Җитми акыл, юктыр белемлек.

Ерак бабам маймыл булган, диеп
Адашкан ул юллар чатында.
Аң-акылы җитми фикерләргә
Җанвар булган маймыл хакында.

Маймыл булган маймыл булып кала!
Коръән әйтә алар – кешедән.
Азгыннарны Аллаһ мәхрүм иткән
Кеше булып җирдә яшәүдән.

Ғу мескен дә Аллаһыны эзли:
"Күргәнем юк – дия, беркайда...
Күренмәгән затка табынудан,
Ғыйбадәттән миңа ни файда?!"

Искән җилне, био-магнит кырын,
Чыбыктагы көрми токны да...
Алар бар ич! Димәк, Аллаһ та бар!
Ғар иткән ул барлык юкны да.

Бар итә ул безне – адәм затын
Мәни орлыгыннан карында.
Кеше мәңге яшәр өчен килә...
Уй, хис, акыл җанда барында.

Бар иткән ул барча мәхлукатны
Табигатьне бай һәм җай итеп.
Җирдә, суда, саф һавада яши
Җан иясе уңай хис итеп.

Безгә җансыз, аңсыз кебек булган
Үсемлекләр, таулар, диңгезләр...
Аллаһыга дога, сәждә кыла,
Зекер әйтә булып изгеләр.

Гәм кеше дә Хаксыз яши аллмый,
Тора аллмый ансыз тормышта.
Туу, яшәү, үлем һәм мәңгелек
Аллаһ белән бергә буллмышта.

Адәменә Аллаһ яшәр өчен
Бар кирәген мулдан булдырган.
Якты биреп, җылы булсын диеп,
Ай, Кояшны күктә бар кылган.

Үсемлекләр белән җирне бизәп,
Хайван, җәнлекләрен җибәргән.
Гәрберсенә бер вазифа йөкләп,
Барысына торыр җир биргән.

Җир өстендә һәр җан иясенең
Бар хокукы, бар хак өлеше.
Яшәр ризык, торыр оясын да
Хак Тәгалә үзе бирмеше.

Һәрберсе дә үз җаенда яши,
Урын-җиргә булып чын хуҗа.
Җирдә яшәү, тормыш барсын өчен,
Бер-берсенә алар бер калҗа.

Хуҗа итеп, бер калҗа итеп тә
Аллаһ безне сөеп яралткан.
Вакыт-вакыт барча тереклекне,
Үсемлекне кабат яңарткан.

Күкләр белән, чиксез Галәм белән
Бу тормышны шулай көйләгән.
Җир-Ананың сихри гүзәллеген
Юктыр җирдә шашып сөймәгән?!

Кем гаҗәпкә калмас, кем сокланмас
Күреп күкнең нурлар балкышын?!
Таң алдында алсу офыкларда
Яшәешнең сихри чаглышын!

Ал таңнарны мактап моңга каплап,
Һәр тарафта кошлар аһәңе.
Болын-кырлар тыңлый һуштан язып,
Чишмәләргә бирә бәһане.

Шаян җилләр бер мәл тынып кала,
Тал-тирәкләр башын игәннәр.
Үрә торып таңны каршы ала,
Дулкынланмый кырда игеннәр.

Тажын ачып гөлләр чәчәк бөрки,
Гүзәллеге күзне яндыра.
Гади генә кебек үсемлекләр
Сокландыра, таңга калдыра.

Безгә гади кебек күренгән һәр
Орлыкларда яшәү көче бар!
Туфрак, кояш, һава, яктылык, дым –
Тормыш өчен уңай шарт ясар.

Галәмдәге барлык могҗизалар –
Аллаһының тиңсез кодрәте.
Гүзәллеген, камиллеген әйтер
Сүзләр дә юк, юк тел куәте.

Аның изге гамәлләрен күреп,
Рәхмәт әйтә дөнья Аллаһка.
Җир-Ананың күркәм сыйфатлары –
Аллаһ сыйфатлары булмакта.

Аллаһ үзен һәрчак таныттыра –
Көне-төне кыла игелек.
Барлыгына Аның бу – хакыйкать,
Хакыйкатьтә яши мәңгелек.

IV

Адәменә үзен танытырга
Хак Тәгалә аңа җан өргән.
Илаһи рух, Илаһи җан белән
Адәменә акыл, хис биргән.

Ул Адәмен гүзәлләрдән-гүзәл,
Иң шәрәфле итеп яраткан.
"Галәмнәрдә син мәңгелек орлык
Булырсың" – дип җиргә тараткан.

Үзен юктан бар итүче Көчкә
Кеше мәңге булыр бурычлы.
Җавап тотар Аның каршысында
Үтәгәнен әйтеп бурычны.

Кануннарын, яшәү тәгълиматын
Адәменә әйтеп иңдергән.
Зәбур, Тәүрат, Инҗил, Коръәнне Ул
Пәйгамбәрләр аша күндергән.

Ислам динен иң дөрес дин итеп,
Мәңгелеккә биргән кешегә.
Ислам дине – Ул Аллаһ илчесе,
Үлем-китем юктыр илчегә.

Ислам дине – Аллаһының нуры,
Иман нуры – Ислам әхлагы.
Адәмнәрне азгын-явызлыктан
Саклар өчен куйган йозагы!

Ислам дине – Аллаһ изгелеге,
Мөселманга, иңгән игелек.
Үтәр өчен Аллаһ әмерләрен
Кирәк иман, ихлас динлелек.

Ислам дине – Аллаһ күрсәтмәсе,
Иман аның изге ноктасы.
Ул Аллаһның нуры чагылышы
Туры юлның асыл уртасы.

Белем, акыл, ислам нигезләре
Безгә биргән әхлак нигъмәте.
Ислам дине – Аллаһ хакыйкате.
Гич югалмас аның кыйммәте!

Ислам динен, рәсүл – пәйгамбәрне
Хур-мәсхәрә итә денсезләр.
Рәсем ясап, террорчы дип атап,
Я ла яклак була мәнсезләр.

Асылташка, энҗе-мәрҗәннәргә
Сафалтынга керле тап төшми.
Алар мәңге үзе булып кала,
Алар пычрак белән керешми.

Күпме генә яла яксалар да,
Ислам дине үсә, киңәя.
Рәсем түгел, җисем ясасыннар,
Пәйгамбәргә булмас киная.

Ислам дине хак дин, саф дин булып
Заман ахырына барачак!
Дәһри яклар, мәртәт мәшрикләр
Үзләре үк көлке калачак!

"Изгелекләр, игелекләр кылып,
Ярышыгыз", – дия Бөек зат.
Ислам дине мәңгелек хакыйкать,
Хак Тәгалә үзе хакыйкать.

Адәмнәргә аның тыйганнарын,
Кушканнарын үтәү – фарыз эш.
Кыл хәерле, игелекле эшләр,
Изге гамәлләргә син кереш!

Адәми зат! Жуйма акылыңны,
Кабартма син күкләр ачуын.
Кабарганның шартлау гадәте бар,
Мөмкин буллмас аннан качуың.

Бу дөньяда син тик кунак кеше,
Кунакларга тыйнак булу хас.
Бер ожмахтан инде син куылдың,
Нәфесеңне тыя алмагач...

Җир тормышы – ул тик сынау чоры,
Фәрман килер, аннан китәрсең.
Ғаләмнең күрә йә оҗмахны,
Йә тәмугны йортың итәрсең.

Җир гомере кыска, ул тиз үтә,
Күзең ачып йомган мизгелдә.
Әле шыта, әле чәчәк ата...
Әле шиңә булып үле дә.

Җир тормышы шулай тәмамлана,
Мәңгелеге аның башлана.
Җирдә үткән тормыш мизгелләре
Килеп баса Аллаһ каршына.

Чинди алар, кайсы кыяфәттә?
Иман нуры бармы йөзендә?
Ерткычлыгы, яман-явызлыгы
Чагыламы әллә күзендә...

Алла хакын, Ана, кеше хакын
Яшәгәнме хаклап дөньяда?
Мохтаҗларга ярдәм, рәхим-шәфкать
Күрсәткәнме булып зыяда?

Ана хакы – хакларның да хакы,
Җир-күкләргә тиңдер өлеше.
Шул өлешнең ни икәнен белми,
Кешеләрнең әле бер ише.

Кешелекнең соңгы пәйгамбәре
Хак сүз әйткән хаклык хакында:
"Җәннәт, – дигән, – безне тапкан, баккан
Аналарның аяк астында".

Аналарның аяк асты җирдә
Гомер итә барча тереклек.
Туфрагында үсә тереклеккә
Яшәү өчен бөтен кирәклек.

Аналарның аяк асларында
Аллаһының Җиргә бирмеше.
Без Җир дигән, бәлкем, җәннәттер ул?
Бәлкем аның лапас өлеше?..

Әгәр җаннар мәңге тере икән,
Кайта булыр җиргә әйләнеп,
Сөйлиләр иң җирдә яшәүләрен
Күп гасырлар элек без, диеп.

Аллаһының рәхмәтләре чиксез,
Кыладыр ул моны гыйбрәткә.
Тик ул гына, тик илаһи бер зат
Ия мондый тиңсез кодрәткә.

Җир-анага кире кайткан затлар,
Бәлки, алар изге җаннардыр?
Бәлки бакый дөнья урынына
Фанилыкны сайлап алгандыр?

Бәлки изге, игелекле затлар
Мәңге шулай урап йөридер?
Бәлки, җирдә инде берничә кат
Яши булыр туып кемнәрдер?..

Барысы да Хак Тәгалә сере,
Мәгълүм түгел Аның хикмәте.
Әби-бабай җаны оныгының
Яшәсә дә булып җефете.

Каннар, җаннар буын-буыннарга
Тапшырылып, бәлки, барадыр?
Изге җаннар кайткан нәсел-нәсәп
Җиргә хуҗа булып каладыр?!

Юкка гына охшамаган булыр
Җиде буынгача балалар...
Әби-бабай, ата-ана холкын
Каннар, җаннар аша алалар?!

Барысы да Аллаһ кодрәтендә,
Ул теләсә – юктан бар була.
Җисемнәр дә әнә бүлгәләнә,
Кайберләре янып юк була.

Гөнаһ кылган ерткыч, явыз җаннар
Китә булыр утлы Галәмгә.
Бер Аллаһка иман барлау фарыз
Җәннәт әһле булыр Адәмгә.

Аналарның аяк асларында
Туфрак булыр ихлас фәһемле,
Үз анасын, изге җир-анасын
Сөйгән Адәм – җәннәт әһеле.

Никадәрле мәрхәмәтле булсын,
Миһербанлы булсын җир-ана,
Аяк сөрткән, хур-мәсхәрә иткән,
Аллаһ газабына абына.

Кыерсытып, җирнең йөзен ертып
Йөргәннәргә гафу булмастыр.
Фанилыкта кылган явызлыгы
Басар аны – булып албасты.

Рәнҗетелгән ана күз яшьләре
Әверелер туфан көченә!
Явызлыгы мең кат яман булып,
Кайта булыр кире үзенә.

Җәрәхәтләп малын талаганга
Җир-анабыз сала җәзасын.
Афәт биреп, әле һәлак итә,
Әле юллый бәла-казасын.

Без күкләргә карап ышанабыз,
Хыялларда аңа ашабыз.
Тик без шушы җирнең хуҗалары,
Монда безнең тормыш ашыбыз.

Күккә карап, гүзәл җирдә яшәп,
Әзерләнә кеше оҗмахка.
Арынып ул хата-гөнаһлардан
Өмет баглый әһле булмакка.

Кеше зәгыйфь итеп яратылган,
Ул җитешсез тик гүр иясе.
Мәңгелек җан чыгып, күккә ашкач,
Иясез дә кала гәүдәсе.

Җир гомере – ул кыска тереклек,
Киләчәгә аның билгесез.
Үлгәч кенә кеше яшәр, диләр,
Мәңгелектә булып үлемсез.

Куенына алган җир-анага
Башны иеп, шөкер җиткерик.
Тапкан-баккан газиз аналарның
Кадерләрен белик иң элек.

Тик шул чакта Аллаһ мәрхәмәтен,
Мәхәббәтен бирер адәмгә.
Аналарның хәер-фатихасы
Ахирәттә килер ярдәмгә.

Әниләргә игелекле булу –
Дәрәҗәли адәм баласын.
Аллаһыга гыйбадәтләр кылсаң,
Җәннәтендә урын аласың.

V

Адәми зат фани бу дөньяга
Булып килә мөэмин-мөселман.
Иконага, потка табынганнар
Адаштыра аны юлыннан.

Кукрәү-тетрәү, җирне су басулар,
Җил-давыллар, ташкын дулкыннар...
Җир убылу, ай-кояш тотылу,
Гәлакәтле утлы ялкыннар...

Кеше дигән акыл иясенә
Курку сала, аңын сүндерә.
Будда кебек ялган "алла" ларга
Табынырга аны күндерә.

Ләкин ул зат нинди көчкә ия,
Галәмнәрне төзи алганмы?
Потлар булып, әллә сыннар булып,
Таш санәмнәр булып калганмы?

Кемнәр алар үзен "алла" итеп,
Йә пәйгамбәр диеп атаучы?
Адәмнәрнең соңгы мал-мөлкәтен
Секталарга җыеп талаучы?

Ялган алла, ялган пәйгамбәрләр
Ширекъ булган яман эш кыла.
Инсаннарның башын әйләндереп,
Үзе "алла" буллмак ул була.

Аз түгел шул җирдә шарлатаннар,
Меңәрләгән ялган "аллалар".
Акча эшли динне кәсеп итеп,
Үләксәче ала каргалар.

Мәҗүсилек заманыннан калган
Кыргый йола, гореф-гадәтне,
Кәсеп итә алар канлы-яшьле
Вәхшиләрдән калган сәбәпне.

Бидгать гамәл кылып алданганнар
Корбаннары ялган "алла"ның.
Мәңге тере булыр Хак Тәгалә –
Тик Алласы тере җаннарның.

Кешеләрдән корбан сорамый Ул,
Бу гамәлне гөнаһ күрсәтте.
Руза беткәч, корбан чалыр өчен,
Тояк малны фарыз ул итте.

Хак мөселман рәсүл Ибраһимга
Куй җибәрде Аллаһ корбанга.
Кеше канын кою, җанын кыю
Үзенә дә хата булганга.

Муса, Гайсә, Ибраһим, Мөхәммәт –
Илчеләре алар Аллаһның.
Әйтер өчен тиңсез илаһи Көч,
Тик бер Аллаһ кына барлыкның.

Пәйгамбәрләр Аның вәкилләре,
Тиңгел Аллаһ, тиңгел потлар да.
Тиңгел алар Аллаһ уллары да,
Гиҗ кенә дә изге рухлар да.

Тик бер Аллаһ тиңсез илаһи зат,
Ул тумаган, тудырмаган да.
Ғаләмнәрнең бер хуҗасы булып,
Мәңге булыр шулай һаман да!

Мәңгелек җан да Аллаһка мохтаҗ
Мохтаҗ аңа үлән, ташлар да.
Мохтаҗ аңа барлык җан иясе,
"Мин аллаһ" дип йөргән башлар да.

Адәмнәргә илаһи зат кирәк,
Аллаһ кирәк җанын сафларга.
Җаннар белән иңгән исламның да
Асыл сыйфатларын сакларга.

Хак дин кирәк, ихлас иман кирәк
Хаклыгыңны хаклап торырга.
Аллаһының фатыйхасы белән
Бу дөньяда тормыш корырга.

Хак дин кирәк. Ул әдәп-әхлакны
Шифалаучы зәмзәм суыдай.
Тик иманлы, динле җәмгыятьнең
Бөтенлеген саклар бер Ходай.

Хак дин кирәк безгә тану өчен
Яхшылыкны золым, яманнан
Потка, сынга табынган адәмне
Арындыру өчен ялганнан.

Хак дин кирәк безгә белү өчен
Үсемлекнең канун дөньясын.
Иксез-чиксез Галәмнәрдә булган
Серле-сихри җисем дәрьясын.

Белү кирәк, ихлас сөю кирәк
Табигатьне, туган төбәкне.
Үзеңә тиң итеп күрү кирәк
Юл аркылы чыккан бөҗәкне.

Безне чолгап алган һәрбер нәрсә
"Бул!" дигәннән пәйда булганнар.
Җир йөзендә барлык җан ияләр,
Бәлки, безне көтеп торганнар?..

Җилләр исеп, болыт алып килеп,
Яңа икән шулчак яңгыр, кар,
Җир йөзендә яшәгән мәхлукнең
Гүя тамчыда үз өлеше бар.

Гүзәл җир-ананың
Табынында ризык җыябыз.
Кунак булып, тыйнак булсак кына,
Тату торсак кына сыябыз.

Гүя үсемлек, иң вак бөҗәкләр дә
Акыл җитмәс серле могҗиза.
Гаепсезгә бер җан коелса да,
Кайтавазы булыр мең җәза.

Барыбыз да Аллаһ тарафыннан
Яралтылган газиз җаннар без.
"Рәхмәтеңнән, шәфкатеңнән, Аллаһ,
Ташлама!" – дип, сәҗдә кылыйк без.

Догаларны, изге гамәлләрне
Багышласак кына без исән.
Җир-анабыз үксеп рәнҗер безгә,
Юкка чыкса хәтта бер сүсән.

Табигатьнең ярсып котыруы –
Адәмнәргә катгый кисәтү.
Табигатьнең кырыс кануннарын
Кисәтүләр аша күрсәтү.

Борынгылар кулын билгә куеп,
Кануннарын җирнең бозмаган.
Вәхшиләрчә талап, байлык санап,
Газ юллары күккә сузмаган.

Чиксез Галәм, Җир-анабыз, Адәм –
Аллаһының иҗат җимеше.
Без, кешеләр, шушы җимешләрнең
Иң кадерле гүзәл өлеше.

Җисемнәрнең хәрәкәтен Аллаһ
Камил төгәллеккә көйләгән.
Һәр җисемнең, һәр җан иясенең
Язмышларын бергә бәйләгән.

Җанын-тәнен, аң-акылын да Ул
Бәйләгәндер җир-су белән дә.
Кылган эшен, аның уй-ниятен
Алар белә тулы күләмдә.

Яхшысын да, яманын да күреп,
Алар бергә гомер кичерә.
Яманлыкны яхшы җиңмәк була,
Тик яман да көчле үчегә.

Җирдә тормыш башланганнан бирле
Яхшы яман һәрчак көрәштә.
Яхшылыкны танып белер өчен
Яманы да кирәк янәш тә.

Адәменә мәңгелеккә диеп,
Бирсен аңа Аллаһ егәрлек.
Саклап кына исраф итә белсә,
Ахирәткә кадәр җитәрлек.

VI

Хак Тәгалә кирәк кадәр итеп,
Адәменә биргән акылны.
Чикләмәгән яшәү рәвешен Ул,
Ләкин җуйма, дигән асылны.

Һәрнәрсәнең чик-чамасы була,
Чик-чамасын җуйсаң, ул тула.
Акылсызга тулу, ташып агу
Табигый хәл булып тоела.

Кайберәүләр чыгырыннан чыгып,
Байлык туплый, аңа табына.
Башы-күзе ак-караны күрми,
Ач нәфесе уттай кабына.

Өермәдәй үткән юлларында
Хәрабәләр кала тырпаеп.
Кайгы-хәсрәт, күз яшьләре һәм дә
Басу-кырлар ята шыр калып.

Бу адәмнәр Аллаһ кануннарын
Үтәмәүче затлар, әлбәттә.
Мәлгунь шайтан коткысына тарып,
Байлык колы булган халәттә.

Канлы-яшьле бу аяныч хәллəр
Зур үсешкə, бəлки, сəбəптер?
Йокымсырап яткан адəмнəрне
Уятырга шулай кирəктер?

Ач торулар, борчу-мəшəкатьлəр
Ризык кебек бəлки кирəктер?
Тук яшəүнең, тынычлыкның кадерен
Афəт аша кеше белмəктер?

Нəрсə өчен яратылган кеше,
Яхшы-яман фани дөньяга?
Лəкин кеше талап яшəр булса,
Əйлəнсен ул ташка – кыяга!

Игелекле гамəл кылган затның
Йортында тор булып нигезе.
Канлы-яшьле хəрам байлыклардан
Файдалырак шул таш берүзе.

Башкисəрлəр аң-акылын җуя,
Хəзинəдə күрə бəхетне.
Үзе туйса, аның күзе туймый,
Туймас күзе күрми ləхетне.

Яши-яши, тормыш итə-итə,
Акыл җыя, кеше сынала.
Аермаса акны карадан ул,
Караңгыга төшеп югала.

Фахишəлек, сəрхүшлектə булсаң,
Җир-күкләрнең бармы гаебе?
Адəм рəтле яшəү өчен кирəк
Җан теләге, күңел таләбе.

Тормыш – көрәш. Ул аяусыз
Яхшы белән яман көрәше.
Гәр юлчыга цзеннән дә яхшы
Булу кирәк янда иптәше.

Аллаһының рәхмәтләре чиксез,
Тик ул белә хәлләр сәбәбен.
Гәр һәлакәт, фаҗигале афәт
Савыктыра кеше халәтен.

Тик хәрам мал бәхет китермидер,
Китермидер хаксыз сугышлар.
Кешелекне мәңгелеккә илткән
Рухиәттә асыл бәхет бар.

Иң зур байлык – рухи байлык, диләр,
Изгелекне кылмау әҗәткә.
Инсаннарның йөзе балкып торыр,
Байлык цзе калыр гаҗәпкә.

Аек акыл томаланмасынга
Хак Тәгалә җанга нур сала.
Ислам нуры булган изге нурдан
Мөселманнар рухи көч ала.

Ак нурлардан җаны-тәне балкый,
Ул нур – Коръән, иман нурыдыр.
Аллаһ нуры булган ул нурларның,
Балкышларның хакы олыдыр.

Шул тылсымлы сихри балкышларның
Нуры көләч җирнең йөзендә.
Кояш, йолдыз, айның балкышлары
Кеше гамәленең цзендә.

Җир өстендә бөтен нәрсә үсә,
Тереклекне сөеп җил исә.
Кояш нуры, айның яктылыгы...
Барысы да бушка, югыйсә.

Аллаһ тыйган гамәлләргә кеше
Сихерләнеп нигә үрелә?
Баштанаяк гөнаһларга бата,
Хаталарга кереп күмелә.

Бул син, кешем, исемеңә лаек!
Битарафка булма битараф.
"Ашау – байдан, үлем Ходайдан", – дип
Яшәүчеләр, әнә, һәр тараф.

Ваемсызлык аркасында кемдер
Табигатьнең талый байлыгын.
Табигать күк кырыс та бул, Кешем!
Бел, аның да хакы барлыгын.

Әдәп-әхлак, күркәм холык, гадәт
Бу дөньяның тормыш күңәре.
Ата-баба, әби-әниләрдә
Бу сыйфатлар булган элгәре.

Юктан бар итүче бер Аллаһка
Кылган алар ихлас гыйбадәт.
Гәм безгә дә дини кануннарны
Үтәү булсын фарыз бер гадәт!

июнь, 2006 ел

Санәм – идол.
Ширекъ кылу – үзеңне Аллаһка тиң кую.
Инсан – кеше.
Бидгать – гөнаһ




خير الرحمين

Иң югары бәһа
(Шигъри вәгазь)

I

Тәүге тапкыр Биләр мәчетендә
Аллаһ сүзен бабам ишеткән.
Кодрәтле һәм күркәм ул авазны
Күңеленә алып беркеткән.

Илаһи нур иңгән җан-тәненә,
Йөзләренә – иман балкышы!
Аллаһыдан иңгән хакыйкатьне
Изге иткән Коръән яктысы.

Игелек кылу, изге бу гамәлләр
Алып килгән бәхет ил-җиргә.
Әдәп-әхлак, тәртип һәм тәрбия
Бала-чага, хатын һәм ергә.

Болгар даны ерак илләрдә дә
Иң югары алган бәһане.
Кәрваннарны Идел буйларына
Җәлеп иткән Коръән аһәңе.

Далаларны иңләп яңгыраган
Мәзиннәрнең моңлы азаны.
Ахыргача хак мөселман булып
Яшәү безгә – Аллаһ язганы!

Аллаһының нуры, иман нуры,
Коръән нуры татар йөзендә.
Үз кадерен, дан-шөһрәтен белгән –
Татарлыгын саклый үзендә.

Ул һәрвакыт горур һәм тәвәккәл,
Кыю атлый хөрлек юлыннан.
Бил алыша көрәш мәйданында
Чыгар өчен коллык чорыннан.

Ул – фидакарь, ул – каһарман татар,
Мал-байлыкка сатлый намусын.
Һәфес колы, корсак колы түгел,
Дәвалаучы милләт ярасын.

Миһербанлык ана сөте белән
Гадәтенә кергән сабыйдан.
Хәләл көчен түгеп тормыш итә,
Үрнәк алмый "өлкән абый"дан.

Ул хезмәттә тырыш, булсын диеп,
Җаен белеп эшли һәр эшен.
Гәр нәрсәгә кулы ятып тора,
Гәр тарафта таба үз ишен.

Тик гыйбадәт кылып яшәгәннең
Бәрәкәтле булыр дәвамы,
Аллаһының кушканнарын үтәп,
Милләтенә табар дәваны.

Иман нуры, Ислам, Ихсан нуры
Көч-куәт, дәрт бирә татарга.
Шәригатьнең изге кануннарын
Фарыз иткән безгә тотарга.

Коръән-хәдисләрдән белем алып,
Яшәү, эшләү безне коткарды.
Бары Коръән аша хакыйкатьтән
Аерырга мөмкин юк-барны.

Коръән хөкемнәре һич өзелмәс,
Аллаһ безгә биргән аркандыр.
Бәрсак тотып ошбу аркан очын –
Бәхетле һәм якты юл булыр.

Шушы хакыйкатьне яхшы белгән
Безнең дини әби-бабалар.
Гүәм бүген дә асыл варислары
Кыйблабызны саклап баралар.

II

И татарым! Буыннардан килгән
Әманәткә итмә хыянәт!
Намаз һәм дә барча гамәлләрең
Аллаһыга булсын гыйбадәт!

"Изге Коръән кеше ахирәткә
Әзерләнсен өчен бирелде.
Аның белән гамәл кылганнарга –
Фирдәвес җәннәте", диелде.

Иңдерелде Коръән тереләргә,
Ул – мөэмин-мөселман кануны.
Яшә, кыл гыйбадәтләр Коръәнчә,
Булырсың Аллаһның якыны.

Коръәндәге сүрә, аятьләрне
Адәми зат аллмас үзгәртә.
Төп китапта язган, саналганнар
Кыямәткәчә калыр үзәктә.

"Әйт, – диде, – Аллаһ, изге Коръәнне
Мөхәммәд чыгарган димәсен.
Әгәр ышанмый икән берәрсе,
Бирәр яңа сүрә китерсен".

Тик кяферләр Аллаһ сүрәсенә
Кәлимә сүз өсти аллмады.
Әмма Инҗилне алар үзгәртеп,
Нәсарый диннәре ясады.

"Мөселманнар, сез – Ислам өммәте!
Бүленмәгез төрле юл китеп.
Курыкма син изге ахирәттән,
Ал мәңгелек аны йорт итеп.

Аллаһының дусты булып яшәү –
Мөэмин-мөселманга бәрәкәт.
Намаз – иң зур Аллаһ зекередер,
Иманлы бул, кыл син гыйбадәт.

Намаз – диннең йөрәге һәм башы,
Намаз кылган нурлы булырлар.
Барлык мәхлук бер Аллаһка гына
Иманланып сәҗдә кылырлар.

Юк булсын монафикъ! Баш тартса ул
Чын мөселман булам диюдән.
Булырсың үзең дә син монафикъ
Кяфер белән дус-иш йөрүдән.

Катнаш гаиләләрдә туган бала
Ике диннән мәхрүм җан-шытым.
Иман белән гамәл, җан белән тән –
Алар икәү генә бербөтен.

Динсез милләт – мал-мөлкәтсез келәт,
Әдәп-әхлаклы да булалмый.
Динсез гаилә, динсез тәрбия дә
Асыл затлы нәсел бираллмый.

И татарым! Бөек, Гүн токымы!
Ким-хур булуларың бик җиткән.
Кяферләрне Аллаһ ләгънәт итте,
Сатлык җандыр аны дус иткән.

Йә, Аллаһым, "Бул!" дидең дә, мине
Кызыл балчыгыңнан яраттың.
Җир-Ананың гүзәллеген күреп,
Гашыйк булдым аңа, яраттым!

Йә, Аллаһым, бар һәм барлегеңне
Таныр өчен Күккә караттың.
Дөньяңның мин камил төзелешен,
Төгәллеген күреп шаккаттым.

Йә, Аллаһым, Кодрәтеңне күрдем,
Акыл җыйдым, карап йолдызга, –
Җирдә үскән һәрбер үсемлегең, –
Кеше аңы җитмәс могҗиза.

Йә, Аллаһым, мең-мең рәхмәт Сиңа
Хис, мәхәббәт, сөю биргәнгә.
Гаилә корып, сөеп һәм сөелеп,
Бу дөньяңда хәят күргәнгә.

Йә, Аллаһым, эш һәм гамәл бирдең,
"Яхшылык ит! – диеп, Кешегә.
Изге ният белән кылганнарың
Игелек булып кайтыр үзеңә".

Йә, Аллаһым, биреп күрсәтмәләр,
Канун китаплары индердең.
Гыйбадәтләр кылыр, сөйләр өчен
Гәрәп кавемгә сөйкем тел бирдең.

Йә, Аллаһым, Адәмеңне сөеп,
Зиһен бирдең аңа, аң-белем.
Җәннәт ишекләрен ачар өчен
Изге китап – Коръән иңдердең.

Йә, Аллаһым, шул китабың ача
Ике дөньяңның да ишеген.
Ғәрбер сүрә, аять, догаларың
Юлламасы җәннәт иленең.

Йә, Аллаһым, һәр эш-гамәлемә
Бисмилламны әйтеп керешәм.
Көч-кодрәтле бер Илаһым, Сиңа
Гыйбадәтләр кылып баш иям.

Дөньялыкта белеп, белми кылган
Хата-гөнаһларым ярлыка.
Ышанамын үлеп тереләсенә,
Җәннәт, тәмугларың барлыкка.

Иксез-чиксез Галәм киңлегендә
Мәхшәр көне булыр, "суд" көне.
Бер-бер артлы үтәр күз алдыннан
Ғәр адәмнең тормыш иткәне.

Ришвәт биреп, сыйлап, майлап-җайлап,
Котыла алмас аннан берәү дә.
Хөкем кырыс булыр, ләкин дөрес,
Яхшы-яман ятар үлчәүдә.

Мәңгелек һәм мизгел – ике дөнья,
Акыл биргән Аллаһ аңларга.
Уңда аклык, сулда – кер, бозыклык,
Ике юлның берсен сайларга.

И син, бәндә, Аллаһ кушканнарны,
Кануннарын үтәү фарыздыр.
Коръән-Кәрим сызган туры юлдан
Баруыңда иман хак булыр.

Раббыбыздан иңгән китапларда
Яшәешнең асыл мәгънәсе.
Изге эшләр эшләп, гамәл кылсын
Дөньялыкта Алла бәндәсе.

Җиһан халкы көн-төн мәетенә
Юлласа да гамәл багышлап.
Тик үзенең гамәл дәфтәрендә
Язылганын алыр кушучлап.

Йә, Аллаһым, көн-төн булган кебек,
Явыз бәндәләр дә яраттың.
Гөнаһ булган начар гадәтләрне
Кавемнәргә биреп тараттың.

Йә, Аллаһым, нәфес колларына
Хәрам бирдең, хәмер йоттырдың.
"Ни кыласаң, шуңа ирек", – диеп,
Кулларына кылыч тоттырдың.

Йә, Аллаһым, Син фатыйха биргән
Юлбашчылар ярсып котырды.
Елга булып ага изге каннар
Гәм һаман да хаклык оттырды.

Йә, Аллаһым, гыйбрәт алыр өчен
Афәт бирдең денсез кавемгә.
Утка ягып, суда һәлак иттең –
Миллионлаган керде кабергә.

Йә, Аллаһым, сөйгән Адәмеңне
Азгынлыкта нигә йөртәсең?
Тәмуг ягып, гөнаһ ияләрен
Мәхшәр мәйданында көтәсең?!

Йә, Аллаһым,үзең чик куймасаң –
Адәмнәрең шашып азынды.
Әдәпсезлек, әхлак-гадәтсезлек
Тозагына кереп абынды.

Йә, Аллаһым, Сиңа табынганны
Мәхрүм итмә рәхим-шәфкатьтән.
Ғаләмнәрнең энҗе бөртегедәй
Җир-Ананы итмә җәһәннәм.

Йә, Аллаһым, беруҡ исеңдә тот!
Җир исемле Ғаләм валчыгын.
Шул валчыкта ыгы-зыгы килгән
Адәм дигән кызыл балчыгын.

Йә, Аллаһым, күпме зарлансак та,
Бу дөньяңнан килми китәсе.
Бөтен начар гадәтләрдән арынып,
Җирне иде җәннәт итәсе.

Йә, Аллаһым, кеше гомер буе
Кайгы-хәсрәт кичеп уздыра.
Ләкин якты, нурлы бу дөньяңны
Бер күрүе үзе ни тора!

Йә, Аллаһым, ризалыгың өчен
Ғамәл кылулары күңелле.
Җир-анабыз кебек игелекле,
Мәрхәмәтле кеше күңеле.

Йә, Аллаһым, бирмеш һәр көнеңне
Шөкерана кылып каршылыйм.
"Төнаһ-хаталарым гафу ит?" – дип,
Төзеремне сиңа багышлыйм.

Йә, Аллаһым, төгәл, гүзәл хуҗам,
Рәхмәтеңнән берүк ташлама.
Мәңгелектә тәүге көннәремне
Тәмуг газабыннан башлама.

IV

Яшәүнең асылы шулдыр:
Якты дөньяга килеп,
"Сөбханаллаһ!" – дию, Җирнең
Ямь-гүзәллеген күреп.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Җирдәге сый-нигъмәткә
Шөкерана итә-итә,
Җир-ананы сөймәктә.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Юктан бар итүгә,
Лә иләәһә илләллаһу,
Дибез Хак Тәгаләгә.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Динле, иманлы булу.
Аллаһ бар һәм берлегенә
Намаз, гыйбадәт кылу.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Тапкан, баккан анаңа,
Кирәксә, җаныңны да бир!
Бурычлы һәркем аңа.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Әтиең-әниеңне,
Гомер буе сый-хөрмәттә
Яшәтү газизеңне.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Барның рәхәтен күрү.
Эшләп тапкан хәләл малның
Хуҗасы була белү.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Изге кәсеп кылуда.
Малның зурлыгында түгел,
Бәрәкәте булуда.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Намуслы тормыш сөрү.
Гомеркәйнең ахырынача
Яшәү кадерен белү.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Туйлы-никахлы булу.
Сөйгәнеңә, туганыңа
Тугрылык саклап калу.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Күркәм гаилә кору.
Гәркем сокланырлык итеп,
Яратып тату тору.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Ил-җиргә хезмәт кылу.
Балаларга, оныкларга
Яхшыдан үрнәк булу.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Милли нигез булдыру
Тамыры мөселман булган
Нәсел-нәсәп калдыру.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Нәселең ерак китсен.
Хәләл гамәлеңнең көче
Җиде буынга җитсен.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Ир белән хатын бердәм,
Фатыйха бирсен яшьләргә
Исламлы йортка тирдән.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Варис булып калганнар,
Күз карасыдай сакласын
Әманәтне алганнар.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Мохтаҗга ярдәм итү,
Изге эш-гамәлләр кылып,
Гомер ахырына җитү.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Яхшылыкның чиге юк.
Яман нәфесең тыйлыйча
Ялгыша күрмә, бирүк.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Җәннәт әһеле булу.
Аллаһ рәхмәт-шәфкатендә
Мәңге яшәүдә калу.

Яшәүнең асылы шулдыр:
Аллаһ кушканны үтәү.
Рәхмәтләренә ирешеп,
Аңа хакыңны түләү.

V

Кешелекнең акыл ияләре
Сорау бирә һаман үзенә:
Ул Адәмме, әллә маймыл дәвамымы,
Кем мөһерен суккан йөзенә?

Маймыл булса, миллиард ел элек
Бик катлаулы чорлар, юл үткән.
Бер күзәнәкле җан үсә-үсә
Кеше дигән затка җитлеккән.

Ләкин болар бар да теория,
Галим Дарвин әйткән сүз генә.
Иксез-чиксез Галәм киңлегендә,
Бәлкем, түгел фәкать без генә?

Фәнгә, техникага һич билгесез
Мең-мең сорау әле җавапсыз.
Кем хуҗасы шушы Галәмнәрнең?
Гаилә дә буллмый хуҗасыз.

Маймыл бүген маймыл булып кала,
Үзгәреш юк һичбер нәрсәдә.
Нәсел башы маймыл булу белән
Килешмидер барча кемсә дә.

Фәннәрнең дә үсеш дәрәҗәсе
Алла барын-югын әйталмый.
Сәяхәттән кайткан космонавтлар
Иланы зат бар дип тәкърарлый.

Үзем, шәхсән, нәсел-нәсәпләрне
Адәм-Хәва, димен башлаган.
Хак Тәгалә фатыйхасын алып,
Ир һәм хатын җирдән атлаган.

Бу ике зат кулга-кул тотынып,
Дәверләрне үтә бергәләп.
Аллаһ һәрчак алар калебендә,
Гыйбадәттә алар чыгәләп.

Аллаһының бар һәм берлегенә
Иманым нык, һич тә юк шигем.
Аның рәхмәт, шәфкать, кодрәтләре
Ача-яба язмыш ишегем.

Ул саклаучы, яклаучы да безне,
Гәрбер эше өстен, хикмәтле.
Намаз укып, дога кылганнарга
Мәрхәмәтле, юмарт, хөрмәтле.

Ул патшасы барлык җисемнәрнең,
Тереклекнең җирдә, күкләрдә.
Аның рухы бөтен тарафларда,
Синдә, миндә, яши күпләрдә.

Ләкин юктыр гәүдә төзелеше,
Рәвеше дә, калып-сурәте.
Ул кемгәдер охшаш зат түгелдер,
Юктыр ашау-эчү гадәте.

Йоклы һәм ял белмәс. Гәрчак уяу,
Армаган да булыр, талмаган.
Берәүне дә үзе тудырмаган,
Берәүдән дә үзе тумаган.

Күрмәсәк тә Аны, ләкин Ул бар,
Искән җилләр дә бит күренми.
Без иснәгән һавалар да төссез,
Анда атомнар да йөгерми.

Галәмнәрне күзгә күренмәгән
Биоэнергия ураган.
Ул илаһи кодрәт иясе дә
Тудырмаган һәм дә тумаган.

Тик алар бар. Гәрчәк хәрәкәттә,
Ният, гамәлләре – хезмәттә.
Шөкерана кылып яшә, Кеше!
Аллаһ вәгъдә иткән җәннәттә.

V

Тик онытма! Аллаһ ризалыгы
Өчен диеп гамәл кылырга.
Уразасын тотып, зәкят биреп,
Бисмилла әйтеп корбан чалырга.

Аллаһ олуг, Мөбарәк һәм Бөек...
Дәрәҗәсе тиңсез, мактаулы.
Аннан пакь һәм саф зат һич тә юктыр,
Чуры гүзәл, исеме дан-шанлы.

Хак Тәгалә – акыл җитмәс камил
Илаһи көч, кодрәт иясе.
Ахирәткәчә Аның ниндилеген
Гичкемнең дә юктыр беләсе.

Иманың нык, җаның изге булса,
Аллаһ нуры иңәр йөзеңә.
Мәрхәмәтле Рахмән дөньялыкта,
Рәхим бирер җәннәт үзеңә.

И син, Адәм! И син Кызыл балчык!
Яшә дингә иман китереп.
Гыйбадәт кыл һәм бул игелекле,
Җаның кайтыр җиргә әйләнеп.

"Без, – ди, – Аллаһ, – байлык, сәламәтлек,
Яхшылыклар сезгә юллыйбыз.
Ачлык, сырхау кебек яманлыклар
Җибәреп тә сезне сыныйбыз".

Мин дә үттем ошбу сынауларны,
Хозурыңа барып чак җитте.
Дүрт яшемдә битемә ат типте,
Кырык көнгә баштан аң китте.

Җиде яшьтә бата-калка актым,
Бозлар белән язгы ташуда.
Черек бәрәңгеләр, башак җыйдым,
Кар сулары ерып басуда.

Адаштырып, әфган җирләренә
Күз ачкысыз буран ташлады.
Йә Илаһым, үз рәхмәтең илә,
Бер ут алдан бара башлады.

Барган хәлдә трамвайдан сикерү,
Китереп салды юлның өстенә.
Ыжгырып узган мәлдә вагоннар,
Утыра идем рельс өстендә.

Утыз биш ел йөрәк бакасыннан,
Экземалардан да интегәм.
Йә Аллаһым, бир хәерле гомер,
Шөкерана кылып, баш иям.

Аллаһ ураза гаете көнне
Бу дөньяга мине китергән.
Үзе теләгән кешесе итеп,
Тугры, дөрес юлга күндергән.

Гомерем буе Аның якынлыгын,
Мәрхәмәтен тоеп яшәдем.
Йөземне ак, җанымны пакь итәр
Эшләр булсын диеп, эшләдем.

Хаталардан кеше хали түгел,
Яхшы-яман аша сынала.
"Анаң карынында да, – дия, – Аллаһ,
Үзеңне гөнаһсыз санама".

Гафу итәм – диде Аллаһ берәү,
Тәүбә итеп, кылса гыйбадәт.
Кабатланмаса гөнаһ хаталы
Яман булган әгәр бу гадәт.

Хак Тәгалә ризалыгы өчен
Диеп башкар изге эшләрең.
Китаплар анасы – Ләүхелмәхфүз
Теркәр яхшы-яман гамәлең.

Адәменә Аллаһ ирек кылды,
Акыл нигъмәтләрен мул бирде.
"Хәләл көчең белән тапканыңның,
Игелеген үзең күр" – диде.

Дөньядагы һәр җан иясенә
Хак Тәгалә бурыч йөкләгән.
Мөселманның фарыз гамәлләре
Коръән, хәдисләрдә әйтелгән.

Туу, яшәү, сөю, фани дөнья –
Мәңгелекнең мизгел арасы.
Кулга тотып гамәл дәфтәрләрен
Аллаһ каршысына барасы.

"Лә иләәһә илләллаһу" безне
Тәмуг газабыннан чит тотар.
Мөселманның йөзен Ислам нуры,
Аллаһ нуры, иман балкытыр.

Дин кардәшем, кан кардәшем, без бит
Мөхәммәд пәйгамбәр өммәте!
Җир-Ана гүзәлләрнең гүзәле,
Гүзәллерәк Аллаһ җәннәте.

Язмышка нәсыйхәт
(поэма)

Язмышлар тудырмый ялгышны,
Ялгышлар тудыра язмышны.
Зөлфәт

I

Бу тормышның, гаилә кормышның
Серләренә буллмый төшенеп.
Шуңа кеше афәт, фаҗигане
Язмышына куя күчереп.

"Язмышлардан узмыш юк", – ди кемдер,
Кул кушырып яши, таптана.
Ялгышларын, гөнаһ-хаталарын
Язмышына сылтап аклана.

Язмышым дип, акламакчы үзен
Кеше талап, урлап йөрүче –
Барчасы да: сәрхүш, хәерчесе,
Тәнен сатып гомер сөрүче.

Берәүләрнең, әнә, тәкъдиренә
Ауга-яуга язган йөрергә.
Чәкъ шундыйлар күпме илне-җирне,
Калдырдылар кара күмергә.

Алла аңа, имеш, җан өргәндә
Барыр юлын куйган билгеләп:
Илбасарга үткен кылыч биргән,
Җан кыярга диеп, йөз-меңләп.

Ләкин Аллаһ кеше үтерүне
Котсыз һәлакәткә тиңләгән.
Дөньялыкта изге гамәлләр кыл,
Җәннәтемә ачкыч шул, дигән.

Изге Коръән – язмыш күрсәтмәсе,
Гамәл кылу – кеше кулында.
Яхшы-яман юлны сайлаганда
Кеше азат гомер юлында.

II

Кан-яшь түгә, мин бәхетсез, дия,
Белми нидән газап чиккәнен, –
Ул теләгән тормыш үз кулында,
Тәртип, тәүфыйкълыкта икәнен.

Безгә яшәү Аллаһ тарафыннан
Язмыш белән бергә бирелә.
Тик кешенең тормыш кормышлары
Үзе тарафыннан үрелә.

Берәүне дә көчләп, күзен бәйләп,
Ятлар кочагына салмыйлар.
Егет-кызны, кыз егетне сынап,
Ышанычлы затны сайлыйлар.

Бисмилласыз, хәер-фатыйхасыз
Өйләнешкәннәрдә тамаша.
Җан сафлыгын җуйган егет-кызлар
Кемнән гаеп эзләп маташа?..

Әхлаксызлык үзды чик-чаманы,
Җир сыкрана, күкләр ярсына.
Гөнаһкәттән йолып алыр өчен
Чүх көймәсе җитмәс барсына.

Талаш-ызгыш, көнчелекнең көне –
Мәхәббәтнең кара шәүләсе.
Хиссез генә яши алмый шул ул,
Төссезләнә Алла бәндәсе.

Ләкин мөэмин-мөселман дәүләттә
Тату яшәү – гади күренеш.
Никахлашкан күркәм гомер сөрә,
Юк аерылу, юктыр бүленеш.

Никах-килешүдә алты талән
Канун булып ята нигездә.
Дин, мал, нәсел, һөнәр, гыйлем, холык –
Камил булса, яклар – бер сүздә.

Күкләр хәер-фатыйхасын бирми,
Җирдә изге никах укылмас.
Үзен сөйгән парларны тик Аллаһ
Рәхмәт-шәфкатеннән ташламас.

Табыштырган һәм ул кавыштырган
Егет-кызның юлы такырдан.
Гаиләдә шыткан саф мәхәббәт
Мәңге балкыр, булып бакыйдан.

Тыйнак, сабыр, итагатьле калыр
Ир хатыны булган кәләш тә.
Чын ир кеше гаиләсен саклар,
Гаилә өчен булыр көрәштә.

Шулай гомер иткән әби-бабам,
Әти-әни димләп кавышкан.
Бер-беренә тугрылыклы булып,
Гомер буе сөю алышкан.

III

Катнаш гаилә корып, денсез булып,
Татарларның корый нәселе.
Тел, милләтен, дин-иманын сату –
Татар егет-кызы кәсебе.

Катнаш гаилә ул – тик мираж-рәшә,
Ике милләтара ызаны.
Шул иясез ызаннарда үсә
Чүп үләне, азган-тузганы.

Урамнарда, вокзал, подвалларда –
Өйләреннән качкан балалар.
Әти-әниләре була торып,
Нигә сукбайлыкта соң алар?

Нигә әле мескен бу нәниләр
Интегүгә дучар ителгән?
Наркоманнар, сәрхүш әти-әни
Сабыйларны ятим иттергән.

Кыйтгаларны афәт урап алды,
Гәр җанның бар борчу, сагышы.
Бер ана каз бәбкәләрен җуйган,
"Кыйгак-кыйгак!" – казлар тавышы.

Анда-монда йөгерешә алар,
Югалтканын эзли казлар да.
Казлар көзен оя югалтсалар,
Ә кешеләр – көзен, язлар да.

"Кыйгак-кыйгак!" – үзәкләрне өзгеч,
Авазлардан һава тетрәнә.
Катнаш гаилә – чишмәсез елга,
Дымсыз туфрак чүлгә әйләнә.

IV

Барча дус-иш, туган-тумачаны
Сөендереп яши ир-хатын.
Аллаһыга шөкерана кылып,
Уртак итеп, булган юк-барын.

Шалтырамый юкка савыт-саба,
Сөю дә бар кебек, ара да...
Гәм бер көнне гаилә күкләрендә
Ник соң әле болыт кабара?

Чәлпәрәмә килгән "үрнәк" гаилә,
Бәгырьләрне юа күз яше.
Юкса, бергә гомерләре үткән
Пенсиядә хатын, ир кеше.

Нинди генә көчләр, нинди кодрәт
Аерды соң ипле бу парны?
Әллә ирнең, әллә хатынгамы
Сөйләгәннәр гайбәт, юк-барны?

Кемгәдер үч итеп, ачу тотып,
Әйләнешкән парлар булганмы?
Әллә ирдә, әллә хатынында
Купкан азгын хисләр бураны?

Хатын – ирнең, әллә ир хатынның
Пычрак хыянәтен белгәнме?
Балаларны ятим итмим диеп,
Тешен кысып кына түзгәнме?

Нинди гөнаһ шомлыклары өчен
Язмыш дигән кодрәт җәзалый?
Ир-хатынны, ана-балаларны
Нинди көчләр шулай аралый?

Җил исмичә генә яфрак очмас,
Утыртмасаң, үсми иген дә.
Шарлар да бит һава тулса гына,
Атып шартлый ахыр чигендә.

Тән ярасы берчак төзәлсә дә,
Җан ярасы кала гомергә.
Ятим итмә, бала, оныкларны
Аерылып картлык көнендә.

Яшәү, язмыш Аллаһ тарафыннан
Изге ният белән бирелә.
Гәр кешенең тормыш корышлары
Үзе тарафыннан үрелә.

Җир-анада без нибары – кунак,
Тыйнакларга кадер, сый-хөрмәт.
Нәфесләнми, хәрамгә керешми
Яшәүләрдә бәхет, бәрәкәт.

Мал-мөлкәтле булу – ярты бәхет,
Хикмәт – барны тота белүдә.
Шул барыңның игелеген күреп,
Җирдә шәхес булып йөрүдә.

Дус-ишләрең, туган-тумачалар
Җыелышып килсә яныңа,
Якыннарның җылы карашлары
Сихәт бирер, балкыр җаның да.

Шалашны да берәү җәннәт саный,
Яратканы булса кырыңда.
Кояш көлә, сандугачлар сайрый
Күңел тыныч булган чагында.

Ни мәгънә бар посып яшәвеңдә,
Затлы ризык белән тукланып?
Яшәр чакта рухи ризык табып,
Гүзәл яңа таңга сокланып.

Күңеле пакь, йөзе дә ак кеше
Кемнәрдәндер куркып яшәми.
Яхшы кеше үзен һәлак итәр
Яман, явыз эшләр эшләми.

Шул тормышны язмыш дисеңме син?
Ә мин әйтәм: нәфес сазлыгы.
Кешеләрне бөек шәхес иткән...
Рухи байлык, күңел байлыгы.

"Язмышлардан узмышлар юк", – диеп
Сыкранадыр ялгыз бер хатын.
Чирек гасыр бергә гомер иткәч,
Ташлап киткән җефет ир-затын.

Йә әйт, Хаким! Нинди сихри көчләр
Аера соң тиңдәш парларны?
Югыйсә бит гомерлеккә диеп
Никахлыйсың сөйгән ярларны.

Нинди кодрәт, нинди илаһи көч
Мәхәббәткә каршы торырлык?
Җаны-тәне белән береккәнне
Яңа баштан сүтеп корырлык?

Бер күрүдә гашыйк булу – гөлнең
Бер тәүлеккә чәчәк атуы.
Балкып торган чәчәкләрнең иртән
Җир өстендә шиңеп ятуы.

Гөлләр кебек гыйшык балкыса да,
Еллар буе килә ярату.
Тик хатын да, ир дә берәү генә,
Ансыз тору – гомер озату.

Тәүге хатын, тәүге ирнең генә
Мәхәббәте затлы, мәһабәт.
Яшьлекнең саф, изге хисләренә
Вәгъдәләргә итмик хыянәт.

Гәр савытның үз капкачы була,
Югалуы аның – фаҗига.
Яулыкны сүрү ертыгына
Яраштырып ямау могҗиза.

Тауга карап кына тау буламыйлар,
Вакыт исраф итмә, Син Адәм!
"Әгәр кеше үзе үзгәрмәсә,
Аны, – дигән Аллаһ, – үзгәртмәм".

VII

Язмышына кеше үзе хуҗа,
Үзе яза тормыш әсәрен.
Кайчак аны читкә тайпылдыра,
Чит кешеләр тыкса каләмен.

Ләкин язмыш, безнең көнкүрешләр
Ил тормышы белән бәйләнгән.
Бу икенең, җан белән тән сыман,
Язмышлары бергә төйнәлгән.

Бер үк илдә, бер үк җирдә торган
Төрле кеше, төрле язмышта.
Кемдер үзен бик бәхетле саный,
Җитмәсә дә нидер тормышта.

Ярлы илнең була зур байлары,
Ғай илдә дә ярлы юк тиңгел.
Казна малын урлап, кеше талап
Ғаеп китә кеше бик җиңел.

Тик берәү дә читтә кала аллмый –
Ил еласа, афәт кичерсә.
Ғай илне дә һәлакәткә илтә,
Әдәп-әхлаксызлык үрчесә.

Киек каз юлының йолдызлары
Җемелдәве аңны сихерли.
Ләкин Аллаһ һәм илаһи акыл
Ғарыр юлны дөрес билгели.




بسم الله الرحمن الرحيم

Кол Шәриф мәчетенә мәдхия

I

Җил кузгалды тагын... Котып җиле...
Җәй уртасы, челлә... югыйсә.
Болыт белән каплап Казан күген
Мәрхәмәтсез салкын җил исә.

Бер мизгелгә болыт арасыннан
Чур көлтәсе төште сузылып,
Хәтерләтеп халкым әләмнәрен,
Ак юл калды күктә сызылып.

Өмет баглап кояш чыгасына
Күпме күзләр бакты офыкка.
Иманга вә халык өметенә
Киртә түгел кара болыт та.

Котыплардан салкын җилләр исә,
Куеннарга кереп оялый.
Каршы төшә халык ташкынына,
Бу ташкынны ләкин тыялмый.

Хәтерләтә шушы котып җиле
Дүрт гасырдан артык дәверне...
Котып җиле күпме котырмасын,
Җуя алмый әлма хәтерне.

II

Бабаларның, шәһид киткәннәрнең
Безнең белән рухы шатлана.
Гасырларны үтеп, алдык көтеп,
Бездә бәйрәм, бездә тантана.

Җил куыра, биткә яңгыр бәрә...
Сизми моны хәтта беркем дә...
Үз ишеген ача изге мәчет
Үз җирендә, татар илендә.

Җилләр исә, биткә яңгыр бәрә,
Мөселманнар тора мәйданда.
Юк, кузгалмас, халык таш яуса да,
Үз иманы илгә кайтканда.

Җилләр исә, биткә яңгыр бәрә,
Олы– кече мәйдан тутырып,
Ачылышын көтә "Кол Шәриф"нең –
Меңнәр басып, меңнәр утырып.

Җилләр исә, биткә яңгыр бәрә,
Бер-беренә йөзләр елмая...
Сөбханалла! Җәннәт сараена
Хак Тәгалә бирә юллама.

Җилләр исә, биткә яңгыр бәрә,
Ала аллмас безне йолкып та.
Котып җиле – күпме котырмасын,
Безне эчтән иман җылыта.

Җилләр исә, биткә яңгыр ява,
Иланһи нур бизи йөзләрне
Изге көндә котып җиле белән
Хак Тәгалә сыный безләрне.

* * *

Һәр мөселман бүген бәйрәм итә,
"Кол Шәриф"не күреп шатлана.
Мөэмин-мөселманның күңелендә
Ислам дине кыла тантана.

Татар иле бүген бәйрәм итә,
Кремльдә ислам дөньясы.
Ғарәп, төрек, татар, рус кавемнәре –
Ихтирамга лаек һәркайсы.

"Таш белән атканга аш белән ат" –
Васыять иткән ата-бабамнар.
Без риясыз, киң күңелле халык,
Тик изгелек кыла оланнар.

* * *

"Бисмилләһир-рахманир-рахим" – дип,
Сүз башлады татар Илбашы.
Кайтты иман илгә мәчет булып,
Ә иман – ул мәңгелек юлдашы.

Тарихыбыз җебен ялгый-бәйли,
"Кол Шәриф" ул – рухият күпере.
Нык тотынса Аллаһ арканына,
Гүч үзелмәс татар гомере.

"Күккә ашкан манаралар торсын,
Иман нуры сибеп мәңгегә.
Күк төсендәге гөмбәзе балкып,
Юл күрсәтсен Коръән-Кәримгә".

Сүзне дәвам итте Әкъмалетдин –
Ислам дәүләтләре илчесе:
" Мәдинәгә килгән Пәйгамбәр дә
Мәчет төзеттергән беренче.

Мәчет төзүчегә кыяметкәчә
Аллаһ мәчет төзер җәннәттә".
Бәхет килер, сүзе алдан йөрер,
Ил рәхмәтен алыр, әлбәттә.

Маатук-Әл-Маатукның да нотыгы
Горурлык вә өмет уятты.
"Гарәп илләре берләшә", – диде,
Күңелләргә гүя май якты.

"Амин, – диде – күктә фәрештәләр –
Ислам динле кавем ныгысын!"
"Мәчет салган илгә рәхмәтемнең
Бирәм, – диде, – Аллаһ олысын".

* * *

Уникедә кырык биш минутта
"Намазга!" дип, күкләр эндәште.
Мөселманны госелләгән сыман
Сибәләргә яңгыр кереште.

Тәһарәтле рәт-рәт тезелеште,
Сафка басты алар дистә мең.
Явыз Иван гаскәренә каршы
Баскан бабамнарга итеп тиң.

Яңгырады янә "Кол Шәриф" тән...
Шәүкәт хәзрәт әйтте азанны.
Коръән моңы, Коръән аһәңнәре,
Иркәләде мәшһүр Казанны:
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр,
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр,
Әшһәдү әллә иләһә илләллаһ.
Әшһәдү әллә иләһә илләллаһ.
Әшһәдү әннә Мөхәммәдер – рәсулуллаһ.
Әшһәдү әннә Мөхәммәдер – рәсулуллаһ.
Хәййә гәләс-саләһ,
Хәййә гәләс-саләһ,
Хәййә гәләл фәләх,

Хәййә гәләл фәләх,
Аллаһу әкбәр,
Аллаһу әкбәр,
Ләә иләәһә илләллаһ.

Йөз меңләгән кардәшләрем белән
Мин дә бастым намаз рәтенә.
"Субханә раббиль-әгъләә", – диеп,
Башны орам җирем өстенә.

Аллаһу әкбәр дип, торып басам...
Кинәт шунда аңым югала.
Мин кайда һәм ни эшләргә тиеш?
Мизгелләргә башым буш кала.

Әйләнемне халык сырып алган,
Нишләп алар җиргә тезләнгән?
Кол Шәрифнең әллә шәкертләре
Үлеп ята монда меңләгән?

Бәгыремне ерта коточкыч шом,
Каян килде тагын бу каза?
Кай тарафтан килә шомлы аваз?
Кемнәр укый кемгә җеназа?

Кара болыт күктә, җирдә шәүлә,
Кемнәр анда мылтык коралар?
Нигә килгән бу кадәрле гаскәр?
Кемнәр рәт-рәт басып торалар?

Алар әзер өскә ташланырга,
Йорт-җирләрне изеп китәргә.
Танклары – Мари урманында,
Әмер көтә һөҗүм итәргә...

Ғасып торам, бераз аңга киләм,
"Кол Шәриф"кә карыйм борылып.
Мәңгелеккә безгә юл күрсәтеп,
Тугыз ае балкый нур булып!

Дүрт йөз илле өч ел ул изге нур
Күңелендә булды халыкның.
Тиңсез Аллаһ җанны саклап килде,
Иман, ислам көче барлыкның.


Көнчыгышта офык күзен ачты,
Коръән тотып милләт уянды.
Ике зәңгәр гөмбәз тоташтылар,
Идел-йортның йөзе нурланды.

Зәңгәр күктә, көмеш нурга манып,
Ак болытлар язды: Азатлык!
Милләтебез асылына кайта...
Ғәй, татарым! Рухың булсын нык!

Ғәр мөселман бакый бәйрәм итсен,
Кол Шәрифләр артсын милләттә.
Ислам дине – хаклык тантанасы
Ғулсын даим безнең йөрәктә!..

7 июль, 2005 ел

قُلْ
أَعُوذُ بِرَبِّ
النَّاسِ ۝ مَلِكِ النَّاسِ
إِلَٰهِ النَّاسِ ۝ مِنْ شَرِّ
الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ ۝ الَّذِي
يُوَسْوِسُ فِي صُدُورِ النَّاسِ ۝
مِنَ الْجِنَّةِ وَ
النَّاسِ


بسم الله الرحمن الرحيم
قل هو الله احد
الله الصمد
لم يلد ولم يولد
ولم يكن له كفوا احد

Ахирәткә хат
(поэма)

1.Юк, вәсвәсә түгел безнең уйлар!

Бу хат, бәлкем, анда барып җитмәс.
Тик шулай да, булдым язарга, –
Төгәл беләм: килер көннәр теләр
Чал тарихтан безне табарга.

Кайсы чорда, ничек яшәгәнбез,
Нинди хәлләр баштан үткәннәр?
Кемнәр соң без?!
Гәм без нинди заттан –
Бу дәвердә гомер иткәннәр?

Таң җилләре белән ирешсеннәр
Безнең хисләр, безнең тойгылар,
Барсын хәбәр ахирәткә кадәр:
Кемнәр җуйды, кемнәр җыйдылар...

Безнең тормыш, бәлкем, сабак булыр
Хата-ялгышларга тарманска,
Килер буыннарга гыйбрәт булыр
Безнең хәлдә торып калмаска...

Еллар буе хәләл хезмәт хакын
Ала аллмый йөрдек интегеп.
Яшәмәсен килер буыннар да
Тиранннарга бездәй баш иеп.

Бу дөньяга барлык җан иясе
Шыр ялангач туа анадан.

Җир-Анада аның үз өлеше
Билгеләнгән тиңсез Алладан.

Гәркемнең дә хакка хокукы бар,
Артыгы да түгел, киме дә.
Мал-мөлкәтен, белəм, ахирәткə
Алып китə аллмый беркем дə!

Данга-малга хуҗа байбәтчәләр
Халкын талый, бирми яшәргә.
Ил – җилкәнсез кораб: эшләр харап,
Чыга аллмый ерак сәфәргә...

Эшсез-ашсыз, ач-ялангач халык
Сазлык уртасында чайкала.
Хуҗаларга билен бөккән мескен
Җан асрарлык мыскыл хак ала.

Кайный халык базар казанында,
Бар кәсебе – нидер сатуда.
Тән сатыла монда, җан сатыла,
Бөтен гамəл – табыш алуда.

Юл буенда ярым шәрә калып,
Фəхишəләр баскан тезелеп.
Үндүрт яшьлек сәрхүш, наркоманнар
"Клиент" ларын көтə өзелеп.

Бу "борынгы кәсеп" ияләре
Азгын тəнен сатып, көн күрə,
Җилдән туган күке балаларын
Зина акчасына үстерə.

Юлның бер читендә әби-бабай
Хәер сорый, сузып кулларын.
Җем-җем итә орден-медальләре,
Хәтерләтеп сугыш елларын.

Типсә тимер өзәр ир-егетләр
Эш юклыктан йөри тилмереп,
Бер урынга егермешәр кеше
Иртә таңнан килә йөгереп.

Бөлгенлеккә төшкән илнең халкы –
Яр читендә тора... ярты лаш,
Гәр тарафта – каһәрләнгән язмыш,
Күз яшьләре, каргыш, ыңгыраш.

Очын-очка ялгый аллаганның
Иңнәрендә – тормыш газабы,
Чиләкләрдә тормыш...
Бу тормышның
Нәрсә белән бетәр азагы?

"Урам тәрбиясе"н тойган бала...
Күзләрендә нәфрәт, үч, сагыш.
Сукбайлыкта йөргән сабыйларның
Шөгыльләре – урлап көнкүрмеш.

Үзен бөек диеп йөргән ил бу,
Аның халкы ачтан интегә.
Фатирына тиеп аллаганнар
Бомжлыкка чыга иртәгә.

Котырынып көн дә үскән бәя
Бугазыннан алды халыкның.
Шушы илгә хезмәт иткән гавам
Бар михнәтен татый картлыкның.

“Акыл белән аңлап булмас ил”дә
Ахмаклыклар итә хакимлек.
Ғәрәкәт һәм иман качкан моннан,
Калган монда ачлык, ятимлек.

Җәбер-золым, мәсхәрәгә калган
Кешеләрдә өмет өзелгән.
Кара каргыш төшкән шушы илме
Сөяк өсләрендә төзелгән?..

Кемнәр алар – юлын югалтканнар,
Милли фаҗигагә тарганнар –
Чит-ятларның гадәтләрен алып,
Ана телсез, өнсез калганнар?

Алла каргадымы?! Илнең халкы
Килеп керде шайтан туена.
Үз урысы да бит михнәт чигә,
Җәфа чигә гомер буена.

Советларда – “кухарка”лар булды,
Эш башында хәзер – уллары.
Ғер өзлексез бара реформалар...
Тик билгесез барыр юллары.

Өметләре сүнгән кешеләрне
Ғитарафлык алган уратып.
Көне-төне ул тамаша карый,
Алдалыйлар уен уйнатып.

Концертларда ир “хатын-кыз” чыга,
Ялган күкрәк элеп төшенә.
Маймыллану, шайтан булып алу
Ғерни тормый ир-ат кешегә.

Олигарх-комсыз... Илне талый,
Үз ишләрен янә аздырып.
Ил байлыгын үз байлыгы итә,
Чит банкка куя яздырып.

Кемдер ялый, чукый, йолкый, талый,
Булсаң әгәр тере үләксә.
Тере җанның тәне калҗа була,
Ерткыч тырнагына эләксә.

Әнә, көчле диңгез дулкыннары
Котырынып бәрә ян-якка.
Белмибезме?! – Зур һәлакәт яный
Бер урында торган корабка.

Ил-җирләрен баскан цунамидан,
Афәтләрдән Аллам сакласын.
Ачы язмышларның кочагында
Оныклар да иде калмасын.

Хак Тәгалә тузан бөртегеннән
Без яшәгән җирне яралткан.
Җисемнәрнең хәрәкәтен җайлап,
Бер-беренә бәйләп җеп аткан.

Көн күрергә кояш кабызган ул,
Төн йөрергә айны калкыткан.
Биниһая йолдызларын сибеп,
Чиксез Галәмнәрне яктырткан.

Җир-Ананы кече җәннәт иткән,
Чәчеп төрле изге үсемлек.
Хисабы юк җанвар-җәнлекләрнең
Корт-бөҗәкләр итә тереклек.

Адәм затын аннан иҗат иткән,
Мәхәббәткә төреп әсәрен.
Ғәм җан өргән, яшәү асылы биргән –
Мал-мөлкәтле итеп яшәрен.

Ләкин адәм һаман туя белми,
Нәфесенә тамга уелган.
Тыңгы белми нәфес – тәмам азган!
Тик аңа да чикләр куелган...

Вәсвәсәдән өстен кал син, Кешем,
Ваклыклардан һәрчак өстен бул, –
Ахирәткә көчләп чакырмыйлар,
Ул – бердәнбер тугры, туры юл...

Юк, вәсвәсә тыгел безнең уйлар,
Без чабабыз тормыш астында.
Яшәү асылы... яшәү мәгънәсе бар –
Безнең уйлар шулар хакында...

2. Син идеңме минем мәхәббәтем?

Мәрхүмнәргә тел тидермә, диләр,
Читкә китми шушы йоладан, –
Гөнаһларың ярлыкауны сорап,
Калдырмыймын сине догадан.

Миңа, бәлки, үткәннәргә кайтмый,
Берни әйтми синең хакыңда,
Яшәү тиеш... Син бик ерак миннән.
Әлмә син бит бик тә якын да!

Кирәктер дә дәшмәү... Тик бәгырьдә
Яраларның тынмый сызлавы.
Күңелемне борчый, җанны талый
Сорауларга җавап булмавы.

Нишләп болай чәлпәрәмә килде
Җай башланган безнең тормышлар?
Юлыбыз да такыр иде сыман,
Кайдан, нидән булды ялгышлар?

Үз-үземә бирәм сорауларны,
Үткәннәрне күздән кичерәм.
Әйтерсең мин – "вакыт машинасы",
Үткәннәргә кат-кат күченәм.

Җил исмичә яфрак селкенми шул,
Болыт йөзми җилләр кумаса.
Тиктомалдан кеше зыян салмый
Үз-үзенә, сәбәп булмаса.

Карамасаң, даим утамасаң,
Бакчаны да котсыз чүп баса.
Күркәм гадәт, әдәп тәрбиясе
Бала чактан җанда булмаса.

Табалмассың, димәк, уңган кәләш,
Әкияттәге кебек ук атып.
Ургып аккан язгы ташкыннарны
Буып кына булмый туктатып.

Фаҗигаләр сабак өйрәтәдер,
Бөкрене тик кабер төзәтә.
Кеше үзе утны-суны үтми,
Аңа акыл керми йөдәтә.

Көтү башы сикереп үтсә әгәр
Җирдә аунап яткан чыбыкны,
Арттагылар, чыбык булмаса да,
Кабатлыйлар шул ук "трюк"ны.

Чик кешеләр – акыл ияләре –
Гыйбрәт аллмый икән үткәннән?
Ата-баба хата-ялгышлары
Кабатлана "кире беткәннән".

Бу дөньяга туган һәрбер буын,
Алып килә үзгә яңаны.
Ул үзенчә тормыш кора башлый,
Бутап бик еш яхшы-яманны.

Аллаһыдан иңгән Аң һәм Акыл
Давыл булып мидә котыра.
Галимнәрнең төшләренә кереп,
Могҗизалар җирдә Ул кора.

Тормыш – көрәш, яшәү – тиңсез бәхет,
Яхшы-яман һәрчак ярышта.
Мең газаплар, кан-яшь, үлем аша
Җәмгыятьләр үсеш аллмышта.

* * *

... Акча боза адәм балаларын,
Ә ул синдә булды санаусыз.
Төнге сменада ирләр белән,
Буфетыңда калдың караусыз.

Азгыннарның татлы сүзләреннән
Ничек шулай башың әйләнде?
Хыянәтле сәрхүш көнкүрешең
Сукбайлыкка кереп төйнәлде.

Башка эшкә сине димләсәм дә,
Ниятләрем терәк тапмады.
Ашханәне җитәкләгән ирләр,
Аяк терәп сине яклады:

“ Бер хатасыз кеше юктыр, имеш,
Без канәгать аның эшеннән...“
“Аерылсам синнән – аерылам,
Аерылмыйм“, – дидең эшемнән.

Үзгәләнеп әйткән сүзләремә,
Ярсуыма исең китмәде.
Хыянәт һәм хәмер төеннәрен
Үзгәләргә тешем үтмәде.

Чибәр идең! Йөзең көлеп тора,
Җем-җем итә иде тешләрең...
Буең-сының коеп куйган кебек,
Ким-хур түгел башка төшләрең.

Кем нәфесен тыеп кала алсын
Табындагы татлы җимештән! –
Бәйрәмнәрдә зур-зур түрәләр дә
Авыз итте синең “өлеш”тән.

Югыйсә бит мин дә дәрәҗәле,
Ихтирамга лаек ир идем, –
Йолдызларга буем җитмәсә дә,
Башкалардан юктыр ким җирем.

Түгел идем төшеп калганнардан,
Җилләр куып йөргән бер надан.
Ярлар сөеп, яшьлек тормышымны
Башлый ала идем яңадан.

Бу гамәлне, беткә ачу итеп,
Тунны ягу итеп санадым.
Акылыңа килеп, асылыңа
Кайтасыңа өмет багладым.

Җилгә каршы мәнсез төкерүләр
Үз битеңә килеп сылана.
Һер хатының кулда тоталмаган
Ир булдыксыз булып санала.

Мин гаепле Аллаһ, әти-әни,
Улларыбыз, синең каршыңда.
Әрнеп, сыкрап, синнән гафу сорап,
Һасып торам кабрең каршында.

Йа, Аллаһым, бәндәң Саниянең
Хата-гөнаһларын ярлыка?!
Уникә ел намаз, гыйбадәттә,
Тәүбә итте, барды хаҗ якка.

"Үткән эшкә салават", – ди халык,
Мин дә китмим шушы йоладан.
Җәннәт әһле булуыңны сорап,
Калдырмыймын сине догадан.

Син идеңме минем мәхәббәтем,
Син идеңме яшьлек сердәшем?
Мин кичереп яшим... һәм сагынып...
Әрнеп-сыкрап яшим мин яшим...

3. Күз ташласам әгәр үткәннәргә...

Үткәннәргә әгәр күз ташласам,
Бугазыма төер тыгыла.
Йөрәгемне нидер әчеттереп,
Тырнап үтә, тыным кысыла.

Гомеремнең чәчәк аткан чоры
Хатын назы күрми бөреште.
Уллар үсте... әле ярый алар
Әрнүләрне бергә бүлеште.

Сагынудан, сине юксынудан
Тоныкланды кебек күзләре.
Уйнап-көлеп йөргән булсалар да,
Борчу япкан иде йөзләрен.

Әле ярый үсте безнең уллар,
Китермичә йөзгә кызыллык.
Дәү әниләренең тәрбиясе
Чигез булды чын ир булырлык.

Нинди гөнаһ шомлыклары өчен
Җәза алдык соң без язмыштан?
Аллаһ рәхмәтеме саклап калды
Начар эш-гамәлләр кыллактан?

Мәрхәмәтлек салды күңелемә
Изгелекнең бирде олысын.
Соңгы сулышыңа кадәр сиңа
Әеп бирдем күңел җылысын.

Сеңлең Зәйтүнәгә әйткәнсең ич
"Бик үкенәм, – диеп буллышка.
Рәхмәт инде, Рәис ташламады,
Ул кайтарды юньле тормышка".

Гәлләбез дә сине Ана итеп,
Хөрмәт иттек, ихлас яраттык.
Тормыш учагын без акыл белән,
Оныкларны сөеп яңарттык.

Бәгыремне телгән җәрәхәтләр
Йомылса да, җөе калса да,
Вакыт-вакыт искә төшергәләп,
Сыкрап куйса, кадап алса да...

Ulaһi көч җанга нур бөркеде,
Күңелләргә иңде сабырлык.
Хаталарның хакын тиләр өчен
Тәүге никахыңда калырлык.

Рәхмәт сиңа, соңгы дистә елың
Намаз укып үттем, тәүбәдә.
Сабантуйлар бизәр чәчәк идең,
Эшләсәң дә шул ук сәүдәдә.

Балаларның әни, дәү әнисе,
Тансык сөеклесе буген дә.
Балкып торган йөзле, киң күңелле
Булып калдың алар күңлендә.

Ләкин миндә ике "мин" яшидер,
Берсе сине ихлас ярата,
Икенчесе бәгыремне ерта,
Йөрәк яраларын яңарта.

Гомер буе шулай ут белән су
Алмаш-тилмәш кайный җанымда.
Гомер буе газап чигәчәкмен
Бу тәнемдә җаным барында.

Тик сөекле бәндәсенә Аллаһ
Сынауларның бирә һәр төрен.
Ulaһi хис булган мәхәббәтнең
Беллмәс идек юкса кадерен.

Гомер иткән кешең мәрхүм булса,
Ул әүлия затка әйләнә.
Еллар үткән саен яратуың
Бәгырьләрдә ныграк шәйләнә.

Син идеңме минем мәхәббәтем?!
Искә алам, назлап исемеңне.
Яшьлегемә кайтсам, мең гөнаһтан
Йолып алыр идем мин сине!

4. Ә күрешсәк әгәр...

Аның белән бер күрешер өчен
Гомереңне бирер буласың.
Аллаһ рәхмәт кылса, җәннәтендә
Күрешергә өмет корасың.

Ә очрашсак?.. Чинди кыяфәттә
Булыр икән безнең җан һәм тән?
Менә шундый чакларымда... (гафу!)
Мин шикләнеп куям җәннәттән.

Искә төшә янә айлы төннәр,
Искә төшә керсез яшь чаклар.
Чуер таш күк шома тәннәреңнән
Таеп китә иде бармаклар!..

Бит уртаңда балкып торган миңең
Калыр микән һаман сакланып?
Әсир иткән зәңгәр күзләреңә
Карар идем мәңге сокланып.

Еллар үтеп, үзгәрешеп бетеп,
Танымаслык буллмыйк әле дә.
"Теге очлар" "бу очныкылар"ны
Белешмиләр хәзер Шәледә.

Исән чакта җаның сөйгәннәрнең
Кадерләрен белми яшисең.
Уч төбендә йөртер идең дә бит...
Эш узган шул инде, нишлисең?!

Гамәл дәфтәрләре дә ябылган,
Азат буллмак савап, гөнаһтан.
Кылган гөнаһларны ярлыкауны
Сорау кала тик бер Аллаһтан.

Мәрхүмнәргә дога багышлыйбыз...
Алар, ләкин, безгә эндәшмәс.
Искә алу... Корбан чалулар да
Хәтер белән һич тә тиңләшмәс.

Хак Тәгалә үз җаныннан бүлеп,
Адәм баласына җан өрә.
Гүәр кылынган эш-гамәлләрне дә,
Ул үз җаны аша үткәрә.

Мәгълүм Аңа тойгы-хисләребез,
Уйларның да яхшы, яманы.
Түкми-чәчми җаның теркәп куя
Гамәл дәфтәреңә аларны.

Изге ниятле эш тик – Аныкы,
Начарлары – иблис кулында.
Ата – улын, ана – кызын беллмәс,
Син курчаксың шайтан туенда.

Анда тәртип, күркәм гадәтләр юк,
Хәмер хуҗа, хәмер тамада.
Исерешеп, ярым шәрә калган
Фахишәләр чыжлый табада!..

– Әче-әче! – диеп кычкыралар,
Әхлаксызлык шуннан башлана.
Үбешүнең санын җуйган табын
Ялашырга үзе ташлана.

Яман гадәт, азгын уй-теләкнең
Юк ахыры бүген, юк чиге.
Совет заманнары сәрхүшлеге –
Бу заманның бары "көчеге!"

Тәмуг кисәвенә әйләнсәк тә,
Ялкын тимәс кеше җанына.
Башка тәнне җанлы итәр өчен
Аллаһ алыр үзе янына.

Көч-кодрәтле, тиңдәше юк Аллаһ...
Гөнаһ дә җаннар безнең мәңгелек.
Адәменә үзеннән җан өргән
Бөек заттан бөтен изгелек!

* * *

Үзең кебек сәрхүш калдыгыннан
Урам эте кебек кыйналдың.
Әүмәкләшеп шулар өерендә
Адәм көлкесенә син калдың?

Гомереңнең чәчәк аткан чоры
Сукбайлыкта йөреп үтте бит.
Әйләнәдә йөргән кабыклык күк,
Кулдан-кулга язмыш йөртте бит...

Гәрбер сәрхүш, җае чыккан саен,
Тәнең тәмен татып карады.
Хәмер сузган һәрбер йолкыш сине
Үзенеке итеп санады.

Айлар буе өйгә кайтмый идең,
Алып кайтсак, качтың иртәсен.
Ата-анаң елый-елый әйтте
Азгын юлның кая илтәсен.

Ике улың, күз яшьләрен түгеп,
"Әни, китмә!" – диеп үтенде.
Ә син киттең, безне нәүмиз иттең,
Күңелләрнең чите кителде.

Ничек кенә үгет-нәсыйхәтләп,
Әндәсәк тә хәләл табакка.
Сазлыгына чапкан дуңгыз кебек,
Ашкындың син шул тагаракка.

Балаларны ятим итмим диеп,
Таралышмыйк диеп, як-якка.
Син теләгән эштә эшләтергә
Риза булган идем ул чакта.

Ләкин минем изге ниятләрем
Чәлпәрәмә килде һаман да.
Кая гына эшкә керешсәң дә,
Гамәлләрең булды яманда.

Бер нәрсә дә үтми эзсез генә,
Барыбызга җитте афәте.
Хәсрәтеннән шашкан әниеңнең
Фаҗигале булды вафаты.

Кайгы йөрми агач башларыннан,
Ул йөридер адәм башыннан.
"Тәртип бозган өчен" син ике ел
Авыз иттең зиндан ашыннан.

Михнәт күрдең, ачлы-туклы йөрдең,
Җир-Анага килеп кунакка.
Нинди явыз көчләр этәрделәр
Еллар буе "бомж" буллмакка?

Яшәр йортың ташлап, безне ташлап,
Син бәхетне читтән эзләдең,
Булганына шөкерана кылып,
Ипләп кенә яши белмәдең.

Көзләр җиткәч, кышны каршыларга
Кошлар җылы якка китәләр.
Киткән кошлар туган илләренә
Яз килүгә килеп җитәләр.

Көзең җитми киптең...
Син дә киттең
Кире кайтып буллмас җирләргә.
Вафат булганнарны ямьсез итеп
Кирәкмидер, бәлки, сөйләргә?..

Тик хурлыклы бу хәлләрнең эзе
Күңелләрдә калды уелып.
Йөрәктәге тирән яраларның
Әрнүләре тормый җуелып.

Ул һаман да сызлый, җәрәхәте
Гомергә дә ахры, йомыллмас.
Нәсел йөзендәге бу кара тап
Гич җуеллмас инде, җуеллмас...

Сәрхүшлектән, мәнсез көнкүрештән
Оныкларны Алла сакласын –
Якласын Ул безне һәм нәселне...
Шайтан зәхмәтеннән якласын!

Гомер буе тынгы бирми сорау:
Ни-нәрсәдән ачы ялгыштың?
Яшьнәп торган күркәм гаиләбезне
Сәрхүш өреңә алыштың?

Югыйсә бит, син – сөекле ана...
Хатын булдың миңа, бердәнбер.
Әйдә үзең хуҗабикә идең,
Ошамады болар нигәдер.

Тормышыбыз җайга салынганда,
Көйле генә барган чагында.
Күз тидерткән нәни бала кебек,
Туздырдың да аттың барын да.

Көтмәгәндә үзгәрдең дә куйдың,
Әйгә салмыш кайта башладың.
Тоткарландың, эштә кунып калдың,
Тора-бара безне ташладың.

Ни гаебе булды балаларның?
Укыдылар яхшы, тәртипле.
Әйбәт ана булсаң, өйдә торсаң,
Булыр иде алар бәхетле.

Ни эзләдең, ни җитмәде сиңа?
Бер кайттың да, әле бер киттең.
Гаепсезгә миңа яла ягып,
Сәрхүшләрне никтер иш иттең.

Нинди зәхмәт чире йокты сиңа?
Сәбәпләрен безгә әйтмәдең.
Башка эшләр тәкъдим итсәм дә бит,
Шул сәүдәдән үзең китмәдең.

Кирелегең, юләр үҗәтлегең
Өзгәләде безнең бәгырьне.
Синең өчен буфет чумарасы,
Хәрам акча булды кадерле.

Кемдер акча вәсвәсәсе дияр,
(Юк, акчага яклыйм гаепне!)
Хатын-кызның тубән төшендә
Ихтыярсыз ирләр гаепле!

Гомер буе үз-үземне әрлим,
Гаепле дип саныйм үземне.
Читкә китеп бардым, күреп синең
Сәрхүшлектән шешкән йөзеңне.

Сизеп юри читләшкәннәремне,
Тора-бара син дә читләштең.
Ераклашкан саен чик, аралар,
Ачу итеп эчтең, үләштең.

Шушы ахмак хаталарым өчен
Гафу итә алмыйм үземне.
Чик алмадым сине кочагыма,
Сабыр булып, җыеп түземне.

Кирәк булган... ләкин бик соң инде,
Үткәннәрне буллмый кайтарып.
(Бу дөньяда беркем үкенмәстер
Минем кебек ташка баш орып).

Хатын-кызлар тойгы белән яши,
Хис ташкыны кич тә, иртә дә.
Чалуларда чана мәтәлдә
Гаепледер ат та, тәртә дә.

Ә тәртә – ул гади агач киртә,
Сынарга да мөмкин каерсаң.
Хатын-кыз да була сыңар киртә –
Чанасыннан, аттан аерсаң.

Хатын-кызлар ургып аккан елга,
Язгы ташкын сыман кайчакта.
Аның шашкын күңел дулкыннарын
Тыеп була бары кочакта.

Ир-ат булып, яхшы ир-ат булып
Ир үтәсен ирлек хезмәтен.
Мәхәббәттән, наздан аермасын
Хатын дигән Аллаһ нигъмәтен!

* * *

Син идеңме минем мәхәббәтем?!
Син языммы минем, көземме?
Үткәннәргә кайтсам, синең өчен
Мин гаепле саныйм үземне.

Бер күрешсәк әгәр... Әй, күрешсәк!
Телләремдә назлап исемеңне,
Туган якның яшьлек тугаена
Урлап китәр идем үзеңне!..

5. Мин хәтерлим әле, хәтерлим...

Сугыш чорын үсмер балалары
Һәм балалар иркә белмәде.
Балачакның татлы йокысында
Матур төшләр безгә кермәде.

Җиде-сигез яшьтән, таңнан торып,
Бала-чага эшкә кереште.
Йорт-җирләрнең бөтен мәшәкатен,
Авырлыгын уртак бүлеште.

Ундүрт-унбиш яшьлек үсмерләрнең
Язын, кышын, җәен, көзен дә,

Басуларны сөреп, чәчеп-урып,
Көн-төн үтте колхоз эшендә.

Сука тарталмаган арык аткa
Камчы белән алдык сыздырып.
Тұбә саламы ашаган атлар
Хәлсезлектән ятты сузылып.

Дүрт аягын терәп көчәнсә дә,
Йөкле арба тирән утырган.
Тиргә баткан атның арык тәне
Җәя кылларыдай тартылган.

Киерелеп янә ул ыргылды,
Ал аякларына тезләнде.
Пар бөркелә, тәне дер калтырый,
Газапларга, ахры, түзмәде.

Көлтә кебек, мескен, җиргә ауды,
Күз яшьләре ага мөлдерәп.
Тәртә арасында елап яткан
Атны чыгардылар өстерәп.

Күтәрәмгә чыккан корчаңгы ат
Җан көченә тартты арбаны.
Кеше белән иңне-иңгә куеп,
Я нәшәдә аның барганы.

Газапларын сугыш елларының
Аң-акылга буллмый сыйдырып.
Игелекле, тугры ул атларга
Алтын һәйкәл куйыйк койдырып.

Син дә күрдең авыр бу хәлләрне,
Син дә булдың заман баласы.
Кан, яшь белән узган ул елларның
Бәгырьләрдә калды ярасы.

Апаларың белән син үзең дә
Печән җыйдың кысыр басудан.
Сыгылып төште кайчак көянтәң дә
Иңнәреңә йөгең басудан.

Басуларның тырпа камыллары
Табаннарга кереп кадала.
Чебиләгән аяк битләреннән
Бөрчек-бөрчек булып кан ага.

Үсәр иде иген кырларында
Төркем-төркем булып чәчәкләр.
Тибрәнделәр кунып таҗларына
Умарталар, барча бөҗәкләр.

Һаваларда канат җилпүеннән
Кыр-басулар торды гөж килеп.
Кояш нурларыннан куәт алган
Мул башаклар төште иелеп.

Басу өстен салават күпередәй
Төскә бизәп рәшә тибрәнә.
Җан иясе челлә кызуыннан
Күләгәдә ятып кинәнә.

Аллы-гөлле керфекләрен баккан
Чәчәкләрдән такыя үрдегез,
Чәчәкләрне сөеп, назлап кына
Кочакларга җыя идегез.

Көянтәңә элгән төремнәрне
Чак күтәрә иде әтиең.
Ә бит әле буыннарың сыек,
Талчыбыктай, кызчык бит үзең.

Синең җылы кочагыңда балкып,
Чәчәк атты эне-сеңелләр.
Егет-кызлар булып үсеп җитте,
Бу бәхеттән үсте күңелләр.

Унбер бала, унбер бертуган сез,
Алтынчысы булып син үстең.
Тапмаган да булыр иде анаң...
Үзәкләрен аның син өздең.

Бу дөньяга унбер җан иңдерде,
Мең газаплар күреп үстерде.
Кайгы-хәсрәт, борчулардан гайре
Нинди хөрмәт, нинди сый күрде?

Теле белән кеше әйтмәсә дә,
Тыя аллмый күңел рәнҗүен.
Дөньялыкта назга мохтаҗ анаң
Ахирәттә күрсен әҗерен.

6. Уйда үтте көннәр, төннәрем

Якын дуслар миңа, көтмәгәндә,
Суд буласын хәбәр иттеләр.
Әгәр мин теләсәм, мин хәл итсәм,
"Эш" не ябачакны әйттеләр.

Ике утның уртасында калдым,
Икесе дә җанны өтәли:
"Төрмәдә ул нишләр? Ә иректә?!"
Күреп буллмый сине үтәли.

Төннәр буе уйлар давылында
Юл табалмый чыктым адашып.
Ике якны бизмәннәргә салып,
Уйда үтте көннәр, баш ватып.

Хатынымны шулай күрәләтә
Бер дә килми тоткын итәсем.
Әлма белмим, "азгын оялары"
Кай тарафка сине илтәсен...

"Туктатыгыз", – дисәм аңга килеп,
Сәрхүшлектән айный алырмы?
Әллә һаман кызыл борыннарның
"Ахирәте" булып калырмы?

Аллам! – дидем –
Сиңа тапшырамын,
Рәхмәтеңнән үзең ташлама.
Дөрес юлга чыгар хатынымны
Өйрәт яңа тормыш башларга?!

Гәм ишетте Аллаһ гозеремне,
Күңеленә тәүфыйк индерде.
Себер төрмәсендә игелекле,
Дин-әхлакый юлга күндерде.

Асылына кайтты, иман тапты,
Биш вакытта басты намазга.
Үтәде биш фарыз гамәлләрне,
Кылды изге сәфәр ул Хаҗга.

Хак Тәгалә кодрәтеннән башка
Җилләр исмәс, яфрак селкенмәс.
Җир йөзендә һичбер нәрсә үсмәс,
Адәм балалары көн күрмәс.

Аллаһ сөеп, ышанычлы диеп,
Хуҗа иткән Җирдә Адәмен.
Җир астына салган байлыкларын,
Җир өстенә биргән тәгамен.

Бу дөньяда яшәү серен әйтеп,
Изге китапларын индергән.
Гөнаһлардан тыелырга кушып,
Кешеләргә әмер күндергән.

Коръән тере кешеләргә җирдә
Дөрес яшәү өчен бирелгән.
Аллаһының кушканнарын үтәү –
Мөселманга фарыз диелгән.

Кушканнарын үтәп, Коръән җөпләп,
Җирдә яшәү – Аның бүләге.
Фанилыкта кылган гамәлләрнең
Ахирәттә булыр кирәге...

7. Төштә күргәннәрдән

Хак Тәгалә изге фәрманнарын,
Кануннарын тора җиткереп.
Кайчак кеше чиксез Галәмнәрне
Урап кайта, сәер төш күреп.

Җир-Анага карап, шушы гаҗәп
Табигатьне күреп соклана.
Яктылык та анда – сөт төсендә,
Гәр тарафта – яшәү, тантана.

Тирә-якта – хәтфә яшеллекләр,
Урман-кырлар ята җәелеп.
Тулып пешкән җиләк-җимешләре
Учларыңа төшә өзелеп.

Көмеш сулы Кәүсәр чишмәләре –
Әйтерсең лә Фазыл чишмәсе.
Агышлары моңлы һәм аһәңле,
Җырлый кебек Айның Зөһрәсе.

Колач җәен, киерелеп ага,
Ширбәт елгалары тын гына.
Хак мөселман намаз-гыйбадәттә,
Баскан гүя Идел ярына.

Кая бакма – сый-хөрмәтле табын,
Инсаннары юмарт, ягымлы.
Ризык-нигъмәтләре бисмиллалы,
Бу соң әллә туган ягыңмы?!

Монда юктыр патша сарайлары,
Хаким итми ерткыч көчлелек.
Алтын-көмеш, асылташлы нәфес,
Гүзәл хөсетлек, һәм дә көнчелек.

Тормыш ямьле, ашлары да тәмле,
Бөтен тараф серле тынлыкта.
Табигать ул – җанлы! Ул – иланы!
Җан тантана итә чынлыкта!

Бу мизгелләр Адәм зиһененә,
Хәтеренә кереп уелган.
Гөнаһ кылганнарга Аллаһының
Җәннәтенә керү тиелган.

Кылу өчен изге эш-гамәлләр
Яман янап тору кирәктер.
Җир-Анада меңгазаплар күрү –
Оҗмах ишегендә иләктер.

Төшләреңә кергән җәннәт бармы?
Тәгаенләп белми берәү дә.
Бәлкем, Җир-Анабыз – үзе җәннәт,
Коръән кушкан итеп яшәү дә!

8. Өзәсеңме ожмах җимешләрен?..

Бу хатыма Галәм юлларында
Туры килер озак йөрергә,
Габдеһади кызы Санияне
Үзен тиеш табып күрергә!

Син җәннәттә микән? Әллә бәлкем...
Җәһәннәмдә (Алла сакласын!)
Инша Аллаһ кылган гамәлләрең
Ачсын серле җәннәт капкасын.

Аллаһының рәхмәтләре чиксез,
Гафу итәр булган гөнаһны.
Иманы саф мөэмин-мөселманга
Бүләк итте тиңсез ожмахны.

Шул ожмахның гүзәл сараенда,
Бакчаларын, бәлкем, гизәсең?
Яр буенда зәмзәм суын эчеп,
Ожмах җимешләрен өзәсең.

Ул елгалар хәтерләтә булыр
Тал-тирәкле Мишә буйларын.
Шул талларга басып, өзеп-өзеп,
Язын сандугачлар сайравын.

Охшаганнар микән урманнары
Нарат урманына Шәленең?
Тиңе бармы анда бездәгедәй
Урман аланнары яменең?

Безнең болыннарда шаулап үскән
Чәчкәләргә бармы тиң булыр?
Җир-Ананың гүзәллеген күреп,
Җәннәт үзе, шиксез, таң калыр.

Бармы анда әсир итәр ямьле,
Хәтфә кебек уҗым кырлары?
Шул кырларда алтын башакларның
Бездәгедәй сихри җырлары?

Авыз суың ташый, кулга алсаң,
Күпереп пешкән бодай күмәчен.
Алсу кызыл ап-ак күмәчләрдә
Кешеләрнең йөзен күрәсең.

Елмаялар, бәйрәм итә алар,
Хезмәтләрен күреп күмәчтә.
Тик намуслы хезмәт кешеләрне
Гасырларга илтә үлгәч тә.

Кеше мәшһүр бөек эше белән,
Эше белән данга урала.
Иң зур бәхет – башкаларга шатлык
Бүләк итү булып санала.

... Бозны төртеп умырзая шыта,
Зәңгәр чәчәкләре вак кына.
Яз сафлыгын иң беренче булып,
Бүләк итәргә ул ашыкына.

Бар табигать җәйге күлмәк киде,
Дөнья яшеллеккә күмелде.
Каеннарның бала яфраклары
Кояш нурларына үрелде.

Бакчаларда җимеш агачлары
Шау чәчәккә төрде дөньяны.
Һәр тарафтан тәмле хуш ис аңкый,
Кемнәр бөрки икән соң аны?

Күк күкри, яшен яшьнәп ала,
Утлы уклар телә күкләрне.
Кояш чыга! Салават күпере
Сәламлидер безнең ишләрне.

Төлләр таҗын ачты, керфек какты,
Тамырларга кадәр дәрт үтте.
Күршесендә үскән ландыш кызын
Кочып алды нарат егете.

Дөнья шундый матур! Чидән икән?!
Хатын-кызлар – нурлы гүзәлләр,
Әллә инде тормыш авырлыгын
Бәхет белән тигез бүлгәннәр?

Бармы анда сөю, яратулар?
Үзәкләрне өзәр сагышлар?
Бер хәсрәтсез кеше булмас кебек,
Югалтусыз юктыр табышлар.

Чайкаламы иген басулары,
Иртән искән иркә җилләрдән?
Бөтерелеп күтәрелә микән
Дулкын-рәшә тып-тын күлләрдән?

Бездәгедәй бармы сихри язлар?
Нәрсә чәчеп, нәрсә уралар?
Ризыкларын ничек пешерәләр?
Нәрсә ашап, кайда тораллар?

Җәннәт халкы торган сарайларны
Чи-нәрсәдән, кемнәр төзидер,
Ғармы анда бездәй җитәкчеләр?
Эш барышын кемнәр күзлидер?!

Ир-хатыннар кайда хезмәт итә?
Ә заводлар нинди соң анда?
Җимеш татып, шәраб йотып кына
Яшәмиләр булыр беркайда.

Тамакның тук, өснең бөтенлеге –
Кием тегү, иген игүдә.
Миллиардлаган җәннәт әһелләрен
Яшәтәсе бар ич мәңгедә.

Иртән кояш чыгып яктыртканга,
Чүр чәчкәнгә барча җиһанга,
Табын җәя кеше, җиң сызганып,
Ғар да эшләп тормыш корганга.

Ашау – байдан, үлем – Ходайдан, дип,
Исраф итә ялкау байлыкны.
Күрдек инде, эшсезлектән азып,
Кырын яткан азгын халыкны.

Эшләмәскә төрле хәйлә кора,
Сәбәп таба бу иш хөрәсән.
Җәмгыятьнең соры корты булып,
Яши алар качып хезмәттән.

Күзәнәккә һәрчак азык кирәк,
Тырыш хезмәт бирә ашамлык.
Җан иясе шулай җайлатылган,
Ашамлыксыз тормыш, яшәү юк.

Җир-Анабыз – үз анабыз кебек:
Игелекле, юмарт, шәфкатьле.
Җан иясен алып кочагына
Туендыра, биреп нигъмәтне.

Бәйрәм ашы – кара-каршы булу,
Данлы эшләр бизи кешене.
Бу дөньяда син яшисең икән,
Үтәү фарыз изге эшеңне.

Канун шулай: кырыс кышлар була,
Көләч йөзле дәртле яз килә –
Ямьле җәй кояшы иркәләгән
Ризык булып көзләр өлгерә.

Һәрбер фасыл үз хезмәтен үти,
Һәрбер нәрсә белә үз эшен.
Орлыклардан күкрәп иген үсә,
Һәр үсемлек бирә җимешен.

Берүк җирдә, янәшәдә үскән
Һәрнәрсәнең үзгә җимеше,
Аллаһның бу тиңсез могҗизаны
Гыйбрәт өчен безгә бирмеше.

Табигатьне буйсындырам дигән –
Ул акылдан шашкан, тилергән.
Табигать ул – Аллаһ тарафыннан,
Без – бер каррә анда, бергенәм!

* * *

Иксез-чиксез Галәм. Һәм бер нокта...
Аллаһ аны Җир дип атаган.
Шуның үзле кызыл балчыгыннан
Аң-акыллы затны бар кылган.

Бөртек кадәр шушы җан иясе
Аллаһының тиңсез әсәре.
Могҗизаларның да ул могҗизасы,
Кодрәтенең тиңсез әкбәре[12].

Хак Тәгалә Кадыйр[13], *Халикъ*[14] *заттыр,*
Ул Гадел дә, тиңсез Галим дә.
Тереклеккә Ризык бирүче дә
Мәшһүр Тәрбияче Галәм дә.

Җирдә кешем рәхәт яшәсен дип,
Якты, нурлы кояш кабызган.
Төнлә юлга чыккан адашмаска
Көмеш айга якты тамызган.

Дөрес яшәр өчен кануннарын,
Изге Китапларын иңдергән.
Фарыз гамәлләрне үтәгән зат,
Җәннәт әһле булыр ул, дигән.

Никахлашкан хәләл җефете белән
Торганнарга бирә фатыйха.
Дин-иманлы бала тәрбияләү –
Иң саваплы, изге вазифа.

Яшә җирдә хак мөселман булып,
Коръән кушканнарга тиң итеп.
Мәүҗүд[15], *Әхәд*[16], *Хәййө*[17], *икәнлеген*
Хак Тәгалә тора искәртеп.

---

[12] Әкбәр – бөек.
[13] Кадыйр – көче җитүче.
[14] Халикъ – булдыручы, яратучы.
[15] Мәүҗүд – бар.
[16] Әхәд – бер.
[17] Хәййө – тере.

9. Юк, сорама җәннәт Аллаһыдан!..

Хаталардан кеше хали тугел,
Гөнаһ эшләрне дә эшли ул.
Аллаһ әйтә: "Анаң карынында да
Үзеңне гөнаһлы диеп бел".

Гәрнәрсәнең әүвәл-ахыры бар –
Дөньяларның башы чишмәдән.
Бозыклыклар ана карынында
Әхлак тәрбиясе җитмәүдән.

Яр ишелеп торса, су болгана,
Буып куйсаң, юлын югалта.
Кешеләр дә язмыш ярын ишеп,
Гомер йомгакларын чуалта.

Имеш, аның тәкъдиренә язган
Яман галәмәтләр күрергә.
Чөнки кеше, тәкъдиреннән узып,
Хирыс яман юлда йөрергә.

Утырдың да, син дә, үзең теләп,
Ятлар арбасына ялгышып;
Язмышыңа сылтап, йөрдең кортлап,
Кара йөзләр белән ярашып.

Кем арбасын якын итсәң, шуның
Җырын җырлап, җаен көйлисең.
Әйләнәдә азгын өерләре,
Исерек баштан аны күрмисең.

Бу дөньясы – эт оясы диеп,
Эт типкесен көн дә күрәсең.
Дулкын белән ярга ыргытылып,
Чүп-чар савытына керәсең.

... Җан иясе үз теләге белән
Бу дөньяга килми, китми дә.
Вакыт җиткәч туа, вафат була,
Бер мизгелне хәтта көтми дә.

Бар гамәлләр – Аллаһ кодрәтендә,
Тик ул хуҗа тиңсез бу эшкә.
Ул – бердәнбер! Моны әйтү кирәк,
Сүз калдырмый имеш-мимешкә!

Мәңге яшәр өчен бөтен көчен
Куяр иде хаким бер кемсә.
Кырыр иде барлык көндәшләрен,
Сихри бер көч кулына эләксә.

Белеп, күреп торса да үлемне,
Чыгырыннан чыга берәве.
Яуга йөрү мәкере, хәйлә кору
Шуллы аңа иң-иң кирәге?

Үзе белән беркем берни алмый,
Барысы да кала бу Җирдә,
Ләкин кеше әзер булып торсын
Үзе тиеш һәрбер әҗергә!

Шуңа кеше җиргә килгән көннән
Көне-төне акыл эшендә.
Искитмәле сәнгать әсәрләре
Иҗат итә гомер эчендә.

Акыл һәм хис биреп, сөеп безне
Җир-Ананың иткән хуҗасы.
Яшәү биргән... Шушы гомер юлын
Кешеләрчә безгә узасы!

Итагатьле, мәрхәмәтле булып,
Адәмнәргә тормыш корасы.
Җәннәт кебек гүзәл Җир-Анада,
Игелекле эшләр кыласы.

Нәфесеңнең күзе туймый торып,
Аллаһыдан җәннәт сорама!
Нәрсә җитми сиңа? Йә, әйт, Кешем!
Тәүбә итәреңә соңлама!

август, 2005 ел


بسم الله الرحمن الرحيم
الله لا إله إلا هو الحي القيوم لا تأخذه سنة ولا نوم له ما في السموات وما في الأرض من ذا الذي
يشفع عنده إلا بإذنه يعلم ما بين أيديهم وما خلفهم ولا يحيطون
بشيء من علمه إلا بما شاء وسع كرسيه السموات والأرض ولا يؤوده حفظهما وهو العلي العظيم

Ъыкмыпэ "Адыр Чэрэз дэлэ Чэлие Гъэш1э "Бысымэ" фэш Ч1ыпэкlэ Жъмакlэр
!.. Iэнэкъэ ачкlэчы

Ташлар сере
(поэма)

Көрәк очыннан очып китте чуер таш,
Ғәрелештеләр ак таш белән башка-баш.

"Чок!" иткән аваздан сискәнеп киттеләр,
Үзләрен бер-берсенә таныш иттеләр.

Хикәя кылды чуер таш: "Ғиш йөзләп ел
Зекер иттем җир астында, чыктым быел.

Нигезендә яттым ханыбыз сарае,
Кол Шәриф мәчетендә шуның бер ае.

Кардәш-ыруг сөякләре күп ятмакта,
Оныкларга риза-бәхилләр буллмакта.

Ғирәләр изге гамәлләргә фатыйха,
Кылсыннар рухларыбызга хәер-дога.

Варисларыбыз яуласын чын азатлык,
Ил-җиребездә кол булып озак яттык.

Татарларга берләшергә кирәк күптән,
Мөстәкыйль булып яшәүнең чоры җиткән.

Мин – чуер таш, нык, чыдам таш, чакма түгел,
Ут чыгарырга өндәмим, ният изгел.

Ак ташларны, якташларны бергә туплап,
Дәүләт төзик, телне, динне калыйк саклап..."

Ак таш шунда нык тетрәнеп телгә килде,
Чуер ташның хак-хакыйкать сүзен бүлде.

Сөйләп китте үз башыннан үткәннәрен,
Белгәннәрен, нинди язмыш кичкәннәрен:

"Шан дәүләтне бүлгәләдек ханлыкларга,
Ирек бирәбез, имештер, халыкларга.

Аерылган вак ханлыклар көчсез калды,
Үзара ызгыш-талаштан сүнә барды.

Аерылганны – аю, бүленгәнне – бүре
Ашар, ачысын татыйбыз шуннан бирле.

Хаталардан бәхетсезлеккә тарыдык,
Сусыз калган мичкә шикелле таралдык.

Бастык ата-бабалар баскан тырмага:
Керешеп һәрбер дәүләт кормага.

Явыз дошманнар яу чапты уңнан-сулдан –
Кыбырсынып, таркалуны көткән булган.

Ябырылды ханлыкларга берәм-берәм,
Сүйды-кырды халыкларны дәһшәт белән.

Яшүсмерләр каны акты елга тулып,
Башлар очты, калды милләт өнсез булып.

Каһарманнар яу кырында баш салдылар,
Карт-карчыкны корбаннар кебек чалдылар.

Хатын-кызны, балаларны кол иттеләр,
Әбер ишләр ирексездән тәре үттеләр.

Идел-Чулман дәрья булып кан-яшь акты,
Таярь ирләр ирек даулап яуга чыкты.

Бетте Урда, аннан ханлыклар таркалды,
Китте хөрлек, ил сатылды, дин сатылды.

Сыкрана ошбу афәтләрдән Җир-Ана,
Кайгы-хәсрәттән әле дә утта яна.

Әйтә: "Бәддогам илбасар улларыңа,
Кара язмыш ятсын барыр юлларыңа.

Күрмә син, җыйган малыңның бәрәкәтен,
Тауга тынмасын илеңдә, ут һәм төтен".

II

Бу каргышларга күкләр дә "Амин" диде,
Фәрештәләр Аллаһ каршысына килде.

Диделәр: "Әйт, тиңсез көч-кодрәт иясе,
Сөекле өммәтеңә бу ни бәласе?"
Диде Аллаһ: "Аларга Коръән иңдердем,
Кануннарын үтәп шәп яшәгез, – дидем.

Мөселман кардәшен, берүк рәнҗетмәсен,
Аны саклап, аны яклап җанын бирсен.

Арканыма нык тотынса ошбу милләт,
Рәхмәт-шәфкатем ирешер, булып хөрмәт.

Ислам диненә иман китергән халык,
Алыр беркөн хөррият һәм хәләл байлык.

Бу фаҗига алар өчен сынау иде,
Үнаһ-хаталар җәзасын күрсен инде".

Явыз патша кат-кат яман фәрман бирде,
Шәһәр, авыл, җиребезгә дошман керде.

Күпләп алар яшен-картын чукындырды,
Чукынмаган инсаннарны су тындырды.

Хак мөселман ил, диненә тугры калды.
Куе урманнарга качып, сихәт алды.

Керәшеннәр җир-суларга хуҗа булды,
Тик исем һәм җисеменнән мәхрүм калды.

Алар бүген дә торалар аваз салып,
Шан милләтебез тәнендә яра булып.

Шул ярадан әби-бабам каны саркый, –
Алар динен сатканнарга ләгънәт укый.

Илен саткан, динен саткан – үзен саткан,
Сатлыкҗан дигән хурлыкта гүргә яткан.

Ятлар җиренә күмелә агач табут.
Өч аршин җир һәркемгә була табып.

Сатлыкҗанга байлыгын бирсә дә дошман,
Үз илендә түгелдер ул хәтта олтан.

Киллмешәк ул анда, бай булып калса да,
Мал-мөлкәтләр, исем, дәрәҗә алса да.

"Поганный татар" хәзер дә безнең исем, –
Икенче сорт халык итеп тотар өчен.

Дүрт йөз илле ел ятка хезмәт кылабыз,
Бетеп бара гореф-гадәт, дин-йолабыз.

Илбасарның эте-бете безне изә,
Шул золымга, мәсхәрәгә халык түзә.

Көн күрәбез илбасар-залимга ярап,
Хөрмәткә лаек түгел без аңа карап.

Илсез калдык, җирсез калдык, телсез калдык,
Дошманнарның дәвамына җирлек салдык.

Ятлар белән катнаш гаиләләр корабыз,
Ә үзебез чиләге гөлдәй корыйбыз:

Катнашларда[18] *урыс телле бала үсә,*
Денсез татар үз тамырын үзе кисә.

Хөсетлек тә, көнчелек тә, мин-минлек тә
Татар белән яши бирә илинлектә.

Татар башын татар ашый элек кебек,
Бер-берсенә аяк чала әләк түгеп.

Дошмалар, гаярь ирләр таратылды,
Кем кыйналды, кем иленнән озатылды.

Өстәгеләр алдап, талап байлык җыя,
Мескен халык үлемтек акчасын җуя.

Түрә үзгә, динче үзгә, халык үзгә,
Бу өчлекнең берләшүе кирәк безгә.

[18] Катнаш – буйдыр, өметсез.

Кул кушырып карап тору – зур җинаять,
Ирек өчен көрәшергә тор, җәмәгать!

Үткәннәрдән нәтиҗәле сабак алыйк,
Нык ташлардан ышанычлы нигез салыйк.

Гәйкәл булып күккә ашыйк Казансуда,
Шәһид киткән каһарманнар булсын сында.

Балкып торыр ул изге җаннарның нуры,
Халкыбызның юлы һәрчак булыр туры.

Гәйкәл белән Сөембикә манарасын,
Салават күпере кочар ике арасын.

Кояштан нур, айдан алырбыз яктылык,
Балкырбыз ак һәм чуер таш якташ булып.

Туплау-барлау кирәк сибелгән татарны,
Бер учка җыю зарури без таркауны!

Халкыбызның көч-куәте – бетмәс дәрья,
Тик оешканлык, бердәмлек җитми аңа.

Аң-акылы, дәрт-дәрманы хәттин ашкан,
Ләкин динсез, телсез калып, ул адашкан.

Милли аң күк асыл сыйфат кире кайтсын,
Үз илендә татар бәхет-тәүфыйк тапсын!

Булмасын яман гадәтләр йортыбызда,
Калсын алар гыйбрәт булып артыбызда.

Хөсетлек, көнчелек чире кимермәсен,
Йортыбызны ызгыш-талаш җимермәсен.

Милләт көче, киләчәге – бердәмлектә,
Дин гыйлемен, фән гыйлемен белгәнлектә.

Халкыбызга әдәп-әхлак, гореф-гадәт,
Мәдәният, әдәбият итсен хезмәт.

Мәгърифәт ислам диненә сугарылсын,
Изге Коръән кануннары хөкем кылсын.

Кирәкмәстер чит дәүләтнең закуннары,
Үзебезнең милли дәүләт кирәк бары.

Шартнамәләр төзеп хәер сорамыйбыз,
Тик мөстәкыйль булсын Идел-Уралыбыз!

Мәңге яшәп, ул кояш кебек балкысын,
Башка милләтләр дә шатлык, бәхет тапсын.

Йә, чуер таш! Тәкбир әйтеп чыгыйк юлга,
Милләттәшләрнең тоташсын кулы кулга!!!"
октябрь, 2003 ел

Хатын-кызга мәдхия

I

И хатын-кыз, кем син? Фәрештәме?
Аллаһыңмы әллә шәүләсе?
Әллә җиргә токым үрчетергә
Җибәрелгән Галәм бәндәсе?

Илаһилык
Аллаһыдан әллә салынган?
Камиллегең, серле гүзәллегең
Галәм, Кояш, Айдан алынган?

Кем син? Хәтта Алла каргышыннан
Курыкмыйча алма өзүче?
Кеше дигән могҗизалы затка
Яшәү биреп учак өрүче?

Ир-атларның күңеленә утлы
Наз, Мәхәббәт, Сөю саласың.
Дөньяларның бөтен мәшәкатен
Иңнәреңдә тартып барасың.

Әле генә син – ата баласы,
Әле генә – сөю ярасы.
Әле генә үзең – гади хатын,
Үзең пәйгамбәрләр Анасы!

Кем син? Сихри, нәфис, сылу ханым,
Үзең чибәр, үзең сөйкемле?!
Үзең юмарт, шәфкать-миһербанлы,
Алыштырдың Җирдә син кемне?

II

И хатын-кыз! Илаһи зат итеп,
Ғәрчак сиңа караш ташладым.
Яшерен сөеп, эчтән генә көеп
Ғомер кичтем, гомер башладым.

Иркәләгән дә – син, яраткан да,
Ғуры да син җирдә тормышның,
Изге ният белән яшәү биргән
Бисмилласы тәкъдир-язмышның.

Хак Тәгалә юкны бар итүче!
Җир-Анабыз юмарт сый бирә!
Ә хатын-кыз, сөеп һәм яратып,
Җирдә аллаш – Кеше үстерә.

Анасының тылсым күкрәгеннән
Илчәк бала ала нигъмәтен,
Мәхәббәтнең күкрәп яшнәвендә –
Ир-ат тоя сөю кодрәтен.

Караттыра, яраттыра белгән
Якты йолдыз, йөзек кашыдай.
Елмаюың җанда ут уйната,
Карашларың – яшен ташыдай.

Итәгатьлек, сабыр-түземлегең
Ихтыярың килә йөрәктән.
Әхлак-әдәп, тәртип һәм тәрбия –
Хатын-кызга бәйле, димәктән!

Зирәклегең, акыл, тапкырлыгың –
Иланының тиңсез бүләге.
Адәм булып Җиргә килү өчен
Шул бүләкнең булган кирәге.

Фигыль-холкың, рухи ихтыяҗың
Риза буллмый җәннәт ашына.
Ярты алма биреп, йөгән салдың
Гамль-шөгыльсез Адәм башына.

Теләмәде сау-сәламәт рухың
Җәннәт колы булып калырга.
Син ашкындың Адәм белән бергә,
Җирдә яшәп, ләззәт алырга.

Чрсәләнде нәҗмиз саф күңелең
Мөлдерәмә сөю, наз тулы.
Җылы куеныңда иркәләнде
Хыялыңда йөргән Җир улы.

Ай-Кояшлы якты бу дөньяда
Килде синең Ана буласың.
Әни булып, сөеп һәм сөелеп,
Бу җиһанга игелек кыласың.

Хатын булып, ир-ат тәмен тоеп,
Гаилә корып Җирдә яшисең.
Бала дигән татлы-утлы затның
Күреп шатлык, ачы-төчесен.

Ни яме бар дөнья, табигатьнең –
Язлар килеп, бөре шытмаса?
Ни яме бар Җирнең, әгәр анда
Болын-кырлар, урман буллмаса?

Тәвәккәллəп әгәр син киллмәсәң,
Мәхрүм булыр иде Җир-Ана.
Гәрбер Ана үз баласын кочып,
Гаилә учагында юана.

Кайгы-хәсрәт, газап-михнәт күреп,
Сафланса да кеше күңеле.
Ғәркем җиргә шат, бәхетле булып,
Яшәр өчен килә, билгеле.

Җир-Ананың яме, гүзәллеге –
Күнермәсе бакый җәннәтнең.
Бер күрүе үзе чиксез бәхет,
Кадерен белсәң шушы кыйммәтнең.

Ғади генә сыман үсемлекләр,
Ғәрбер җан иясе – могҗиза.
Рәхәтен күр диеп, Алла биргән
Шушы байлыкларга син – хуҗа.

Дөньяга – ямь, тормышка тәм биреп,
Яши кеше, кылып тантана.
Яшә, Ана – игелекле җан син,
Яшә Ғаләм, яшә Җир-Ана!

III

И мөкатдәс татар хатын-кызы!
Үзең – горур, кыю, тәвәккәл.
Милләтеңә асыл дәвам биргән
Ғыйбадәтле, тыйнак, син – гүзәл!

Аллаһыдан иңгән иман нуры,
Ислам дине балкый үзеңдә.
Ғәва-Ана Җәннәттә тешләгән
Алма алсулыгы йөзеңдә.

Миһербанлык, шәфкать, инсафлылыгың
Әби-бабаң мирас бүләге.
Төс-кыяфәт, күркәм буй-сыныңда –
Татарларның милләт бизәге.

Чыныктырды сине Дала җиле,
Иркәлидер Идел кояшы.
Сихәт-куәт бирә Җир-Ананың
Бисмиллаңны әйткән сый-ашы.

Күңел күгең – йолдызлы төн кебек
Сер сандыгы, сихри тирәнлек.
Нарасыйдай ихлас елмаюың –
Язгы гөлбакчага тиңләрлек.

Сөю-сөелү, яну-көю өчен,
Кирәк булган Җиргә килүең.
Үзенә күрә бер мәгънә бирә
Үпкәләвең, "дулый" белүең.

Мөселманлык, әхлак кануннары
Мирас итеп сиңа бирелгән.
Гасырларның тиңсез хәзинәсен
Милләт өчен сакла, диелгән.

Әби-бабаң Ислам тәрбиясен,
Әдәп-гадәт, йола калдырган.
Аерылган башлар – гәүдәләрдән,
Аерылган нәсел тамырдан!

Кылыч аша үткән шәһидләрнең –
Шәкертләрнең рухын рәнҗетмә.
Милләтеннең тамырларын кискән
Төссез-хиссез маңкорт үрчетмә!

Рәнҗемәсен чиркәү нигезенә
Кыстырылган кабер ташлары.
"Лә иләәһә илләллаһу!" – диеп
Шәһид киткән өммәт башлары.

Һәр кавемне Алла үз иманы,
Үз мәсләге белән яраткан,
"Үз ишеңә иш-кардәш бул!" – диеп,
Фатихасын биреп тараткан.

Үзебезнең гореф-гадәтләрдән
Мәхрүм итмә газиз балаңны.
Хәер-догаңнан ташлама, берүк,
Күптән мәрхүм әби-бабаңны.

Һәлакәткә илтмә нәселеңне,
Милләтеңә итмә хыянәт.
Тамырыңнан аккан татар каны –
Татарыңа булсын әманәт.

Чын татар бул! Милли горурлыгың
Югалмасын барыр юлыңда.
Ятлар арбасында бара калсаң,
Дилбегәсе булсын кулыңда.

Буыннарның бердәмлеген сакла,
Милләтеңнең акла өметен.
Суырып ал, читләр куенында
Кыйбла җуйган татар егетен.

Яхшылыгың җирдә ятып калмас,
Игелектән шытыр игелек.
Ислам берләштергән кыз-егетнең
Кан-тамыры булыр мәңгелек.

Коръән-Кәрим тотып, балаң калыр
Иң мөкатдәс теләк, үй белән.
Бисмиллалы эш-гамәлең калыр
Дәүләт белән, халкың, ил белән.

И, асыл зат – татар хатын-кызы,
Холкың – күркәм, үзең – сөйкемле.
Ятлар белән ятма, динең сакла,
Бул намазлы әбкәң шикелле!

Хәрам ашап, хәрам эчкән йортка
Бәрәкәтле бәхет иңмәячәк.
Чәчең белән җирен себерсәң дә,
Чит милләткә син – тик киллмешәк.

IV

Татар телле, Ислам динле булу
Гыч китермли йөзгә кызыллык.
Тел, динебез – дөнья тирәли без
Аяк терәп җирдә торырлык.

Нәселебез Мисыр, Шумерлардан
Утлар-сулар кичеп береккән.
Дистә мең ел төрки кавем булып,
Данлы-шанлы озын юл үткән.

Ул юлларда авыл һәм шәһәрләр,
Ханнар хәзинәсе күмелгән.
Мәгърифәт, фән, сәнгать, әдәбият
Асыл энҗе булып сибелгән.

Милләт Аналары! Рәхмәт әйтеп,
Башым иям сезләр алдында.
Җир нигъмәте, җәннәт рәхәтләре –
Аналарның аяк астында.

Тик бер Алла – тиңсез һәм мәңгелек
Иксез-чиксез бакый Галәмдә.
Хатын-кызның җирдә мәңгелеге –
Ана була алган гамәлдә.


ای فلان! کیف أطلک
Игелек кылсаң — үзең өчен,
Яманлык кылсаң — шулчагы үз үзеңә.
Коръән, 17/7
إن أحسنتم لأنفسكم
وإن أسأتم فلها
قرآن ۱۷/۷
سیف سرایی "گل ستان بالتورکی" ۱۳۱۱ اپچیل

Йә, әйт, Кеше!

I

Алдау, ялган, хәйлә, хыянәт һәм...
Абау ямьсез "букет" син, Кешем.
Котсыз әхлак, гадәт, сыйфатларга
Уралырга кайчан җитештең?

Ә бит үзең – гүзәлләрдән гүзәл
Аллаһ могҗизасы син – Адәм.
Аның тиңсез иҗат көч-кодрәте,
Үзең – җанлы гаҗәп бер Ғаләм.

Елмайганда йөзең нуры белән
Кояш кына, бәлкем, тиңләшә.
Балкып торган серле күзләреңнән
Йолдызлар да хәтта көнләшә.

Бер карасаң – тәүфыйк, итагатьле
Фәрештәләр кебек изге җан.
Бер карасаң – синең вәхшилектән
Асты өскә килә бу җиһан...

Бер карасаң – аңлы, акыллы зат,
Игелекле гадел, дус, иптәш.
Бер карасаң, син ерткычтан-ерткыч,
Юлларыңда үлем, канлы яшь.

Синең кыргыйлыктан, җаһиллектән
Җирләр, күкләр ярсып тетрәнә.
Шартлаулардан атом дәһшәтенең
Урман, кырлар чүлгә әйләнә.

Явызлыгың, усаллыгың белән
Тиңләшә алмый бер җан иясе.
Үзен аскан, суйган, золым кылган
Ул син – кеше – үлем шәүләсе.

Үз балаңны табып багар өчен
Нинидәр көч сарыф итәсең.
Үсеп буйга җиткән газизеңне
Бер мизгелдә юк та итәсең.

Йә, әйт, гүзәл, аңлы, акыллы зат!
Яшәвеңнең нидә мәгънәсе?
Кеше булып, җиргә килгән көннән
Кан түгәсең Алла бәндәсе.

Адәм улы Һабил үтерелгәч,
Җиде кат күк әрнеп елады.
Фаҗигане белеп, фәрештәләр
Аллаһыга сыкрап сүз салды:

"Җир өстендә хәлифәме булыр
Кан коючы Адәм баласы?"
"Шул Адәмгә һәр җан иясенә
Боерылды сәждә кыласы..."

Булды җавап, Яшен ялкыннары
Ялт-йолт килеп, дөнья айкады.
Нәфрәтләнеп Илаһи көч җирне
Һәлак итте: гыйбрәт күпләргә.

Туфан купты, тузан өермәсе
Бөтерелеп аште күкләргә.
Бәндәләрен ут, су белән Аллаһ
Һәлак итте: гыйбрәт күпләргә.

II

Дөньядагы аңсыз җан иясе
Җан асрар өчен җан кыя.
Зиһен-аңга ия Кеше заты
Кеше җанын кыеп мал җыя.

Мин акыллы, диеп масаясың,
Үз-үзеңә әле бер кара!
Нәфсең өткән юлда – хәрабәләр,
Корбан кала, хәсрәт, кан кала.

Кан-яшь түгеп, байлык туплау өчен
Сугышасыз һаман үзара.
Тамаклары туйгач, ерткычлар да
Башкаларга өлеш чыгара.

Сиңа, Кешем, шәфкать-мәрхәмәтле
Миһербанлы булу тиешле.
Тиеш буллмаганны аласың син,
Умырасың алтын-көмешне.

Сый-хөрмәтен мулдан биргән Җирне,
Табигатьне көн-төн талыйсың.
Җир астында яткан байлыкларны
Үзеңнеке итеп саныйсың.

Мөлкәтеңнең исәп-хисабы юк,
Җиде буыннарга җитәрлек,
Подвалларда яшерелгән алтын
Үзеңне дә күмеп китәрлек.

Үзең туйсаң, күзең туймый һаман,
Туплаганың һаман аз сыман.

Акыллымы, әйтик, кесәсенә
Миллионнарча хәрам мал җыйган?

Алтын-көмеш, энҗе, асылташлар
Затлы ташлар, ләкин аш түгел.
Кешелекнең иң күп өлешенең
Өлеше юк, алар ач буген.

Алдап-талап җыйган кеше хакы
Күңелләрдә нәфрәт уята.
Гәм кешеләр, үз хакларын даулап,
Сезнең ишеләргә ут ата.

Тик берәү дә үзе белән аллмый,
Җир өстендә кала байлыгы.
Гүр иясе булган бәндәләрнең
Бар байлыгы – тик баш казыгы.

Ахирәттә исәп-хисапларга
Кылган эш-гамәлең алыныр.
Мизаннарның бер ягына – савап,
Бер ягына гөнаһ салыныр.

III

Тырәләрнең мәнфәгатен яклап
Күпме асыл ирләр үлмәгән?
Дошман диеп, каршы якка ата
Бersen-bersе һич тә белмәгән.

Ә зиннәтле мәрмәр сарайларда
Зур түрәләр табыш бүлешә.
Хәләл көчен куеп, тир түккәнгә
Исем бирә, медаль өләшә.

Кеше хакын урлап баеганның
Ояты юк, күзен кан баскан.
Нәфесләрен тыя аллаганнар
Намусларын саткан, югалткан.

Ләкин бай да, ярлы-ябагай да
Ахыр чиктә – тик гүр иясе.
Анда синең малың, даның да юк,
Иң кыйммәте – гамәл бәясе.

IV

Йә, әйт, Кеше! Җирдә хаким булып,
Бармы чынлап рәхәт күргәнең?
Таныйсыңмы фарыз гамәлләрне,
Кануннарын изге Коръәннең?!

Нинди мирас җирдә калдырасың?
Кылган эшең нидән гыйбарәт?
Тамчылардан күл җыела. Тамчың
Китерәме илгә бәрәкәт?

Утырттыңмы бакча, салдыңмы йорт?
Инсафлымы, Кешем, дәвамчың?
Үтисеңме Аллаһ кушканны син,
Саф вә изгеме соң иманың?

Никахлашкан асыл ярың белән
Күркәм, тату гаилә кордыңмы?
Сиңа ризык, яшәү биргән затка
Руза тоттың, намаз кылдыңмы?

Яхшы кеше булу авыр шөгыль,
Игелекле булу – тагын да.

Кеше бәхет таба, мәхәббәте,
Иман торса күңел сагында.

Аңла, кешем, минем бу сүзләрем
Нәсыйхәт тә түгел, үгет тә.
Гөнаһлардан арына алмассың син
Соң көнендә Коръән үбеп тә...

Без, гөнаһсыз сабый бала булып,
Шыр ялангач Җиргә киләбез.
Яхшы, яман юлны үтәбез дә,
Кәфенлектән гүргә керәбез...

Памир

(поэма)

Тау белән тау гына очрашмый.
Халык мәкале.

Бу әсәрне төрле кеше төрлечә кабул итәр. Кемдер әйтер: "СССР күптән таркалды, Памир чит дәүләтләрдә калды, аны язудан ни мәгънә?" – дияр. Әмма кемдер мине аңлар: Памир – безнеке, Җир йөзендә яшәгән миллионлаган кешеләрнеке. Бу бөек тау – бер генә, бердәнбер. Солдат хезмәте елларымны, яшь чагымның күпмедер бер өлешен, шул тауда чик сакчысы буларак үткәрдем мин. Әйләнәм дә кайтам, әйләнәм дә кайтам мин Памирга. Яшьлегемә кайтам. Хәерлегә булсын...

1. Очрашалар таулар...

Очрашалар таулар, очрашалар,
Әйтерсең лә таулар тоташ алар,
Бер-берсенә бик тә охшаш алар,
Очрашалар таулар, очрашалар.

Очрашалар төрле кыяфәттә,
Табигатьтә, хәтта... сәясәттә.
Очрашалар хәтер түрләрендә,
Очрашалар алар мәхәббәттә.

Очрашалар ак болытлар аша –
Түбәләре тауның күккә аша,
Очрашалар безнең язмышларда,
Очрашалар әрнү-сагышларда.

Очрашалар безнең шатлыкларда,
Очрашалар хәтта каргышларда.
Очрашалар таулар, очрашалар...
Әйтерсең лә таулар тоташ алар.

Менсәм дә мин Әфган тауларына,
Йөрмәдем мин Әфган яуларында,
Солдат идем, чик сакчысы идем,
Мин Памирга килеп башым идем.

Чикнең аның чиге чикләнмәгән,
Чик – бикләнгән, күңел бикләнмәгән.
Бу гамәлдә юктыр һичбер шигем:
Сез килегез, ачам чикнең биген!

Очраштырам сезне таулар белән,
Очраштырам сезне Памир белән,
Тубәләре күккә ашкан Памир
Җирдә тора ныклы тамыр белән.

Сез килегез! Әмма, белү кирәк:
Таулардан да бөек булсын йөрәк!
Сез киллмәгез тауга даулар белән,
Сез киллмәгез тауга яулар белән!

Тау өнәми тупас адымнарны,
Тауның аның кайтавазы каты –
Тау яратмый әрсез алымнарны.
Тау үз итми холкы тауга ятны.

Тауга менеп, таудан төшкәнем бар,
Тау елгасы суын эчкәнем бар.
Тарлавыклар аша үткәнем бар,
Тау башында күкне үпкәнем бар.

Үрдән аска карап торганым бар,
Таудан биек уйлар корганым бар,
Тавышланмас таулар – шаулар гына,
Таудан биек – бары таулар гына!

Яши алар күңелем түрләрендә,
Бер менәрбез Хәтер үрләренә.
Ямьле җәйләр, көзләр, кышлар,
язлар –
Кайтыр әле булып кайтавазлар.

Очрашалар таулар, очрашалар,
Әйтерсең лә таулар тоташ алар.
Бер-беренә гаҗәп охшаш таулар
Йөрәгемдә минем тоташалар.

2. Хәтер түбәләре

Менә, Памир!..
Җилләр уйнап торган
Түбәләре акка төренгән.
Шул түбәләр калкып чыга бүген
Хәтеремнең иң-иң түреннән.

Менә, Памир...
Күпме гасырларның
Серен салган бу тау үзенә.
Үзән белән күк тоташа монда,
Киек төшә киек эзенә.

Тау битендә – сарык көтүләре,
Тарлавыкта – архар... меңләгән!
Менә, Памир!

Сөзәк итәкләрен
Иген басулары иңләгән.

Җем-җем килеп җемелдәшә күллар,
Яшел хәтфә – елга буйлары.
Тугайларда гөл-чәчәкләр балкый,
Гүрләп тора бөҗәк туйлары.

Менә, Памир...
Әфган җиле иссә,
Әтеп ала Пәнҗ[19] камышын.
Монда миңа һәрбер куак таныш,
Һәр сукмакның таныйм тавышын.

Беләм кайда иген иккәннәрен,
Кайсы җирдә кайда үскәнен.
Кайсы кышлак кайда кышлаганын,
Кайсы кышлак кая күчкәнен.

Ничә еллар күзалдымда йөрде,
Төшләремә керде шан Памир!
Сакта торган чик буйлары якын,
Әйтерсең лә, Памир – туган җир.

Кайчак Памир балкый-балкый көлә,
Бар да матур, бар да җитешле,
Кыр казлары гүя сәлам бирә,
Баш очыннан очып үтешли.

Памир кырыс, табигате кырыс –
Чебен-черки тауда безләми,
Памир халкы монда тормыш кора,
Бәхетне ул читтән эзләми.

[19] Пәндж – Таҗикстандагы елга.

Гәркем өчен туган туфрак изге,
Ул кадерле, кырыс булса да.
Кендек каны тарта кешеләрне,
Читтә рәхәт тормыш корса да.

Кайта сагынып солдат булганнар да,
Ата-бабасының җиренә.
Кырыс Памир сыный кешеләрнең
Мәхәббәтен туган иленә.

Ургып чыккан кайнар чишмәләрнең
Суы татлы, дәва итәрлек.
Тәнгә – сихәт, җанга көч-дәрт бирә,
Саф һавасы, исең китәрлек.

Менә, Памир!
Илебезне саклап,
Өч ел чиктә үтте төннәрем.
Биш мең метр биеклектә яшәп,
Чик буена көн дә йөргәнем.

Гомеремдә булды үр менгәнем,
Биек-биек таулар күргәнем.
Тик буллмады ләкин бер тауның да
Язмышыма шулай кергәне.

3. Нурлы йомгак

Памир төне. Кузачкысыз буран.
Яхшы хуҗа кумас этен дә.
Сулышыңнан чыккан парлар шундук
Эленеп кала яка читендә.

Без үтәсе дозор суклмакларын
Кар-киртәләр кат-кат киртләгән.

Буранларны монда чикләп буллмый,
Кем бар аның юлын бикләгән?!

Без дозорда икәү. Юк-юк, дүртәү! –
Ике ат, мин һәм дә Абашев.
Абашев та кайчак әйтеп куя:
"Йөрибезме әллә адашып?!"

Ә мин аны, имеш, юатмакчы,
Атларны да телим акларга:
"Син борчылма, туган, атлар исән!
Адашалармыни ат барда?!"

(Мин, чыннан да, атлар белән үстем,
Хәтеремдә тәүге атым да.
Төнге учак... Болын. Ат көтүләр,
Туган аулым Субаш-Атында).

Атка аңа ышанырга була,
(Юл югалту егет эшеме?!),
Буранларда алып кайтты атлар
Юл югалткан күпме кешене!

Без дә менә кайтыр юлга чыктык,
Язмышка һәм атка ышанып.
Ә атларның керфекләре – бозда,
Үзләре дә калган өшәнеп.

Басу-кырда юлны таба атлар,
Тояк тоя юлның катысын.
Атның җаны тоя авылының,
Үз өенең җылы якты сын.

Ә монда – таш, көртле суклаклардан
Атлый атлар бөтен көченә.
Шул көртләрне ерып чыгабыз да,
Югалабыз буран эчендә.

...Һәм каршыда кинәт – кышлак уты,
Менә бит ул, шатлык! Йа, Хода!
Утлар яна, кемнәр сөйләшәләр?..
Тавыш килә бик тә якында!

Мин ул чакта йөрәгемне кыстым
(Укучылар мине аңласын),
Абашев та уйлап өлгергәндер,
Туганнарын, газиз анасын.

Минем дә бит күзалдымнан үтте
Әти-әни, якын туганнар.
Казан үтте... Шунда, "Меховой"да
Мине көтеп калган сөйгән яр.

Заставада калган дус-ишләрем,
Командирлар үтте – барысы да.
Өнсез калып басып тордык бер мәл
Без дүртебез кышлак каршында.

Шик калмады: аяк табанында
Тойдык хәтта шушы шикне без,
Суклак эзләп, Әфган җирләренә
Үтеп чыкканбыз ич чикне без!

Ә ул чакта... (һәм монысын инде
Белгән кеше генә хәтерләр.
Ә калганнар: " Ул чак басмачылар
Беткән инде", – диеп әйтерләр).

Мең тугыз йөз илле бишенче ел
(Дөресен әйтик, нәрсә кылсак та!),
Буранлы төн илтеп кертте безне
Басмачылар торган кышлакка.

Мин яшь идем, комсомолец идем –
(Укучылар дөрес аңласын),
Мин Аллага дәштем... Абашев та,
Уйлагандыр үзенең Алласын.

Үлем безнең янәшәдә иде,
(Без яшь һәм дә үлемсез идек!),
Хәзер сөйлим инде курыкмыйча,
Әфган чиген узган – без идек.

Аңга килеп... Кире ашыктык без,
Томырылдык буран эченә.
Бер үлемнән качып, яңасына
Атлау җиңел, димсез, кешегә?!

Без буранда юлны тапмас идек,
Туңар идек, бәлкем, боз булып.
Чәкъ шул чакта кинәт... алдыбыздан
Нурлы йомгак узды сузылып.

Чәкъ шул чакта... чынлап әйтәм моны:
Мин ышандым Хөкемдарыма –
Барлыгына һәм дә берлегенә,
Ышандым мин Аллаһ барына.

Нур артыннан атлап киттө атлар,
(Рәхмәт инде, рәхмәт атларга!).
Нурлы йомгак юл күрсәтеп барды,
Күрде моны безнең атлар да.

Без барабыз... Буран куа килә,
Кар-көрт ята безнең эзләргә.
Заставабыз "в ружье!" га баскан,
Төркем чыккан безне эзләргә.

Чик буе шул... Кайсы солдат монда
Солдат өчен утка кермәгән?!
Тик ни гаҗәп: безнең нур йомгагын
Заставада беркем күрмәгән.

Ә без күрдек! Чикне бозган идек...
Тик бозмадык ләкин без антны.
Чынлап әйтәм: шул нур шары безне
Заставага кадәр озатты.

Яшь чаклар шул...
Юкса шактый күргән
Ялганын да инде, чынын да.
Бу турыда начальникка әйттек,
Эләгәсен белеп җәзага.

Без гаепле идек, әзер идек.
Инде хәзер нәрсә күрсәк тә.
"Шпион" нар булып, ГУЛАГ дигән
Җәһәннәмгә барып керсәк тә.

Башлык безне сүзсез тыңлап торды,
Йозагына бикләп бүлмәсен.
Приказ итеп әйтте: "Ошбу хакта
Заставада һичкем белмәсен!.."

Әйе, башлык шулай диеп әйтте,
Безгә шәпләп йодрык "иснәтте".
Бу тормышта яхшы ялган барын,
Яман ялган барын күрсәтте.

"Сез әйтмисез моны яшереп тә,
Сез әйтмисез моны ялгышып.
Сез бары тик үзебезнең якта
Кар-буранда йөргән адашып!"

Бу "сәяхәт" ярты гасыр буе,
Үзарада калды сер булып.
Ярты гасыр бу сер бәгыремне,
Һаман телә яман чир булып.

Мин хәзер дә уйлыйм: авыр хезмәт
Сындыраллмый солдат канатын,
Командиры әгәр яклый белсә,
Саклый белсә үзенең солдатын.

... Тышта буран. Застава да җылы!
Туң кайтудан тәннәр чемерди.
Бөркеп тора кайнар чәйнең пары,
Учакта ут балкып җемелди.

Өстәл өсте ризык белән тулы,
Җаның теләгәнен алып кап.
Җан да, тән дә ләкин шуны сорый:
Ятагыңа тизрәк барып ят.

Тешне-тешкә сугып туңуларны
Застава да яхшы беләләр.
Үз өстеннән алып, синең өскә
Кат-кат итеп юрган өялар.

Юк, бер генә түгел, күп тапкырлар
Өшедем мин әфган җилендә.
Биш мең метр биек тау башында,
Сакта чакта илнең чигендә.

Әшулай да, Памир миңа якын,
Памир яши кайнар канымда,
Мин дуслыкның ни икәнен белдем,
Тагын бер кат тудым Памирда!

4. Җаннар табышу

Үсмер чакта мин бер йомык булдым,
Кызлар кулын хәтта тотмадым.
Җибәрмәде кулны ишек бавы,
Әтисезлек дигән тотканың.

Әйе, шулай: чынлап йомык идем,
Мәхәббәтнең тәмен белмәдем.
Кайберәүләр кебек, адым саен
Кызлар алыштырып йөрмәдем.

Унбиш яшьтән цех ишеген ачтым,
Чүкеч, игәү алдым кулыма.
Гүдок авазларын ишетүгә,
Иртүк чаптым завод юлына.

Мин әтисез үстем. Әти сүзе,
Нәсыйхәте кирәк бер чакта,
Әллә ничек кенә тартылдым мин
Калын романнарга, китапка.

Минем юлым роман геройлары
Йөргән тарафлардан агылды.
Әйтә иде әни: "Бу малайга
Китап җене, ахры, кагылды".

Әтиемне көтеп яшәдем мин,
Әй, авыр шул, төгәл белмәгәч, –
"Гәлак булды..." дигән хәбәре дә,
Башка хәбәре дә килмәгәч.

Үрсәләнеп өметләнде күңел,
Юк, исәндер әти, исәндер! –
Мин үзем дә әле, бәлки аны
Бер очратыр өчен үсәмдер?

Әтисезләр шактый... "Билгесез" ләр
Бер мин генә калдым түгелме?
Билгесезлек дигән шомлы бер хис
Ныграк талый икән күңелне.

"Ғәлак булды..." Монысы да авыр:
Йөрәгеңнең олы ярасын,
Бер кузгатып, бер юатып яшәп,
Үзең белән алып барасың.

Билгесезлек исә эчтән талый
Өзмәс-куймас талый җаныңны.
Мин хәтерлим, кызалларга теләп,
Җүләрләнә язган чагымны.

Кайда әти? Соңгы тамчы каны
Кайда тамган, кайда түгелгән?
Ни рәвешле үлгән? Ни рәвешле,
Кайсы тарафларда күмелгән?

Үрсәләнеп янә кайтып төшәм:
"Юк, исәндер әти, исәндер!
Мин үзем дә аны кочагыма
Кысып елар өчен үсәмдер?.."

... Буранлы кич. Майор Виковшинин
Дәшеп алды мине үзенә.
Таныш түгел сәер дулкынлану
Чыккан иде аның йөзенә.

Мин төз басып аңа рапорт бирдем,
Хәрби Устав таләп иткәнчә.
Көткән идем бер-бер махсус бурыч...
Тик булмады ул эш көткәнчә.

Гәм шулай ук көтмәгәнчә иде –
Сүзен саф татарча башлавы,
Күзләренең кинәт дымлануы,
"Улым..." диеп әйтеп ташлавы.

Урыныннан торып каршылады,
Иңнәремә салды кулларын.
"Сине күрсәм, – диде һаман саен
Искә төшә сугыш елларым..."

Тып-тын калып, сүзсез торды майор,
Үрсәләнеп, мин дә төбәлдем.
Аның бик зур бер сер әйтәчәген
Сизеп алды шунда йөрәгем.

Сүзләрен ул өзеп-өзеп әйтте,
Туры карап минем күземә:
"Әҗәлләрдән авыр... Әмма бүген
Әйтми кала алмыйм үзеңә.

Син гафу ит, әгәр күңелеңнең
Яраларын кабат яңартсам,
Сүнгән учак көлен таратам дип,
Утлы күмер көлен таратсам.

Өзелмәгән өметеңне өзсәм,
Күңелеңне китсәм кабаттан.
Тик мин сине, инде ничә айлар,
Аераллыймын Абдул-солдаттан.

Буең-сының, бөтен кыяфәтең
Әтиеңә шундый охшаган.
Ике тамчы су бөртеге кебек,
Әйтерсең лә кисеп каплаган.

Йөзең синең – дустым Абдул йөзе,
Йөрешләрең, холык-фигылең.
Йә, әйт хәзер әтиеңнең синең
Минем дустым Абдул туғелен?!"

Майор сөйли, ә мин өнсез калып,
Ғәрбер сүзен тыңлыйм йотылып:
"Абдул белән "Суслонгер"да булдык,
Мең бәладән калдык котылып.

Ә аннан соң – Волхов сазлыклары...
Чолганышта калган көннәрдә,
Сыкранмады атаң, чая иде! –
Арысланга була тиңләргә.

Бер-бер артлы фашист танклары
Өстебезгә килде ыргылып.
Меңнәр ятып калды шул сазлыкта,
Окоп кырыена егылып.

Ике солдатка бер мылтык иде,
Патроннар да калды санаулы.
Дошман безне дәһшәт белән кырды,
Меңнәрдән тик берәү сау калды.

Кул сугышы барды – рукопашный,
Таныйм, улым, таныйм хатамны:
Мин ул чакта саклап калалмадым,
Калалмадым саклап атаңны!

Ә ул һәрчак янәшәмдә булды,
Ул һәр мәлдә мине саклады,
Аяк астындагы гранатаны
Үз гәүдәсе белән каплады.

Рукопашный иде... Син беләсең,
Син аңлыйсың инде калганын.
Без чигендек. Әтиеңнең хәтта
Гәүдәсен дә җирли алмадым.

Сугыш кыры, мәхшәр кыры була,
Шуңа күрә мин дә акланмыйм.
Рөхсәт итсәң, атаң кебек итсәң...
Күз карам күк сине саклармын.

Мин – Тәтештән. Чуаш.
Без якташлар,
Бер бит безнең, улым, туган җир.
Сине күрсә, әй сөенер иде,
Дустым минем – Абдул-баһадир.

Улым, диеп дәшәм сиңа бүген,
Син бу сүздән, зинһар, каушама.
Безнең хәлдә ата белән бала
Менә шулай гына күрешәала.

Мин дә ялгыз. Мин фронтта чакта
Газизләрем үлгән ачлыктан.
Безнең җаннар, улым, бу сугышка
Мәңге бетмли торган ут йоткан".

Майор мине кочагына алды,
Күкрәгенә кысты иркәләп,
Бөртек-бөртек кайнар яшьләребез
Битне өтеп алды тәгәрәп.

Ата-уллы итеп булмаса да,
Без туганнар кебек яшәдек.
Карт полковник Виковшининны без
Туган Тәтешенә җирләдек.

Ә ул чакта майор әйткән хәбәр
Тетрәндерде мине, тетрәтте.
Ләкин тормыш бала чактан мине
Сыгылмаска ныклап өйрәтте.

Әти исән, дигән өметемне
Тәмам җуйдым, тәмам югалттым.
Ә үземне "Мин әтине таптым!"
Дигән уйлар белән юаттым.

Һәм хәзер дә әйтәм (сезгә дә бит
Туры килер моны танырга);
Әти җаны минем җанны танып,
Мин әтине таптым Памирда!

Ак болытлар тау битләрен юып,
Әкрен генә үргә агыла.
Шул тауларны сарып алган кебек,
Бәгырьләргә сагыш ягыла.

Сугыш чоры балалары дигән,
Буын күрде газап-михнәтне.
Әтиләргә без алмашчы булдык,
Үзебез эшләп таптык икмәкне!

5. Сынаулар, сыналулар

Дәүләт чиге. Монда – хәрби тәртип,
Кырыс монда тормыш агышы.
Сакка китә наряд... Ә кемнеңдер
Заставага кайтып барышы.

Сактан кайтучылар ял иткәндә
Икенчеләр эшкә күмелгән.
Төтен чыга мунча морҗасыннан,
Юылган кер бауга эленгән.

Заставаның такта идәннәре
Памир кары кебек агарган,
Ашханәдән килгән тәмле исләр
Бүлмәләргә кереп таралган.

Кемдер әнә судан кайтып килә,
Кемдер күмер илтә мичләргә,
Кемдер көри ишегалды карын,
Эшсез булсаң монда нишләргә?

Кырык тапкыр карап яттан белгән
Кинонымы кабат карыйсың?
Ике дистә китап арасыннан
Инде тагын кайсын сайлыйсың.

Гәркем эштә. Кемдер атлар карый,
Печән, солы сала атларга.
Монда шулай: атны саклау кирәк,
Үйлыйм дисәң чикне сакларга.

Ат – якын дус... Әйтүчеләр булыр:
"Бүлмас – диеп, атка чуртым да!"
Кайсы дустың сигез, тугыз сәгать
Йөртер иде сине сыртында?!

Атны сакла, атны тәрбиялә,
Кызганма син аттан печәнне!
Күпме атлар монда, безнең кебек,
Тешсез калды, туңды, өшәнде?!

Ул тарлавык сукмаклары буйлап
Җәяүле дә үтмәс таяксыз.
Күпме атлар тояк салды монда,
Күпме атлар калды аяксыз?!

Илле градуслы салкыннарда
Сакта тору җиңел дисеңме? –
Әйтү генә, йөртү генә ансат
Чик сакчысы дигән исемне!

Әнә, алга башын ия төшеп,
Ике җайдак бара чик буйлап.
Таш арасын, дозор сукмакларын
Өеп киткән буран, кар сылап.

Юлдан язган һәм адашкан атлар
Кар кибәннәренә төртелә.
Бөтерелеп күккә ашкан буран
Ишелеп төшә алар өстенә.

Тарлавыктан искән Әрган җиле
Үзәкләрне айкый түреннән.
Чырайларны ялап, өтеп ала,
Атлар туктый барган җиреннән.

Куеныңа кергән ул суыклар
Тән җылысын алып җәзалый.
Борыннардан аккан сулар ката,
Бер ачылса авыз – ябыллмый.

Катып калган төссез иреннәр дә
Төшәр сыман биттән өзелеп.
Бияләй каплап бераз җылыткач та,
Сыкрый башлый алар, җан өзеп.

Җелекләр дә катып кала сыман
Котырынган шушы җилләрдән.
Әле ярый, "Меховой"дан кызлар
Безгә бүләк туннар җибәргән.

Әфган җиле әгәр котырынса,
Сулышларга каба, тыннарга.
Мондый чакта хәтта туңып кала
"Меховой"да теккән туннар да!..

Кислород юк тауда, һава җитми,
Аһ, ул көннәр җанга уелды.
Өч ел буе тауда. Өч көне дә
Кайчак өч ел булып тоелды.

Кояш чыкса, ак кар күзне кисә –
Карап буллмый тауда карга да.
Хәзер әйтәм кайчак үз-үземә:
Зарланма син, тауны каргама!

Юк, каргамыйм... Чик сакчысы идек,
Төшмәсен тап безнең йөзләргә!
Үтсә дошман чиктән, ил буенча
Туры килә аны эзләргә...

Чик буенда тору – чат башында
Тору түгел, кызлар сагалап.
Үз эшеңне монда, үз көчеңне
Йөрү кирәк төгәл чамалап.

Мургабтагы штаб, төп отрядтан
Заставалар тора ераста.
Чик йозакта... Әмма үзебез дә
Яшәдек без гүя тозакта.

Тозакта шул. Читтә, тау башында,
Нур хастасы алды күбебез.
Меңчакрымнар читтә чиктә торып,
Сакладык бит туган илне без!..

... Кичке сигез. Заставада – приказ,
Гичкелгә юк монда ташлама:
Сакчыларның, атлар, этләрнең дә
Хезмәт көне кичтән башлана.

Заставада дежур – ул диспетчер,
Нарядларны юлга әзерли,
Бар да тәртиптәме? Наряд үзе
Чик буена юлга әзерме?

Дежур белә кайчак кемнәрнеңдер
Приказны да бозган чакларын.
Бергә хезмәт иткән солдатларның
Белә йомшак, көчле якларын.

Заставада дежур торган чагым,
Урап кайтыйм дидем постларны.
Тышта салкын!..
Төкрек җиргә төшми,
Җәлләп куйдым сакчы дусларны.

Гөнаһ шомлыгыдыр, старшина –
Ул да бүген миңа иярде,
Карап чыктык барлык постларны без,
Эт оясын, торак-өйләрне.

Ат абзары.
Дневальный!..
Пароль?!

...
Черем итә атлар аранда.
Ялитәләр атлар. Ә нишләп соң
Иярләнгән атлар бар анда?

Әйе-әйе, абзар почмагында
Иярләнгән ике ат тора,
Без торабыз моңа гаҗәпләнеп,
Дневальный да сүзсез тик тора.

Бу атларны кемнәр иярләде?
Дәшми солдат, аста күзләре.
Кинәт кенә искә төште шулчак
Дус-ишләрнең әйткән сүзләре.

Кайбер наряд, имеш, салкыннарга
Җиткән инде тәмам "күнеген",
Чик буена бармый, йорт-курада,
Печәнлектә ята күмелеп.

Һәм нәкъ шулай!.. Сидоров һәм Козин
Бик тә җылы урын тапканнар,
"Печән алырга дип барганнар" да,
Печәнлеккә кереп ятканнар.

Дневальный яшь. Болар –
"Карт солдатлар",
Болар белә тормыш хәйләсен,
Белмәгәннәр ләкин тикшерергә
Старшинаның да киләсен.

Акланалар. Алар, имеш монда
Печән алырга дип килгәннәр.
Хуш ислесен сайлап алыйк диеп,
Бераз озаграк йөргәннәр.

Старшина көлде – "хет атларны
Калдырырга иде иярсез,
Безне алдап булыр... Тик намус бар,
Аңа менә нәрсә диярсез?!

Чик буе бу! Чик бозучы, бәлки,
Күптән инде йөри бу якта!.."
Күреп торам, егетләрдә хәзер
Курку да бар, һәм бар... оят та.

Старшина кыза: "Сезнең гаеп!
Хатагызны үзегез көйләрсез.
Печәнлектә печән эзләдек дип,
"Намус суды"нда да сөйләрсез!"

... Заставада гаупвахталар юк,
Суд-фәләннәр юк шул бу якта.
Алар Мургаб, штаб, отрядта,
Алар бездән бик тә ераката.

"... Намус суды..." Анда һәрбер дустың
Синең хакта әйтә фикерен.
Сидоров һәм Козин тыңлый әнә
Бүген "Намус суды" хөкемен.

Юк, суд аңлый: мондый салкыннарда
Шундый хәлгә килеп җитәрсең.
Печәнлеккә түгел, җир ярылса,
Җир тишегенә кереп китәрсең.

Һәм аңлый суд: әйе, чик буе бу,
Чик акламый мондый гаепне.
Чик бозучы бер гаепле булса,
Антын бозган – мең кат гаепле!

Һәркем белә, аңлый бу хөкемнең
Солдат йөрәгендә каласын.
Сакла, Ходам, солдат иптәшләрнең
Хөкем сүзен ишетү язмасын!..

Кече гөнаһ... Бәлкем зурлары да,
Булгандыр ул гөнаһ, булгандыр,
Кемдер ялгыш хаталанып куйган,
Кемдер белми гөнаһ кылгандыр.

Төләкесен кемдер кабызгандыр,
Яткан чакта, сакта – "секрет"та.
Печәнлеккә кереп күмелгәндер
Алтмыш градуслы суыкта.

Булгандыр ул гөнаһ...
Әмма әйтмим:
Ул гөнаһлар киткән очракта,
Ул гөнаһның тик бер генә өне
"Югары"га җиткән очракта,
Гаеплене җәза көтә иде
Штрафбатта төрле сроккa.

Заставада ләкин беркайчан да
"Өйдәге чүп" читкә чыкмады.
Җәзаны ул үзе белеп бирде,
Гөнаһлы да йөзен сытмады.

Кемдер, әйтик, бик тә дөрес санап
Гомум җыелышның фикерен,
Хезмәттән соң ай буена юды
Заставаның булган бар керен.

Кемдер, әйтик... Хәер, нигә сөйлим
Күптән булып узган хәлләрне.
Гаепләрне без кичерә белдек,
Безне менә Памир жәлләрме?

Ул үзенең кырыс холкы белән –
Бездән дә шул холык сорады.
Биш мең метр биеклектә тордык,
Гай, сынады Памир, сынады!

Әнә, тышта ачы Әфган җиле
Гасырларның карын туздыра,
Әле ярсып улый, әле шыңшый,
Әле аждаһа күк ыжгыра.

Гәр тарафта болытларга ашкан
Кыя-таулар баскан тырпаеп.
Бер мизгелгә ай күренеп китә,
Зөһрә кыз да карый моңаеп.

Шул арада еллайгандай була,
Ай яп-якты, Зөһрә сөйкемле!
Туганнардан, сөйгән ярлардан ул
Гүя сәлам әйтә шикелле.

Бернәрсә дә үтми эзсез генә,
Җөе кала йөрәк түрендә.
Төшләремдә һаман чик буенда,
Хезмәт итәм кайчак бүген дә...

6. Языгыз хатлар

Кыенлыклар, сизәм – вак хатирә,
Памир калсын үзе урынында!
Сөйлим әле сезгә, сагыну-сагыш,
Мәхәббәт һәм кызлар турында.

Монда шулай: сәлам, хат-хәбәрне
Язга чыккач кына аласың.
Әңдәге хәлләрне дә кайчак
Ел буена белми каласың.

Айга бер көн, бәлкем, ял бирерләр,
Якаңны тек, хатлар язып сал.
Хатлар китми моннан, хатлар килми,
Ачыллыйча кардан перевал.

Яңа елның сәлам-котлауларын
Май аенда гына аласың.
Кышлар буе язган хатларыңны
Соң булса да илтеп саласың.

Хат килгән көн – бәйрәм, ыгы-зыгы,
Үз уена чума бар кеше.
Үзгәрә дә куя кинәт кенә
Солдатларның атлап йөреше.

Үзгәрер шул Абашев шикелле
Бер килүдә алсаң кырык хат.
Бер-берсенә ялгап буллый хәлне,
Укысаң да көнгә кырык кат.

Хат алганнар белә гаиләсендә
Күптән булып үткән хәлләрне.
Йөрәк аша һәм үткәрә алар
Гәммә сүзне, һәммә хәбәрне.

Мин дә алдым андый хәбәрләрне,
Соңлап кына килгән хатларны.
Әй, шул чакта өзелеп сагынулар,
Юксынулар туган якларны!

Ђерничә хат сеңлем Рәисәдән,
Өйдәгеләр исән, сәламәт!
Әнинең дә ҡәтләрен язган,
Дусларыңа, дигән, сәлам әйт!

Саниядән хатлар! Ђер дистә хат –
Һаз һәм җылы бөрки алардан.
Әй, рәхәт ул, дуслар, әй, бәхет ул
Хатлар алу сөйгән ярлардан!

Меховойның кызлар бригадасы
Күп сәламнәр юллый икән бит.
Фабрикадан безгә җылы туннар
Җибәрергә уйлый икән бит!

Эш планын алдан үтәгәнгә
Премия бүлеп биргәннәр.
Шул акчага кызлар тун теккәннәр,
"Ђездән бүләк булсын", – дигәннәр.

Кат-кат укыйм хатын Саниянең,
Яттан беләм һәрбер җөмләсен.
Күз тимәсен инде Саниямә,
Кызларга да күзләр тимәсен!

"Күңлә байрак – безнең бригадада,
Ул әле дә безнең кулларда...
Ђерләшмәнең мактау тактасыннан
Елмаялар безнең кызлар да...

Ђергә төшкән рәсемеңне күргәч,
Үзең кайткан кебек хис иттем.
Синең белән ихлас горурланып,
Кызларга да илтеп күрсәттем".

Саниянең шундый хаты да бар,
Дүрт кыз язган уртак хат та бар.
Аһ, яшь чаклар! Мондый хатларда соң
Нинди гаеп, нинди хата бар?!

Ә бер көнне безне шаккаттырып,
Заставага килде посылка.
"Меховой" лар сүзләрендә торган –
Ап-ак туннар киндер капчыкта.

Зур капчыкның киң авызын бөреп,
Сургуч салып, мөһер сугылган.
Әйтерсең лә анда кызларның да
Асыл вәгъдәләре салынган.

Гәр тунга да кызлар имза куйган
Айгөл, Иркә, Ләйсән, Илсөяр.
"Ап-ак туннар кебек күңелебез,
Без булырга риза сөйгән яр".

Кызлар язган: "Таудай сәламәтлек,
Зур уңышлар сезгә телибез.
Бүләк тунны киеп йөргән чакта
Я нәшәдә без дип белегез..."

Менә шулай... Кызлар әле, димәк,
Өметләр дә баглап калганнар.
"Егетләргә истәлеккә" диеп,
Рәсемнәрен хатка салганнар.

Заставада зур җыелыш булды,
Рәхмәт хаты яздык кызларга.
Хәрби антка өстәп без сүз бирдек:
"Тап төшмәс, дип, ап-ак туннарга.

Җан җылыгыз сеңгән шул туннарны
Кигән егет яхшы белә ул.
Илнең чиге ышанычлы була,
Тотса гына бердәм кулны кул".

Кызлар язган уртак хатларына
Без дүрт егет яздык җавапны.
Имза салдык... Димәк, бу хат өчен
Дүртебез дә хәзер җаваплы.

Расих, Ирек, Наил... Йөрәкләргә
Бөек вәгъдә сүзен үйгандай.
Без кул куйдык бергә, бик тә мөһим
Документка кулны куйгандай.

Янып-көеп, мәхәббәткә үреп,
Вәгъдә сүзен яздык кызларга:
"Сез көттегез, кызлар, без кайтырбыз,
Без кайтырбыз килер язларда!.."

Әйе, шулай... Без дүрт егет бергә
Туй итәргә сүзләр куештык.
Ах, бу яшьлек... Язмыш... Тик ул чакта
Вәгъдәләшкән иде нык дуслык.

Вәгъдәләрнең соңын сорамагыз,
Сакланыгыз яшен ташыннан.
Йөрми бәла агач башларыннан,
Бәла йөри кеше башыннан.

Бу дөньяны үз кулында тоткан
Дәһшәтле дә язмыш йөретә.
Эчәсе су, ашар ризыклары
Кешеләрне утка керетә.

Еллар үтте, күпме сулар акты,
Дөньяларның холкы үзгәрде.
Хәтеремдә Памирга еш кайтам,
Яшьлегемә төбим күзләрне.

Мин Памирга киләм, башым иям,
Беллим, Памир мине танырмы?
Кырыс та ул, назлы да ул Памир,
Мин сагынам һаман Памирны...

Яшьлегемдә калган егет һаман
Хат язадыр әле кызларга:
"Көтегез сез, кызлар, без кайтырбыз,
Без кайтырбыз килер язларда!.."

7. Ярым көтә

Заставада "отбой", "подъем"нар юк,
Бердәмлек бар монда, тәртип бар.
"Дедовщина" дигән яман чирне
Ишетеп тә белми солдатлар.

... Дәүләт чиген бүлеп Пәндж ага,
Атлар атлый сөзәк ярыннан.
Таң беленә. Сихри моң агыла –
Азан моңы Әфган ягыннан.

Үзәнлектә торган Госхан постын
Кем үткәргән икән ут аша?
Крепостьтан хәрабәләр калган
Кем үйнаган канлы тамаша?

Шул җимерек ныгытмага карап,
Иректән авыр сулыйсың.
Чик сакчысы уйламаска тиеш
Уйларны да кайчак уйлыйсың.

Тау битләрен төреп, пәрдә элеп,
" Утлап" йөри кысыр болытлар.
Үзәнлектә – томан, без – дозорда,
Кыл өстендә торган минутлар.

Яр буйлатып икәү барабыз без,
Күз күрерлек ара калдырып,
Көтелмәгән хәлгә әзер булып,
Карабинны иңнән салдырып.

Атларның да колаклары сакта,
Аңлый булыр хәлне атлар да:
Алар хәтта сирәк пошкыралар
Дозорларда йөргән чакларда.

Без – дозорда. Ә күңелнең никтер
Гел матурлык эзләп барышы.
Бу якларны чынлап яраттым мин,
Җанга якын халкы, тарихы.

Таҗикстан! Үзәннәрең якты,
Күккә ашкан биек тауларың,
Кай тарафтан үтте Македоннар,
Әермәдәй килгән яулары?!

Күпме ирләр синдә учка кыскан
Хакыйкатьнең утлы күмерен! –
Сәгъди узган гөлбакчалар буйлап,
"Бустон" белән бизәп гомерен.

Синдә язган Габдрахман Җәми
"Йосыф вә Зөләйха" әсәрен.
Шул мәшһүрне укып сихерләнгән
Мин инде ул – исәр Мәҗнүнең!

Синдә туып Бохарага килгән,
Таяк тотып, сукыр Рудәкый.
"Шаһнамә" се белән бар дөньяны
Таң калдырды улың Дәкыйкый.

Таҗикстан! Асыл ирләреңне
Рөстәм батыр итеп күрдем мин.
Фирдәүсинең тылсым дөньясында
Мең ләззәтләр чигеп йөрдем мин.

Таҗикстан! Оеп тыңладым мин
Дәһканнарның җырлар сузганын.
Хәйлә корып түгел, кәйлә тотып,
Таба алар җирдән үз нанын.

Таҗикстан! Чик бер каракүзең
Кыстамады синдә калырга?!
Юк, шаяртам... Илдә ярым көтә,
Сау бул, димен бүген Памирга!..

8. Хушлашу

Әй, мәһабәт Памир! Кар тауларың,
Кыяларың күккә кадалган.
Биеклекне алдың кайлардан син,
Бөеклекне алдың кайлардан?

Яр астыннан ургып, ташлар ярып,
Ташып чыга кайнар чишмәләр.
Ул чишмәләр хәтерем ярларына
Әле дә булса агып төшәләр.

Чуер ташлы үзән, уйсулыкта
Әрлән чаба, җимгә кызыгып.
Куе камыш арасыннан чыгып,
Көзән, елан ята кызынып.

Тугайларда кош-корт чыр-чу килә,
Бөркет оча күктә тын гына.
Аһ, сабыр ит, Памир! Фатиха бир
Уллары̆ңның чыккан юлына!

Аһ, дәһшәтле Памир! Башбирмәс тау!
Чи газаплар бу тау йоттырмый?
Кирәк икән – үзе тота Памир,
Читкә-ятка кулын тоттырмый.

Кул бирми ул килгән-киткәннәргә,
Үз итмәсә, якын күрмәсә.
Кем ни әйтер, әгәр Памир сине
Кар-буранга төреп җырласа?

Эчләрендә әче җилләр улый,
Илле градуслы салкыннар.
Әле дә ярый: безнең йөрәкләрдә
Памир аңлый алган ялкын бар.

Сынау үттем синдә өч ел буе –
Кышлар, язлар, көзләр, җәйләрен.
Биш мең метр биеклектән күрдем
Бөркетләрнең канат җәйгәнен.

Без дә бөркет идек... Әмма дөрес:
Бөртек идек Памир каршында.
Хәтергә мин махсус теркәмәдем,
Бер сөйләрмен, диеп барсын да.

Памир минем яңь-яшь йөрәгемә
Үзе кереп калды уелып –
Кыргый холкы, табигате белән
Якыннардан-якын тоелып.

Сау бул Памир! Инде хушлашабыз,
Син онытма!.. Мин дә онытмам!
Син бит минем солдат чакларымда
Күз карасы күргән ныгытмам!

Саубул, Памир! Сукмакларың буйлап
Мин кабаттан инде үтәлмам.
Итәгеңә ятып ял итәлмам,
Түбәләргә менеп җитәлмам.

Саубул, Памир! Атлар иярләнгән
Перевалга тикле барырга.
Соң түгелме? Күңел үрсәләнә:
Бәлки әле тагын калырга?

Юк шул инде! Соңгы саубуллашу,
Соңгы әмер бездән атларга.
Сау бул, Памир! Солдат егетләрең
Юл чыгалар туган якларга!..

Саубул, Памир! Сиңа һич үпкә юк
Үзәкләрне безнең өзгәнгә.
Син үзең дә шаккатасың булыр
Сынауларга безнең түзгәнгә.

Борма-борма текә юлларыңнан
Упкыннарга карап үтәбез.
Бер баскычка менеп җитәбез дә,
Яңа түбән төшеп китәбез.

Машиналар ыңгырашып уза
Тарлавыклар, таулар арасын.
Менә-төшә Памир юлы буйлап,
Ошка кадәр әле барасы.

Барган саен, Памир тубәләре
Элеккечә күккә үрелер.
Меңчакрымнар юлны узгач кына
Ош шәһәре таудан күренер.

Күренер ул гүзәл Ош шәһәре,
Җимеш бакчасына күмелеп.
Тау ягыннан искән талгын җилләр
Фирганәгә өрә, үрелеп.

Ош шәһәре... Монда – сафлык, җиләс,
Тау һавасын сулый чишмәләр –
Кар-таулардан чыккан ул чишмәләр
Арыкларга агып төшәләр.

Ош шәһәре. Сөләйман пәйгамбәрнең
Тау өстендә ята җәсаде.
Тауга менеп халык дога кыла,
Аны кече Мәккә ясады.

Изге чишмә монда тау астыннан
Зәмзәм суы булып тибәдер.
Суын эчкән – дәва, сихәт алыр,
Бар сырхауларыннан терелер.

Ош шәһәре! Вокзал. Саубуллашу.
Якын дуслар керә кочакка.
"Очрашырбыз! Кабат очрашырбыз,
Чишләсәк тә, нәрсә кылсак та".

Командирлар тели хәерле юл,
Чәсыйхәтләр бирә кабаттан.
Йә хуш, Памир! Имин яшә, Памир!
Бәркетләрең кайта солдаттан.

... Еллар узды. Тормыш сынауларны
Гиҗ кызганмый бирә кешегә.
Гомерем буе мин тауларда йөрим,
Памир керә минем төшемә.

Памир дәшә мине яшьлегемә,
Шундый якты, матур тау булып,
Мин ышанам, очрашырбыз, Памир,
Икебез дә исән-сау булыйк!

Очрашырбыз. Я нә ышанам мин
Син танырсың мине, танырсың,
Йөрәгемдә минем бу дөньяда
Иң биек тау булып калырсың!..

9. Әйләнәм дә карыйм

Каршы алды мине газиз туганнарым,
Өч ел көтеп алды сөеп йөргән ярым.
Сүрелмәгән иде вәгъдәләр һәм антлар,
"Я вып" кына торды сагынулы хатлар.
Без дүрт егет кайттык ерак чик буеннан,
Бергә язган ул хат китми һич уемнан.
Кемдер көтеп алды, кемдер ятка калды,
Я змыш безне шулай утка-суга салды.
Кемдер артка калды, кемдер китте алдан,
Кемдер кичаллмады язмыш-перевалдан.
Кеше шулай инде: алга карап яши,
Тормыш куа килә, сорамый ул яшең.
Без Сания белән матур гаилә кордык,
Балалар да үсте, яратышып тордык.
Тормыш алга куйды җитди сорауларын,
Өеп-өеп бирде авыр сынауларын.
Килсен ул сынаулар, җәлләү өмет итмим,
Памир сынауларын үткән егет бит мин!

Памир түбәседәй ак чәчемне тарыйм,
Яшьлек елларыма әйләнәм дә карыйм.
Гомер көчен кеше шул яшьлектән ала,
Яшьлек уза-китә, хәтер исән кала.
Памир карый миңа шул ук биеклектән,
Памир саклый мине алган "бөеклек"тән.
Әй, ул хәтәр ялган, илгә оялаган,
Кемнәр аны шулай кәсеп итеп алган?
Хакыйкатькә табан әллә юл өзекме,
Чигә күтәрәләр икейөзлелекне?
Хөсетлек һәм мәкер сагалаган чакта,
Күпме игелекләр елап кала чатта?!
Таныйм сине, Памир!
Эзлим сине күптән –
Саклап калдың мине барча түбәнлектән.
Бардыр – ашар ашым, бардыр – яшәр яшем,
Чик соң сиңа, Памир, гел табынып яшим?
Сиңа таба бармый, тагын кая барыйм? –
Әйләнәм дә карыйм, әйләнәм дә карыйм.
Синең кырыслыгың – дөреслегең синең,
Шуңа да бит сине гел яратып сөйлим.
Ялган биеклекләр сиңа торырлыкмы?!
Синнән алам, Памир, көчне, горурлыкны!
Синнән алып яшим – йөрәк дәрманнарын,
Авырлыклар күрдем,
Күрдем – зарланмадым.
Сине уйлыйм Памир, бәлаләргә тарсам,
Сине уйлыйм һаман, юлларымда арсам.
Хәтеремдә һаман ямьле үзәннәрең,
Үзгәрмәдең, Памир, җанда үзгәрмәдең.
Сиңа бармый Памир, тагын кая барыйм?
Әйләнәм дә карыйм, әйләнәм дә карыйм!

август, 2006 ел

Безнең заман
(Шигъри хикәя)

Аш ашадым, яшь яшәдем, шөкер,
Яшем чыкты сиксән ягына.
Саф күңелем бала чакларымны,
Яшьлек елларымны сагына.

"Сугыш елы балалары" дигән
Мин ямаулы буын баласы.
Мең мәхшәрне кичеп, исән калып,
Картлыгыма булдым барасы.

Бала чаклар, безнең яшьлек чоры,
Авыр еллар аша сыналды.
Яшьтәшләрем тормыш чоңгылына
Мәңгелеккә төшеп югалды.

Ул елларда, фронт өчен диеп,
Бар ашлыкны җыеп алдылар.
Көнне-төнгә ялгап эшләгәннәр
Ач-ялангач торып калдылар.

Яшь үсмерләр, арык атлар белән
Сукалады басу-кырларны.
Чәчте-урды, ындыр табагына
Ташыдылар кырдан урганны.

Таңнан торып һәркем эшкә барды,
Ун-уникe яшьлек үсмер дә.
Болыннарда ашар үлән беткән,
Башаклар да әле үсемдә.

Бер чокыр сөт, черек бәрәңгенең
Кәлҗемәсе – табын ризыгы.
Бер тәгамсез калган кешеләрнең
Алабута булды азыгы.

Кышын өшеп, җәен ачтан цлдек,
Сугыш барган авыр елларда.
Кайгы-хәсрәт, ачы кцз яшьләре
Көткән безне барыр юлларда.

Сугыш беткәч, без дә цсә төшкәч,
Таралыштык илне төзергә.
Кандалалы бараклар да гця, –
Хан сарае иде безләргә.

Аннан-моннан тормыш корган булдык,
Сәбәп таптык хәмер эчәргә.
Денсез-динсез, гореф-гадәтләрсез
Керештек без гомер кичәргә.

Бала-чага ясле-бакчаларда
Атеистлар булып цстеләр.
Халыкларны тамырыннан йолкып,
Ата-баба телен кистеләр.

Үз телендә эти-әниләргә
Бала белән сөйләц тыелды.
Милләтләрне, "совет халкы" итеп,
Руслаштыру алга куелды.

Кара тәнле, сары тәнлеләр дә...
Урыс булды, кысык кцзләр дә.
Тик урысның цзенә хас милли
Төсе бетте аума йөзләрдә.

Үзәннәргә җәелгән торгын су
Җир-анага сеңеп югала.
Үз юлыннан аккан елгалар тик
Диңгезләргә таба юл ала.

Үз йөзеңне, үз төсеңне җуйсаң,
Җиһан халкы сине танымый.
Кабак зур да... Тик берәү дә аны
Базар күрке итеп санамый.

Бог-Алласыз шушы кабак буын
Буыннарның җебен югалтты.
Әдәп-әхлак белмәс наркоманнар
Спид афәтенә юлыкты.

Ата – улын, ана кызын белми,
Акка кара кереп буталды.
Хатын-кызлар ярымшәрә калды,
Оят, намус, вөҗдан югалды.

Юл читендә азып-тузып беткән
Фахишәләр тора тән сатып.
Талибәләр сынау-имтиханны
Секс белән бирә төн ятып.

Базарларда халык сәүдә итә,
Сату-алу – илнең бар эше.
Мал сатыла, монда ил сатыла,
Сатучылар бар да бай ише.

Шушы байлар илне-җирне талый,
Ришвәт ала затсыз һәр түрә.
Байлык өчен бугаз чәйнәшәләр,
Банкирларны киллер үтерә.

Ил эчендә эчке сугыш бара,
Көн дә атыш, көн дә үтереш.
Саксыз калган халык – яшәү белән
Үлем арасында көнкүреш.

Сәрхүш ирнең, сәрхүш хатын-кызның
Ач-ялангач яши гаиләсе.
Наркоманга тик бер доза тора
Кеше җаны, кеше бәясе.

Тимер ишек, тимер рәшәткәләр
Бикләп алды кеше торагын.
Туган белән туган йөрешмиләр,
Белешмиләр ничек торганын.

Гәммәсе үз казанында кайный,
Карт-корылар ачтан интегә.
Очын-очка ялгый алмаганнар
Басып тора ярның читендә.

Алар – теге сугыш елларының
Корбаннары булган инсаннар.
Газап чиккән, кан-яшь түккән җаннар
Соңгы барыр юлга чыкканнар.

Авырлыкка кеше түзә икән,
Сабырлыкта икән түземе.
Илне-җирне талап баеганнар
Әҗәл җитми үлә түгелме?

12 март, 2008 ел

بسم الله الرحمن الرحيم

الحمد شکر و سپاس اول احد ملکی دایم بی زوال اول صمد
ملکت ایچره بلا شرک اول احد آنی باقی ذوالجلال بلدك ایمدی

آندن صونکره اونیک عیبنا شهیدلر ولی آنلرك وصفین قرآن ایچره اوکدیکجه
نهی دقت عطا و برمش اکا غفار : جمیع قرآن خطاسزین دوشمش ایمدی

آندن صونکره اونیک عیبنا شهیدلر ولی آنلرك وصفین قرآن ایچره اوکدیکجه
مشهور لکی لا سیف الا ذوالفقار لا فتی الا علی کمثلی ایمدی

آندن صونکره حشرکیم علی کمثلی یوزینك هوا رعسکر اولوب سیاسنلر
یار اولیا حاضر کلدی دوتیا دی عمر آنلك صدق فی قولارین آرتیر ایمدی

آندن صونکره اول صدیق صاحبار غار اچینده مصطفانی دوتدیلر اولیا
یوز رنگ ایدن آرتیر ایردی آنلرك فضلی تورینك تورینك قلمش ایمدی

آندن صونکره اونیک عیبنا شهیدلر ولی آنلرك وصفین قرآن ایچره اوکدیکجه
نهی دقت عطا و برمش اکا غفار : جمیع قرآن خطاسزین دوشمش ایمدی

آندن صنکره آننك دوستی محمد پیغمبر لرگزیده سی اول احمد
قاب قوسین مقامی اول احمد آننك اوزره تسلیم درود اولسون ایمدی

قل علی « قصه یوسف »

Дүртьюллыклар

(Дини мотивлар)

* * *

Күк йөзендә кояш чыкса, ай калыкса,
Җир йөзендә, димәк, тормыш дәвам итә.
Кояш чыккан, Ай калыккан Җир-әнкәдә
Изгенең дә, явызның да көне үтә.

* * *

Бу дөньяның азгын-явыз бәндәләре,
Фанилыкта яшәсә дә мул-рәхәттә...
Ләкин алар бар да тәмуг кисәүләре,
Изге гамәл кылганнар тик булыр җәннәттә.

* * *

Ай, кояш, йолдызлар балкый зәңгәр күктә.
Байларга да, ярлыга да бер үк микъдар.
Берәүләрнең зиһен ягы хәттин ашкан,
Берәүләрдә тинтәклек мул. Кем хөкемдар?

* * *

Әйтәләр: "Теге дөньяда рәхәт булыр,
Монда ярлы – тегесендә кәеф кылыр".
Кәеф кылу – гөнаһ кылулардан торса,
Оҗмахларда кемнәр генә торып калыр?

* * *

Азгын хисләр урап алса кеше җанын,
Котсыз нәфес кочып аллак булыр барын.
Җефетләре, хур кызлары җитмәс аңа,
Җәннәттә дә тартып алыр кеше ярын.

* * *

Ике җенес булган җирдә мәхәббәт бар,
Мәхәббәтнең җимешләре – ул балалар.
Дөнья булгач, яхшы, яманы да туа,
Ата-ана бала өчен гөнаһ кыла.

* * *

Гауга купса – ызгыш-талаш, сугыш китәр,
Сәрхүш бәндә бер-беренең башын тишәр.
(Тьфү-тьфү) алар җәннәткә дә керсә,
Шәраб инеш-елгалары кибеп бетәр.

* * *

Җәһәннәмдә газап чигә бер адәмнәр,
Аларның нинди гөнаһ һәм гаебе бар?
Фанилыкта язмышлары язган юлны
Кайгы-хәсрәт, михнәт чигеп үтте алар.

* * *

Аллаһының рәхмәт фәрманы иңмичә
Яфрак та селкенмәс, диелгән Коръәндә.
Туган көннән алып үлгән көненәчә
Хак Тәгалә әмерендә яши бәндә.

* * *

Мөселманга дүрт хатын да рөхсәт, имеш,
Ярый әле дүртнең берсе булса һәйбәт.
Якты дөньяң болыт белән капланачак,
Дүрт ягыңнан һөҗүм кылса котсыз гайбәт.

* * *

Искиткеч гүзәл, дисәк тә фани дөнья,
Ошбу тормыш кайгы-хәсрәтләрдән тора.
Аллаһ безгә хис, мәхәббәт бүләк иткән,
Шуннан дәрт алып кешеләр тормыш кора.

* * *

Күкләр җиргә бүләк иткән хатын-кызны
Могҗизалар алиһәсе итеп күрдем.
Табигатьнең үзе кебек гүзәл затка
Гомер буе сөеп вә сокланып йөрдем.

* * *

Күккә бактым, ямь-гүзәллектән шаккаттым,
Игелекле Җир-анага сәҗдә кылдым.
Хатын-кызлар таифәсе нинди гүзәл!
Андый гүзәлләргә һәрчак гашыйк булдым.

* * *

Кояш, айның йөзен кайчак болыт каплый,
Якты нурлар җиргә багар урын тапмый.
Хатын-кызны кайчак болыт капласа да,
Ай-кояштай йөзләренең нурын саклый.

* * *

Әгәр булсаң сөеклесе хәләл ярның?
Иң бәхетле кешесе син бу дөньяның.
Яхшымы ул, начармы – ул никахлы,
Кадерен бел яныңда яшәгән барның.

* * *

"Язмыштан узмыш юк". Ышан дөреслеккә,
Лаеклап бирелгән ул синең үзеңә.
Язмыш юлын кайчак урап үттең исә,
Килеп төшәсең янә иске эзеңә.

* * *

Гомер буе баш күтәрми мин казгандым,
Ач-ялангач, кайчак мәхәббәтсез калдым.
Күпме генә тырышсам да, тырмашсам да,
Язмышымда язылганын гына алдым.

* * *

Кайгы-хәсрәт, авырлыклар күп күрсәм дә,
Язмышымнан бик канәгать булып йөрдем.
Җәннәт кеби ошбу гүзәл дөньялыкта
Могҗизага, тылсымга тиң хәят күрдем.

* * *

Кеше гомере хата-ялгышлардан тора,
Елганы да уңга-сулга агым бора.
Бер кат тукгел, мең кат туып яшәсәң дә,
Шул ук хата-ялгышлыклар саклап тора.

* * *

Кеше җаны кук-гарешкә аша, диләр,
Кайбер җаннар җиргә кабат кайта, диләр.
Тик кайтмас ул инде синең сын-гәүдәңә,
Җиргә сеңеп юкка чыга бит гәүдәләр.

* * *

Аллаһ әйткән: "Сезгә мәңгелек җан өрдем,
Җир йөзендә яшәр өчен ризык бирдем.
Бирдем зиһен, бирдем сихри сөю хисе,
Адәмемне акыллы зат итеп курдем".

* * *

Бар тереклек җир-туфрактан яшәү ала,
Кем гөлчәчәк, кем агач булып ярала.
Яктылыкмы, кылгәме кубрәк төшә –
Гәммәсе дә җир-туфракта ятып кала.

* * *

Коръәнеңдә каһәремнән курык, дисең,
Куркаклыкта хөрмәт юклыгын белмисең.
Куркаклар бит икейөзле монафикълар,
Бу шиләрне үзең дә бит Син сөймисең.

* * *

Хак Тәгалә җан өргән без бәндәләрен
Дүрт төрле хаклык-тереклектә яшәтә.
Куркәм холык, әдәп-әхлак һәм мәхәббәт
Акыл безне хайваннардан өстен итә.

* * *

Иң бәхетле адәмдер – бу җиргә килгән,
Ай, Кояшлы һәм Йолдызлы Күкне күргән!
Мәңгелекнең мизгелендә кеше булып,
Җир йөзенең бер миһманы булып йөргән.

* * *

Дүрт хатынга өйләнгән бер мөселман ир
Җитмеш хур кызын кочмакка бик кызыга.
Җитмеше дә алмаш түгел татарымның
Итәгатьле, саф-инсафлы бер кызына.

* * *

Аяз төнне күзәтәм мин сихри күкне,
Энҗе-мәрҗән җемелдәшә назлап безне.
Гарше-әгъляләргә ашкан бу Галәмдә
Нинди язмыш, нинди көчләр йөртә безне?

* * *

Көчле белән мәйданга чыгып көрәшмә,
Байлык белән сөлге тотып бил алышма.
Син җиңсәң дә җиңелде диярлар казыйлар,
Казыйлары да бит аның бай абзыйлар.

* * *

Бу дөньяда тормыш итүләре авыр,
Яшим дисәң, булу кирәк бик тә сабыр.
Хак-хакыйкать дигән асыл җуелса да,
Тик сабырлар яшәү көчен җанда табыр.

* * *

Җирләр, күкләр... Гәр тараф сергә уралган,
Бу дөньяны вак микроблар чолгап алган.
Кеше гыйльме, аң-акылы белми әле,
Мәңге яшәү серен алар каян алган?

* * *

Күк йөзенә карыймын да хәйран калам,
Йолдызларның җем-җеменә, әй, сокланам.
Әйе, кешем, нурлар чәчеп син дә балкы,
Тылсымлы һәм бик тә серле йолдыз сыман.

* * *

Дәрьяларны чык-тамчылар тәшкил итә,
Халыкларны зат-кешеләр барлык итә.
Туган телем, моңлы көем, асыл динем
Милләтемне гасырдан-гасырга илтә.

* * *

Безнең дөнья гүзәлләрнең дә гүзәле,
Монда яшәү – гүзәллекнең гүзәл мәле.
Кайгы-хәсрәт, борчу-мәшәкатьләре дә
Гүзәллекнең үзенчә бер төре, яме!

* * *

Бу дөньяга кеше булып килү – бәхет,
Күрү, тою, ишетүләр – чын сәгадәт.
Телебез бар, моңыбыз бар, динебез бар,
Халкыбызны бизи күркәм гореф-гадәт.

* * *

Кешеләрнең бәхет-шатлыкларын алма,
Кайгы-хәсрәт, җәбер-золымнар да салма.
Гүяркемнең дә гомеркәе тик бердәнбер,
Канкоючы явыз булып истә кала.

* * *

Җүләр белән тапма да син, бүлешмә дә,
Изге эш-гамәл кылырга килешмә дә.
Мәсхәрәгә калырсың ил-җир йөзендә,
Җүләр дигән язма булыр белешмәңдә.

* * *

Ғерәү яшәү ләззәте таба эчидән,
Ғерәү ала тәм-ләззәтне тик эшеннән.
Эштән ләззәт алганы да, эчкәне дә
Ғара булыр ата-бабасы эзеннән.

* * *

Керләнгәнне чиста итеп юып була,
Ялгыш сүзне, уй-фикерне тыеп була.
Тик юып та, тыеп та буллмый намусны,
Ғер керләнсә, ул мәңгегә шулай кала.

* * *

Ғу дөньяга гариза биреп киллиләр,
Язмышында ни язганын да беллиләр.
Тормышларын үз кулына алганнары
Язмыш артыннан ияреп тә йөрмиләр.

* * *

Мин бәхетсез диеп, һәрчак шыңшып йөрмә,
Әнә кояш иртә таңнан үз эшендә.
Аның кебек көләч йөзле, нурлы булсаң,
Ғәхетең балкып торачак һәр эшеңдә.

* * *

Җитмеш бишкә кадәр яшәү күп шикелле,
Тик борчулы уйлар тырный күңелемне.
Кайгырттымы милләтемне, ил-җиремне?
Әллә бушка уздырдыммы гомеремне?

* * *

Миннән соң да бу дөньяга язлар килер,
Назлы гөлләр кояшка таба үрелер.
Тик мин буллмам, гөл-чәчәкләргә үрелләм,
Тик бер тапкыр чәчәк ата безнең гомер.

* * *

Китәргә дип килсә дә дөньяга кеше,
Изге эш-гамәлләр кыла затлы ише.
Мәңге яшәр һичнәрсә дә юк дисәк тә,
Ләкин бар ул. Ул – Аллаһның акыл эше!

* * *

Акыл бит ул бирелмәгән һәркемгә дә,
Чәчәк атарга өлгерми кай гөлләр дә.
Акыл, зиһен, зирәклегең булганда да
Чәчәк атар мөмкинлек юк кай илләрдә.

* * *

Гыч заяга үткәрмә син гомереңне,
Бел, оныклар дәвамында килереңне!
Игелекле хәзинәләр мәңгелектер,
Изге җир-туфракта калдыр үрчемеңне.

* * *

Берәү әйтер: "Үгет-нәсыйхәт сөйләмә,
Төйнәлгәнне икенче тапкыр төйнәмә.
Коръән дә бит үгет-нәсыйхәт вәгазьли,
Вәгазьләрнең асылында хак өндәмә.

* * *

Көфер сүзләр әйткән кеше имансыздыр,
Андыйларның калеб-күңеле буш-такыр.
Юкса мәшһүр акыл ияләре язган
Әсәрләрнең нәсыйхәтсезләре юктыр.

* * *

Сәрхүш кеше – күз көеге, ил череге,
Сәрхүшләрнең эчү булыр җан кирәге.
Шул сәрхүшлек баткагында гаип булды
Зур әдипләр – әрни шуңа ил йөрәге.

* * *

Офыкларга кояш алтын билбау атты,
Көмеш нурлар җирдә яңа көн уятты.
Аллаһының илаһи рәхмәте белән
Мәрткә киткән тереклек яшәүгә кайтты.

* * *

Бер иш затлар үз-үзләренә кул сала,
Мондый боерык-фәрманны ул кемнән ала?
Дөнья белән алыш-биреш өзүчеләр
Нәтиҗәсе нәсел – нәсәбендә кала.

* * *

Әй, кешем! Син язмышыңнан алда чапма,
Сабырыңны түземең бетсә дә сакла.
Бу дөньяның мизгелен дә һич югалтма,
Гомереңне шайтан коткысына сатма.

* * *

Азгынлыкны, фәхешлекне кәсеп итеп
Яши берәү сәрхүшлектә әүмәкләшеп.
Милли төскә әйләнгән бу гадәтләрен
Балалары арттыралар күмәкләшеп.

* * *

Бу дөньяда фанилык тауларын кичтем,
Гомер буе куенымда аш йөреттем.
Туган телне саклап калган буыннарга
Милли-рух байлыгымны ядкәр иттем.

* * *

Һич акланмыйм, булды миндә хаталар да,
Хатасыз юк һичберәү дә бу дөньяда.
Бу тормышның изге кагыйдәсе шулдыр:
Кеше башын, кеше хакын ашамауда.

* * *

Ил-җирләрне яулаган гаярь Искәндәр,
Ғазраилдән ала беркөн шомлы хәбәр:
Бинһая байлыкларга ия хәким
Тик кәфендә уралып кабергә иңәр.

* * *

Ғаләмнәрнең иң яманы – ул хаинлык,
Хаинлыкта безнең бүгенге кыенлык.
Дәүләтләрен, ил-җирләрен җуйган кебек,
Үзен-үзе җуеп бара безнең халык.

* * *

Көне-төне телевизор экранында
Сугыш, атыш, үтереш кебек тамаша.
Ярты халык илне талый, илне сата,
Ә яртысы шуларны эзләп маташа.

* * *

Бетте әхлак, бетте әдәп, гореф-гадәт,
Илне басты фахишә, сәрхүш бергәләп.
Олигарх әфәнделәр мал бүлешә,
Фәкыйрьлеген өстери ярлы мүкәләп.

* * *

Кая басма – һәр җирдә адәм сөяге,
Ғәр тарафта – яман кешеләр өрәге.
Кайсы кеше, кайсы өрәк – аермассың,
Кемнәргәдер аларның да бар кирәге.

* * *

Җиргә килеп, адәм заты зур юл үтте,
Үзгәреп ул, бу заманга килеп җитте.
Ғәр заманның начар гадәтләрен җыеп,
Ул үзе дә яманга әйләнеп бетте.

* * *

Әлифне таяк дип белмәгән адәмнәр,
Чалма киеп, хәзрәтләргә әйләнделәр.
Тәмугъ белән тәкъва затларны куркытып,
Хәрам ашап, хәрам эчеп кинәнделәр.

* * *

Бериш хәзрәт теле белән вәгазь сөйли,
Азгын нәфес сылу тәнле кызлар эзли.
Күзе белән вәсвәсә дә зина кыла,
Ул намазын инде тәһарәтсез кыла.

* * *

Ике чабата – бер кием, дисәләр дә,
Аерма бар чабаталы кемсәләрдә.
Берсенең эш-гамәлендә котсыз мәкер,
Икенченең – хак иманлы изге сүздер.

* * *

Берәү белән хаталанып борчу алдым,
Унҗиде ел мин хуҗабикәсез калдым.
Сукбайлыкта йөреп безне газаплады,
Дөньялыкта яшәвендә җәза алды.

* * *

Язмыш белән канун талкый кешеләрне,
Кол хәлендә тота гавам ишеләрне.
Бу дөньяда адәм заты бер уенчык,
Тегесендә тәмуг утына – утынчык.

* * *

Заманында Кашпировский һәм Чумак,
Йөргән иде бөтен Рәсәй халкын алдап.
"Изге урын буш тормый", – дип әйтә халык,
Гәм бүген дә халкын икәү парлап.

* * *

Бер нәфесең тыялмыйча, туялмыйча,
Шартлар хәлгә җитеп бары җиләр ашый.
Тәнең, каның үз кирәген генә ала,
Кирәксезгә әйләнгәнен чүпкә ташлый.

* * *

Бу дөньяга мин кунакка килдем димә,
Тормыш җебен мәңгелеккә диеп төйнә.
Нинди ният белән җирдә тормыш корсаң,
Тегесендә мәгълүм булыр бәйнә-бәйнә.

* * *

Алдап-йолдап, талап ул хәрам мал җыйды,
Тәкәбберлек белән җиргә күсәк орды.
Тик кабере өстендә берни дә үсми,
Хәтта шайтан таягына кадәр корды.

* * *

Акыллы сүз кешеләргә зиһен бирер,
Барлык эш-гамәлләрендә алдан йөрер.
Изге сүзләр, изге уйлар фикер булып,
Мәңгелеккә – Гареш күңеленә керер.

* * *

Сүзнең яхшы, яманын да бер тел әйтә,
Сүз кешенең бәгыренә барып җитә.
Тел берәүгә җир-күкләрне бүләк итә,
Ә берәүне тел вакытсыз гүргә кертә.

* * *

Бер карасаң, нәфес коточкыч нәрсә күк,
Комсызлыгы, кансызлыгы чиктән ашкан.
Ләкин нәфес җан асрау өчен тырыша,
Мәңгелек җан ике дөньяга тоташкан.

* * *

Хак Тәгалә Адәменә акыл биреп,
"Җир йөзендә кунак булып яшә", – дигән.
Җирнең астын өскә китерә шул адәм,
Бу кадәрле тиле-тинтәк каян килгән?

* * *

Бу дөньяга миллиардлаган кеше килә,
Төмугы да, оҗмахы да бар тормышта.
Ә яшәүнең иң-иң асыл мәгънәсе шул:
Изге гамәл, игелекле эш кылмышта.

* * *

Бу дөньяга миллиардлаган кеше килә,
Берәүләре дөнья малын кочып ала.
Исә җилләр, кичә чүлләр, кибә күлләр...
Изге гамәл, хикмәти сүз торып кала!

* * *

Халык әйтә: "Тәвәккәллек, – дип, – таш ярыр,
Булдыклылар кыя-ташка кадак кагар".
Тәвәккәлләр сират күперләрен үтеп,
Җәһәннәмнән чыгар юлны эзләп табар.

* * *

Барлык төсне кара төскә буяп була,
Тик кара төс башка төстән калкып чыга.
Кул-аяксыз, бер коралсыз гап-гади су
Тау-кыялар тишеп чишмә булып ага.

* * *

Аттан ала да, кола да туа, диләр,
Гайрәтле дә, җебегән дә була ирләр.
Ала-кола ил белән идарә итсә,
Яклаучысыз, саклаучысыз кала җирләр.

* * *

Ялагайның төпле үз фикере буллмый,
Тегеңә дә, моңа да ул койрык болгый.
Шуңа күрә аңарга: "монафикъ" диләр,
Монафикъны эт урнына тота илләр.

* * *

Ялтыравык нәрсә күрсәк шаккатабыз,
Әсәрләнеп мәхәббәт угы атабыз.
Ялтыраган һәрнәрсә дә алтын түгел,
Пыяладай челпәрәмә килә күңел!

* * *

Безнең тормыш гөнаһ-хаталардан тора,
Ялгышлыклар аша кеше тормыш кора.
Ә син: "Тәүбә вә әстүбү иләйһи" дип,
Аллаһыдан гафу-ярлыкауны сора.

* * *

Тимер ишек артларына халык посты,
Симергәннең арт шәрифләре бөреште.
Ачлы-туклы халык сугыш елында да
Бар булганы белән үзара бүлеште.

* * *

Нәфесенә хуҗа түгел – комсыз кеше,
Хәрам җыяр курыкмыйча Аллаһыдан.
Әсир булып сихри шайтан коткысына,
Җиңелә ул явызлыгы тарафыннан.

* * *

Иман нуры – Хак Тәгалә нуры булып,
Мөэминнәргә җаны белән бергә иңә.
Коръән нурлы, милли гадәтле татарны –
Дошман түгел, хәтта чёрт та аллмас җиңә!

* * *

Утны-суны, кояшны, сулар һаваны
Алыштыра аллый һични табигатьтә.
Татарлыкта – тел дә, дин дә, милли рух та...
Безнең җанда, безнең канда, хакыйкатьтә!

* * *

Көнбатышның дин кояшы батып бара,
Кәферләрнең күк йөзендә болыт кара.
Борынгыда мөселман булган кавемнәр
Аллаһының хак диненә кайтып бара.

* * *

Мөселманлык – Аллаһның бирелгән тану,
Итәгатьле, гыйбадәтле Аңа булу.
Ялгышлыкта йөз таяк җәза урынына,
Йөз сабак салам учмасы белән сугу.

* * *

"Ишәк изге Коръән күтәреп йөрүдән,
Ул динче дә, хак мөселман да булмастыр".
Коръән тотып, ашау өчен ашка йөрү, –
Безнең хәзрәт-абыстайларга да хастыр.

* * *

Бу дөньяда бөтен нәрсәләр дә пардыр,
Нәфеснең дә бар изгесе, бар яманы.
Изге нәфес матди, рухи байлык барлый,
Яман нәфес – байлыкны талап алганы.

* * *

Җирнең эче куышланып, бушап калса,
Тартым көче, егәре аның югалыр.
Җил очыртып йөрткән ач кандала кебек,
Ул да Галәм бушлыкларына юл алыр.

* * *

Үчак уты үз алдын гына яктырта,
Кызуы да казан өчен генә җитә.
Кояш якты нурлар бөркеп җылытса да,
Тик аналар җылысы тамырга үтә.

* * *

Безнең тормыш шундый хәлгә килеп җитте:
Чын табигый рәвеш бетте, хәләл бетте.
Кешеләрдән оят китте, намус китте,
Һәфеслене акча җене әсир итте.

* * *

Кешеләрнең уннан тугызы ахмактыр,
Яшәүләре – су уңаеннан акмактыр.
Адәмнәргә кирәк кадәр белем биргән
Хикмәти серләр иясе – Аллаһ хактыр.

* * *

Эткә әйтсәң, әйтмәсәң дә – ул бичара,
Җәй-челләдә телен аска салындыра.
Аллаһ сыйфатлары булган кешене дә
Вәсвәсәле тормыш үзе азындыра.

* * *

Зур бәхеттер, дәрәҗәдер мөселманга
Рәсүл Мөхәммәтнең өммәтендә булу.
Хак динебез – ислам белән Аллаһыга
Итәгатьле булып, изге гамәл кылу.

* * *

Гич кенә дә ышанасы килми әле,
Инде җитмеш биш яшьлек карт булуыма.
Аллаһыга шөкер итәм, рәхмәт әйтәм,
Ил-җиремә һаман хезмәт кылуыма.

* * *

Заманында бер мең татар кырык меңне
Урак урган сыман итеп кырып салды.
Шул каһарман татарларның варислары
Бүген куркак, мәми авыз булып калды.

* * *

Аллаһ кушып, берәү "алтын балык" тотса,
Үзен "алтын чалма" кигән итеп тота.
Башкаларны санга сукмаган ахмакны
Тәкәбберлек, мин-минлеге кабып йота.

* * *

Алып батыр кебек куәтле булсаң да,
Ил-җирләрне кисәкләп ерта алмассың.
Күккә ашкан тауның башына менсәң дә,
Асылыңда тик үзең булып каласың.

* * *

Берәү әйтә: "Балта биреп, шөшле алдым,
Күршемдәге бер татарны алдаладым".
Чит милләттә улың – кияү, кызың – килен,
Балта, шөшлесез дә калма, әй татарым?!

* * *

Икейөзле булган мөэмин-мөселманнар
Кәферләргә дуслык кыла, кода була.
Татарның да тырә дигән зыялысы
Чит-ятлардан тәре таккан хатын ала.

* * *

Тотынма син көчең җитмәстәй нәрсәгә,
Буең җитмәгән нәрсәгә дә үрелмә.
Аллаһ сине бер нәрсәгә дә көчләми,
Фарыз булган гамәлдән тик йөз чөермә.

* * *

Хак Тәгалә кешелеккә җәза итеп,
Гыйбрәт өчен яңа чирләр биреп тора.
Азганнарны, туры юлдан язганнарны
Яман чирләр, СПИД дигән афәт кыра.

* * *

Аллаһының иксез-чиксез хозурында
Мәңгелек дин – ислам дине генә хактыр.
Пот, тәрегә табынганнар ник саташа –
Чебен дулап тәрәз ватканы да юктыр.

* * *

Гәр изге сүз, һәр игелекле бәрәкәт
Аллаһының тарафыннан иңгән безгә.
Иблис-шайтан явызлыкны яхшы итеп,
Азгынлыкны бизәп күрсәтәдер күзгә.

* * *

Тиңсез асыл сыйфатында һәм затында
Бердәнбер Аллаһ чиксез Галәмнәрдә.
Аңа мәңге тугрылыклы була белик,
Галәмдәге кояш кебек гамәлләрдә.

* * *

Йә аяныч, йә көлке хәлендә булып,
Үткән заман һәр тормышта кабатлана.
Гәр буынның тәүге эше ата-баба
Тырмасына басып караудан башлана.

* * *

Буыннардан күчеп килә акыл көче,
Белем белән тулылана бер өлеше.
Затның мәшһүр, данлы-даһи булуында –
Каршылыклар белән тулы заман эше.

* * *

Таш өстеннән йөгереп аккан инешнең
Читләрендә ак күбекләр бөтерелә.
Ут өстендә торган сөт тә ташып чыга,
Мәйданнарда халык "сөте" күтәрелә...

* * *

Лә иләәһә иллəл-лаһу дигән сүзнең
Тамырлары җир белән күк үзәгендә.
Итәгатьле, гыйбадәтле мөселманның
Иман нуры балкып тора йөзләрендә.

* * *

Мәхшәр көнне каберләрдән кубарылып,
Адәм заты хисап тотар илсез калып.
Ахирәттә без нинди хәлдә булырбыз?
Нинди рәвеш, нинди төс-кыяфәт алып?

* * *

Миллəтемнең күңел капусы ачылыр,
Офыкларга нурлар бөркеп таңы атар.
Әй, татарым! Ата-бабаң юлын барла!
Халкыбызга дәүләт тотар эшләр майтар!

* * *

Бөек державачылык шовинизмы
Милли хурлык, милли оят, милли хәсрәт.
Халкыбызны аздыручы иблисләрнең
Булганыннан буллаулары хәерлерәк.

* * *

Чал тарихның котырынган давыллары
Миллəтләрне тамырыннан йолкып ата.
Татарның да яртылаш тамыры җирдә –
Яртылашы тышта калып, корып ята.

* * *

Коръән әйтә: "Диннән киткән мөртәтләргә,
Фәхешлектә йөргәннәргә җәза тиеш".
Ләкин алар – бу дөньяның арбасында,
Кулларында хәрам маллар, алтын-көмеш.

* * *

Фәрештәләр яшәсәләр җир йөзендә,
Тойгы, хис тә, мәхәббәт тә буллмас иде.
Фәрештәләр ничек црчи – без белмибез,
Тик балалар мәхәббәттән тумас иде.

* * *

Яши торгач, ачысын да, төчесен дә...
Кешене дә язмыш колы итеп кцрдем.
Гомеремне ялгыш-хаталарга төрдем,
Гафу итмәс нәрсәләрнең югын белдем.

* * *

Ләцхелмәхфцздә язылган тәкъдиреңне
Хак Тәгалә Кадер кичендә цзгәртер.
Мең айдан да хәерле булган бу кичне
Хак мөселман ураза тоткан хәлендә,
Намаз укып, догалар кылып цткәрер.

* * *

Хак Тәгалә кешене кызыл балчыктан
Бар итә дә... Аңа мәңгелек җан өрә.
Дөньялыкта изге гамәлләр кылсынга
Гәр кешегә җан белән рәсцл дә керә.

* * *

Иман нуры, Коръән нуры – Аллаһ нуры,
Мәңге балкып торыр алар җир-кцкләрдә.
Килер бер көн: дөнья малы җилгә очар,
Тик изгелек калыр рухи кцңелләрдә.

* * *

Коръән әйтә: "Хак Тәгалә кешеләрне
Ислам дине өчен генә барлык кылды.
Монафикълар, мөшрикләр һәм кяферләр...
Барысы да әүвәл чакта мөэмин булды".

* * *

Аллаһының кодрәтенә тиңнәр юктыр,
Үзе хактыр, көче хактыр, эше хактыр.
Диңгезләрнең суларын кушып язсаң да
Изге сүзе мәңге бетмәс, Ул – Илаһтыр.

* * *

Коръән белән гамәл кылган мөэминнәргә,
Аллаһының нигъмәтләре булыр бүләк.
Җәннәтләргә керү өчен итәгатьле,
Гыйбадәтле күңел кылган гамәл кирәк.

* * *

Хак Тәгалә адәмнәрне төрле диндә,
Төрле төстә итте җиргә, күккә карап.
Ислам динле һәм иманлы мөселманны
Үз рәхәте, шәфкатенә алды урап.

* * *

Әл-Коръәннең "Төтен" сүрәсендә Аллаһ:
"Җир-күкләргә утлы төтен иңәр", – дия.
Тәкәбберлек чире йоккан кешелеккә
Хак Тәгалә һәлакәтле сабак бирә.

* * *

Адәм затын акыл иясе дисәк тә,
Гыйлем аңа чеметемләп ирешелгән.
Тәкәббер һәм денсез-динсез залимнәрдән
Җир-күкләрнең сер сандыгы яшерелгән.

* * *

Хаин татар! Син ханлыкка уктан аттың,
Ата-бабаң тамырына балта чаптың.
Идел-йортны, динеңне, телеңне саттың,
Дошманнарның куенына кереп яттың.

* * *

Күңелендә шайтан йөрткән җаһил бәндә,
Азгынлыкта йөрер хәрам гамәл кылып.
Явызлыгы үз башына җитәр аның,
Эт көнендә иңрәп ятар ялгыз калып.

* * *

Яшәр өчен кирәк булган һәр нәрсәне,
Җир-анабыз ала илаһи күкләрдән.
Хак мөселман ике дөнья хикмәтләрен,
Акыл көчен аладыр изге Коръәннән.

* * *

Һәр милләтнең үз юлы бар, кыйбласы бар,
Гореф-гадәт, йолалары: бар да мулдан.
Тик шәригать, ислам дине кыйбласы хак,
Мөселманнар! Адашмагыз туры юлдан!

* * *

Бер кешенең җирдә яшәү дәверендә,
Миллиардлаган кеше килә бу дөньяга.
Тик иманлы, игелекле гамәл кылган,
Күренмәгәнне күрүче зат азая.

* * *

Галәмнәрдә сызылып йолдыз атыла,
Кисәкләре башка җисемнәргә төшә.
Бер нәрсә дә юктан бар, бардан юк буллмый,
Бер халәттән икенче халәткә күчә.

* * *

Маңгай күзе түгел, күңел күзе күрә,
Күңел аша үтсә генә акыл керә.
Никадәр зур, бик акыллы булса да баш,
Әмерне бит серле-күзле күңел бирә.

* * *

Берәү әйтә: "Дини әкиятләр тыңлаган
Кешелекнең бала чагы инде үтте".
Ләкин акыл, гыйлем һәм тәрбия биреп,
Шул берәүне иланы дин кеше итте.

* * *

Аллаһыга ышанмаган бәндәләргә
Барлыгын һәм берлеген Үл исбат итте.
Үтә нәни нанокисәкчекләренең
Кодрәтеннән кешелекнең исе китте.

* * *

Төрки кавемнәрне бергә берләштереп,
Әверелдек без татар милләте булып.
Татар телле, ислам динле дәүләт булып,
Яшәрбез без хәр ил-җирдә мәңге калып.

* * *

Кешелекнең явызлыгын әйтеп кенә,
Язып кына бетерә торган түгелдер.
Дөньяларның яшәешен юк итүдә
Үл Җаһил дә, Газраил дә... Үл – әҗәлдер.

* * *

Ата-ана баласына рәвеш бирә,
Кеше булыр шул рәвешкә акыл керә.
Иманына тугры булган хак мөселман,
Аллаһының рәхмәтендә көнен күрә.

* * *

Азчылыкны күпчелеккә буйсындырып,
Дәһри дәүләт хокуклардан мәхрүм итте.
Аллаһының хак юлыннан адаштырып,
Миллионнарны җәһәннәмгә алып китте.

* * *

Бу дөньяда һәркемнең бар туган җире,
Шул туфракта һәр халыкның үз тормышы.
Үз бәхетен, мәхәббәтен табар һәркем,
Балкып торса күңеленең ай-кояшы.

* * *

Кеше дигән җан иясе акыллымы?
Бу дөньяның яшәешендә калырмы?
Әллә инде дәһшәтле кораллар ясап,
Үз-үзенә җәллад булып кул салырмы?

* * *

Кеше дигән акыллы зат ышанадыр
Им-томнарга, хорафатка, пот-сурәткә.
Аллаһыга ширек кылып йөргән бәндә
Үзен-үзе тәкъдир итә һәлакәткә.

* * *

Кемнәр килеп, кемнәр китми бу дөньядан,
Яхшысын да, яманын да җыя-җыя.
Кеше талап җыелган мал варислары,
Мирас бүлә нәсел канын коя-коя.

* * *

Җитмештән соң кеше дигән җан иясе,
Әҗәл көтә, торып картлык җирлегендә.
Гыйбадәтле, итәгатьле изге җаннар
Мәңге яшәр ике дөнья берлегендә.

* * *

Ил-дәүләтләр тоткан мәшһүр халык идең,
Кайда синең горурлыгың, милли йөзең?
Ата-баба телен онытқан оланнар,
Маңкортлашты ятның ялчысы булганнар.

* * *

"Булдырабыз!" дип мактандык. Булдырмадык.
Булдырылган азатлыктан колак кактык.
Халыкара хокук иле булган идек –
Хокуксызлык заманына кире кайттык.

* * *

Иртә-кичен Аллаһыга ул табынды,
"Мал-мөлкәт бир, байлык бир", – дип ялынды.
Баеп китте. Аллаһның кирәге бетте,
Үрделәр. Байлыгы башына җитте.

* * *

"Хиз-бут тахрир, һәм фанатик баһһабчылар
Кирәк түгел безгә", – дия чаллмалы баш.
Дин акчасын урлап йорт-коттеджлар салды,
Динне кәсеп итеп ашый калҗалы аш.

* * *

Капка артларына посып, шыңшый-шыңшый,
Койрыгы бот арасындагылар өрә.
Өтек адәм, нәфесле тәкәббер бәндә,
Аллаһыга теш ыржайта, тел тидерә.

* * *

Бик борынгы заманнардан халыкара,
Аллаһ бармы, юкмы? дигән бәхәс бара.
Бар дигән дә, юк дигән дә – бу тормышта
Гәр мизгелдә Аллаһка мохтаҗ бичара.

* * *

Әверелеп яшәешнең корбанына,
Ғәркем гомер ахырына кабалана.
Ата-баба хатасыннан гыйбрәтсезләр –
Тырма тешенә басканнан җәфалана.

* * *

Дөнья һәрчак үзгәрештә, хәрәкәттә,
Бернәрсә дә була аллый бер рәвештә,
Аллашынып тора тормыш табигатьтә,
Яшәеш тә дәвам итә тик көрәштә.

* * *

Космонавтлар галәмнәрдә очып йөри,
Бу гамәлдән ни буласын һичкем белми.
Күкнең Аллаһ тыйган катламына керү –
Ғәлакәтле буллас микән? Әй, адәми.

* * *

Ғәлакәткә дучар булган инсаннарны,
Икеләтә кызганамын – татар булса.
Кызганулы хисләрем кире кайтадыр,
Хәмер эчеп үз башына җиткән булса.

* * *

Кем иленә, кем диненә, кем иренә...
Хатынына берәүләр хыянәт итә.
Сәбәпләрнең иң зуры да – сәбәп түгел!
Хыянәтче һәр азгынны җәза көтә.

* * *

Изге зат та, хәшәрәт тә җир куйнында,
Исән-имин йөргәннәрнең ни уенда?
Киткәннәрнең кире кайтканнары юкка,
Җан иясе яшәештә үз җаенда.

* * *

Табигатытә бернәрсә дә котсыз тугел,
Мәхәббәтле бу дөньяның һәрьягы да.
Чәчәк таҗын сырып алган умартага
Бәрәкәтле хәтта шайтан таягы да.

* * *

"Бер кыр казы язны китерми шул, диләр,
Бер тарыдан ботка да пешереп буллмый.
Бер хатын-кыз тутыра алган йорт эчен
Кырык ир дә тутырып бетерә аллмый".

* * *

"Татарга дүрт класс белем җитә", – диеп,
Берәү, гүя таш гасырлан аваз салды.
Шуны гына көткән козгын-шовинистлар,
Халкыбызның тел нигъмәтен йолкын алды.

* * *

Һәр мөселман биш вакыт намазын укыр,
Калебенә Коръән-Кәрим нурын алыр.
Җәннәтенә керер изге бәндәләре
Аллаһының рәхмәтендә булып калыр.

* * *

Монафикълар Аллаһ динен кәсеп итте,
Оят-намус, әдәп-әхлаклы зат бетте.
Денсезлектә, тәкәбберлек, мал җыюда...
Фиргавеннәрне дә алар узып китте.

* * *

Караңгыда каралар да, аклар да юк,
Тик ут сыман янып торган күзләр генә.
Ахирәттә ярлылар да, байлар да юк,
Тик гөнаһлы һәм гөнаһсыз йөзләр генә.

* * *

Коръән әйтә: "Ләә иләәһә илләллаһ, – ди, –
Ғәрәкәтле җимеш биргән яхшы агач".
Шул агачка денсез халык ташлар ата,
Ләә иләәһә илләллаһлары буллмагач.

* * *

Адәм заты хәрам ашап, хәмер эчсә,
Көнкүреше хайван рәвешенә күчә.
Ата-ана, улы-кызы... Кем булса да,
Дуңгыз кебек тагаракгган ашый-эчә.

* * *

"Изге хатын кыз табар", – дип, әйтә халык,
Ғорын заманнар мирасы – бу затлылык.
Ләкин хәзер изге хатыннарга кытлык,
Кызларның да җан-тәннәре – товар сатлык.

* * *

Ғашкаларның милли гадәтен кабатлый
Үз башында үй-фикере буллмаганнар.
Юл буенда аунап яткан савытлар да
Чүп-чар салу өчен диеп куелганнар.

* * *

Әүвәлендә эшче булган бериш артист,
Зарланадыр: артист булу авыр, диеп.
Тик берсе дә эшче булып кире китми,
Эте-бете йөри үйнап, җырлап-биеп.

* * *

Җир кешесе – фәрештә дә, җен дә түгел,
Гөнаһ кылып яшәүчедер бу тормышта.
Изгеләрдән-изге булган әүлия дә –
Гомер буе нәфесенә кол буллмышта.

* * *

Берәүләрнең калебенең миллилеге –
Баласының исемендә чагыладыр.
Чит-ятларның михрабында табынудан
Татарымның тамырлары чабыладыр.

* * *

Ике икең дүрт була, кебек сүзләрне
Әйткән чакларым булган өчен җенәм.
Киләчәкнең акыл, хикмәт иясеннән
Башым иеп, гафу итүен үтенәм.

* * *


Сүзләренең хаклыгына раслык итеп:
"Иманым камил" диюләр ипле хәйлә.
Адәмнәрнең иманының ниндилеген,
Бер илаһи Хак Тәгалә генә белә.

* * *

Гадәтенчә, келәттән ашлык урлады,
Өнен дә казыды итеп, катлы-катлы.
Тик орлыклар агуланган булган икән,
Бичаракай игелеген күрми калды.

* * *

Озын-озак гомер кичеп аңладым, шәт –
Хәят яме – акыл белән яшәештә.
Рух-күңеле ай-кояшлы булганнар тик
Чын бәхеткә ия затлар бу тормышта.


بسم الله الرحمن الرحيم
قل هو الله أحد
الله الصمد
لم يلد ولم يولد
ولم يكن له كفوا أحد

Автобиографик уйланулар

Дүрт яшендә башыма ат типкән,
Баш миемне хәйран селкеткән.
Болыт каплаган кояштай итеп,
Томалаган аны бер читтән.

Күк капусы ачылгандай булып,
Кайчак шул чит китә ачылып.
Өтәләнеп кәгазь, каләм алам,
Үй-фикерем язам ашыгып.

Гомер буе чикле баш миемнең
Ачылышын көтеп яшәдем..
Маңгай күзем белән дөнья күрдем,
Күңел күзем белән эшләдем.

Кечкенәдән саулык өмет иттем,
Ачылуын көттем капусның.
Ат тоягы аны ваткан булган,
Аңы киткән акыл затының.

Кай нәрсәне һич тә аңламадым,
Тырышсам да ун ел мәктәптә.
Белемне дә сайлап алганмын мин
Башым кабул иткән тәртиптә.

Алу, кушу, бүлү, тапкырлаулар...
Буйсынмады минем акылга.
Укытучы апа, кызганыптыр,
Куяр иде "3"ле журналга.

Хәрефләрдән иртә сүз чыгардым,
Әлиф – "таяк" диеп аңладым.

Белгәннәрем бик тиз җилгә очты,
Күңелемә ятлый алмадым.

Коелдылар алар кайчак баштан
Җиз иләккә салган су кебек.
Я лан калам. Башым учка алам,
Мин томанда очам шар кебек.

Гәркемнең дә, тәкъдиренә күрә,
Үз кануны бардыр тормышның.
Тугыз яшьтән дүрт ел көтү көттем,
Чыбыркысын сөйрәп язмышның.

"Чыбыркысы бик килешеп тора", –
Шулай дигән авыл кешесе.
Барыбыз да ишкә-куш булабыз,
Бәлкем, шулдыр язмыш дәресе?

"Дөрес сүзгә җавап юк", – ди халык,
Эшләп үттем тормыш мәктәбен.
Туганнарыма сыендым һәрчак,
Максат иттем Аллаһ мәзһәбен.

Тормышның да төрле чагы була –
"Кәҗәләнгән" чак та булгандыр.
Кирәкмәстән чыгырымнан чыгып,
Чыгымнау да булып алгандыр.

Әнә, ат та мине аңламаган,
Тәртәсеннән чыгып "җенләнгән".
Койрыгына чана тагуымны
Я ратмаган, тибеп җибәргән!..

Я тим бала – кимсетелү була,
Аны этеп-төртеп китәләр.

Гаепсездән – ул гаепле булыр,
Сәбәпсездән рисвай итәләр.

Чабатаның иске тишегеннән
Гаеп табар – гайбәт эзләүче.
Башкаена ат та типкән булса,
Ул, һичшиксез, гаепләнүче.

Шулай булды. Класс: "Ул түгел", – ди,
Саклап мине ялган бәладән.
Аның һаман үз туксаны-туксан,
Чикләвекне эзли юкәдән.

Бу дөньяда бер "үләксә", булсаң,
Бүре, аю килеп умырыр.
Этләр – йолкыр, төлке, шакал талар,
Ерткыч кошлар чукып утырыр.

Еллар үтте. Әлгерер чак җитте,
Акыл кирәк тормыш корырга.
Егерменче гасыр кешесенең
Әлгер замандашы булырга.

Кичке мәктәп, читтән торып уку –
Сугa кереп, коры чыгудыр.
Вуз бетереп, диплом алулар да –
Фәннәрне тик иснәп алудыр.

Кибәк чәчкән җирдә иген үсми,
Укымасаң – белем өстәлмәс.
Кешеләрне акыл заты иткән
Аң булмаса – тел дә сөйләнмәс.

Кибәк башлы башак кебек булып
Бушап калган башым орлыктан.

Ат типкәннән акыл, зиһен, хәтер
Җилгә очкан тояк ормыштан.

Күп вакытлар өн-җавапсыз калам,
Белсәм дә шәп әйтер сүземне.
Хаҗәт беткәч, башым эшләп китә,
Ачып куя капус-миемне.

Белем-гыйлем миңа "йогып" каллый
Очкын кебек сүнә, югала.
Кай уй-фикер җанга тынгы бирми,
Кайберенә мин тик-дивана.

Ни кылсам да, иман тора сакта,
Я нәшәмдә һәрчак фәрештә.
Ирештерә Аллаһ рәхмәтләрен,
Ул ярдәмче миңа һәр эштә.

Исәп-хисап фәнен белмәгәннәр
Була аллас иде җитәкче.
Өч мең халкы булган коллективны
Җитәкләдек, иттек җиңүне.

Гич кенә дә бу мактану түгел,
Масаю да түгел шау килеп.
Хезмәтеңне намусыңа төреп,
Башкару бу – хәләл көч түгеп.

Тиктомалдан күктән берни яумый,
Алма үзе төшми авызга.
Тәвәккәллек, зур тырышлык кына
Ирештерә ямьле язларга.

Гомер буе кеше өмет итә,
Өмет йөртә адәм баласын.

Игелекле, изге гамәл кылып,
Яшәүдән тик мәгънә табасың.

Гүяркемнең дә акыл-фигылендә
Язмыш-узмышлары сурәте.
Минем тормыш инфаркт, инсульт белән
Башкаларга булсын гыйбрәтле.

Кемгә нәрсә, күпме кирәклеген
Тик бер Аллаһ белә тәгаен.
Рәхмәт әйтеп, Аңа шөкер итәм,
Гыйбадәттә булып көн саен.

Аллаһыга чиксез рәхмәтлемен, –
Җир-күкләрнең бирде кадерен.
Хак Тәгалә эти-әниемә
Җәннәт итеп бирсен әҗерен.

Газиз халкым, гашыйк булдым сиңа, –
Җир-күкләрне кебек яратам.
Күңелемнең син кояшы, ае –
Алсу офыгыңда таң атам.

Башым иеп, сиңа рәхмәт әйтәм,
Син – хикмәтле Аллаһ бүләге.
Мәңге Аның рәхмәт-шәфкатеңдә
Яшә булып, дөнья терәге!

Берәүне дә хаксыз гаепләмә,
Сабыр гына, иплән гомер ит.
Тормыштагы барлык сынауларны
Аллаһ тәкъдире дип кабул ит!

Апрель, 2018 ел.



Коръән – Аллаһның китабы, – Дөньялыкның әсбабы.

Эчтәлек

I бүлек
Коръән безнең тормышта,
Коръән мәңге булмышта...

Галәмнәрнең бердәнбере 6
Аллаһ куша 7
Аллаһының илаһияте 8
Лә иләһә илләл-лаһ 9
Аллаһыга сыгыныйк 10
Аллаһ хикмәтләре 11
Юлы туры, юлы такыр 12
Бердәнбер 13
Аллаһка сыену 14
Коръән әйтә 15
Тик бер! 16
Үткәннәргә кайтып 17
Коръән әйтер 18
Коръәннән 19
Җавап 20
Килер бер көн 21
Гамәленә күрә әҗере 22
Коръән сүзе 23
Хаклык 24
Аркан юлы 25
Намаз вакыты 25
Адашу 26
Имансызлык 27
Дәһри адәм 28
Сукырлык турында 29
Фани дөнья, фани эш 30
Үлчәүләрең җитмәс, үлчәсәң 31
Җиргә, күккә карап 33
Шигъри вәгазь 36
Җеназадан соң 38
Дәвам итә тормыш 40

Яшәү катламнары 42
Иншаллаһ 44
Бердәнбер юл 45
Өч һәдия 46
Денсезлек 47
Ике язмыш, ике юл 48
Әйләнеш 49
Күк җәзасы 50
Кеше хакы – Аллаһ хакы, диеп 51
Җәннәтне белү 52
Замана корбаннары 53
Чарасызлык 54
Дөреслектә 54
Җир һәм күкләрнең тетрәнүе 55
Ялгышмагыз 56
Курыкмагыз! 58
Канун булсын 59
Бер нәсихәт 59
Җан 60
Гыйбрәтле гамәлләр 61
Мәңгелек көрәш 62
Адәм 63
Әхлак 65
Никах 66
Сур мөгезе әле 67
Тилмердем 68
Гамәленә күрә 68
Икмәк каргышы 69
Яңгырдан соң 70
Иншалла 71
Язмышлардан узмыш 72
Читкә язмасын 73
Аллаһ бүләге 74
Ике куен 74
Җиде күктә 75
Әни талган үлем йокысына 76

Аш ашадым, яшь яшәдем ... 77
Могҗизалы терелү ... 78
Тарихтан бер сәхифә ... 82
Пәйгамбәрне яд итү ... 83
Соңгы чик ... 84
Саранлык бәласе ... 86
Хисап бирәбез ... 87
Мәңгелек сорау ... 88
Нәфес турында ... 89
Хисләрем дисбесе ... 90
Онытмыйк! ... 91
Әйләнештә... ... 92
Яшәү мәгънәсе ... 93
Әҗәлгә бер сүз ... 93
Шәһри Болгар җирендә ... 95
Фарыз булсын! ... 101
И, мөкатдәс туган телем! ... 102
Аллаһ мәхәббәте ... 103
Аллаһү әкбәр ... 104
Мөнәҗәт ... 105

II бүлек
Кеше һәм хәят

Кешегә мәдхия ... 108
Кеше – сәнгать әсәре ... 111
Адәми зат – акыл иясе ... 112
Акылга мәдхия ... 113
Акыл кергән ... 114
Кем син? ... 116
Бер карасаң... ... 117
Аңла, Кеше! ... 119
Уй-фикер ... 120
Акыл белән яшәргә ... 121
Иң мөһиме ... 122
Ике юл ... 123
Гомер юлы ... 124

Бар да әйләнештә....125
Икмәк исе....125
Өмет итик....126
Үз юлы белән....127
Һәркемнең үз өлеше....128
Карыныннан ук....129
Җир ярасы....130
Бөек сер....131
Манзара....132
Баш иямен....133
Туганлык....134
Милли холык....135
Җавап....135
Бер киңәш....136
Юл башы, юл азагы....137
Өммәт....138
Дисәк тә....139
Җәза....140
Нәсихәт....141
Сиңа бер сүз....141
Хакыйкать....142
Ике көч....143
Аллаһ һәм Коръән....144
Тәүфыйк бирче....145
Парлы-парлы....145
Һәркемнең үз урыны....147
Дәлил....147
Нигә?....148
Беләсеңме?....148
Гөнаһлы уен....149
Бу дөньяның кеме юк....150
Көтә....152
Ахыры ничек бетәр?!....153
Тормыш....154
Заман фаҗигасе....155
Уенчык....156

Безнең хәят 156
Ахырзаман 157
Бердәнбер 158
Бер кебек 159
Кардәшкә эндәшү 160
Риваять 161
Чорнап ала язмыш 162
Каһәрле кавем 162
Могҗиза 163
Мөселманнар, берләшегез! 163
Елады, галәм, елады... 164
Көрәш 165
Бәхәс 166
Чиге бармы? 168
Дәшсен өмет! 169
Байлык 170
Саклап тора җәза 171
Димәс идем... 172
Сыерга сыену 173
Маймыл бизмәне 174
Мәхлук 175
Бакыр казан, җиз комган 176
Элгәреләр һәм бүгенгеләр 177
Нигә шулай? 178
Чигүле дөнья 179
Байлык белән сынау 180
Өмет 181
Изге нур алып 181
Үз иленә хуҗа илбашлары – 182
Фәлсәфи яңгыр 183
Әйләнеш 184
Сөйлим ихластан... 186
Күктән иңде 187
Әнкәм васыяте 187
Әнием Хәбибҗамал 188
Гафу ит... 189

Татарыңа акыл иңдер....190
Изге Болгар җирендә....191
Болгар җирен тездән үлән япкан,....193
Йөзен кулы белән каплап,....194
Барысы да Аллаһ кодрәтендә....195
Татар язы килер....197
Иҗат газабы....198

III бүлек
Әй син, татар! Асылыңа кайтып,
Илне-динне сакла,
горур бул!

Әсәрләр тажы....202
Васыять....204
Яшәү шарты....205
Оныгым Шамилгә....207
Оныкларым!....208
Оныгымның оныгына....209
Догалы тамга....210
Аллаһ әмере белән....211
Тиңсез бүләк....212
Илче булсын....212
Хисап тоту....213
Мин – татармын!....214
Бәхетем әлифбасы....215
Әманәт....216
Тартыш....218
Татар язмышы....219
Атлар чаба....220
Ат һәм Кеше....222
Нигә?....223
Җитәр вакыт....224
Үзең хуҗа бул!....224
Син белеп тор....225
Бергә булыйк, бердәм булыйк!....226
Дәүләтеңне торгыз!....227

Кайда ялгыштың? 228
Күңел очынганда 229
Өмет 230
Төерле татар 231
Мокыт турында 232
Татарлык билгесе 233
Булма гафил! 234
Вакыт! 235
Милли корт 235
Метаморфоза 236
Бер кыйтга 237
Уйлан, Кеше! 238
Хисап 239
Буталган мәгыйшәт 240
Кемгә нинди бәхет? 241
Була – булмый 242
Ни өчен яшисең? 242
Лаекмы син? 243
Зиратларда 244
Әй, җир-әнкәм 248
Фаҗига 249
Бәрәкәтле хәрәкәт 251
Шулай булыр! 252
Әгәр 253
Бертуганнар 254
Кемдә гаеп? 255
Үз җаенда 257
Ялгышты 258
Мода корбаннары 258
Җәза 259
Тәкъдир 259
Аналар күрке 260
Артка таба йөгерү 260
Бурыч үтәү 262
Сәрхүшлекне яңгыр юмакчы 263
Сабырлык турында 264

Теләк 265
Яшәеш кануны 266
Албасты 268
Тансыклаган төш 269
Исеңдә тот! 270
Синең барыр юл 271
Болгар җыенында 274
Аллаһ юлы 277
Ә син беләсеңме? 277
О син, кеше! 279

IV бүлек
Поэмалар

Аллаһка мәдхия 286
Иң югары бәһа 316
Язмышка нәсыйхәт 333
Кол Шәриф мәчетенә мәдхия 344
Ахирәткә хат 352
Ташлар сере 389
Хатын-кызга мәдхия 396
Йә, әйт, Кеше! 404
Памир 410
Безнең заман 446

Дүртьюллыклар (Дини мотивлар) 451

Автобиографик уйланулар 482

Рәис Сафин

АЛЛАҺКА МӘДХИЯ

Рәссам Нәҗип Нәккаш

Техническое редактирование
и компьютерная верстка – Азат Гапсаламов

Сдано в набор 14.02.2018 г. Подписано к печати 23.05.2018.
Формат 60x90 1/16. Бумага офсетная.
Гарнитура «Таймс». Печать ризографическая.
Усл. печ. 31 л. Тираж 100 экз. Заказ № 4.

420111, Казань, Дзержинского, 9/1. Тел. 8 917-264-8483.
Отпечатано в редакционно-издательском центре «Школа».
E-mail: ric-school@yandex.ru